ЯҢӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

№ 10 (345)
ОКТЯБРЬ 2020

# ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ISSN 0130-2418

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

## АЛМА – АГАЧЫНА, БАЛА АТАСЫНА ОХШАР

*Гаилә уңышы серләре...*

4 612750 670011

16+

**Редакция:**
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

**Баш мөхәррир:** Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
**Шеф-редактор:** Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
**Баш мөхәррир урынбасарлары:**
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Дәүләтшина
**Чыгарылыш мөхәррире:**
Фәридә Әхмәтҗанова
**Бүлек мөхәррирләре:**
Олеся Бондаревская, Ольга Туманская, Руфия Фазылова
**Веб-редактор:** Алсу Дәүләтшина
**Авторлар:** Илдус Заһидуллин, Мөршидә Кыямова,
Ксения Сёмина
**Фотографлар:** Александр Ефремов, Лилиана Вәлитова
**Дизайн-макет:** Леонид Гобәйдуллин
**Вёрстка:** Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин
**Препресс:** Игорь Глушков
**Корректор:** Айсылу Корманова
**Офис-менеджер:** Ләйсән Һадиева
**Тышлыкта:** Александр Ефремов фотосы

**Журнал 1920 елдан нәшер ителә**

1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

**Тираж:**
**1 880 данә**

**Бәясе ирекле**

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан» журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела. Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция җавап бирми.

Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

**Заказ №** А-2680
**Басарга кул куелды:** 15.10.2020
**Басмадан чыкты:** 21.10.2020

**Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:**
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com

**Махсус проектлар бүлеге җитәкчесе:**
Алсу Троицкая, alsu_1970@list.ru
тел.: (843) 222-09-79

**Коммерция директоры:**
Юлия Фәсәхова, 89272483384_pr@mail.ru
тел.: (843) 222-09-76, +7-9272-483-384

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә
2350 данә тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4230 данә

Реклама 16+

**Бухгалтерия:**
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

# ХЫЯЛЫҢНЫ КЫЗУЫНДА СУК!

Әгәр сезгә дөньяда булмаган нәрсә кирәк икән – хыяллану гына аз! «Эх, әгәр шул әйбер булса иде... Юк инде, хыялланырга гына кала» дип, уфтанып-сукранып утырырга ярамый. Гел зарланырга яратучыларның уй-хыяллары тормышка ашмый. Йолдызлардай ерак тоелган хыялга, авырлыклар аша үтеп, кыю рәвештә юл яра барган тәвәккәлләр генә үзләренекенә ирешә. Башта хыял якыная, аннан чынга аша, үз нуры белән башкаларны (янәшәдә атлаучыларны да, ерактагыларны да) җылыта, аларда өмет уята, нәкъ безнең басмабыз геройларыныкы кебек. Аларның һәркайсы үз хыялын кызуында суга, кирәк вакытта, кайнар вакытында.

Шәхси кебек тоелган хыялларын тормышка ашырып, мондый фидакарьләр уртак галәмебезне яхшыга үзгәртә. Моның өчен аларга зур рәхмәт әйтәсе килә. Бер файдасы булмаган ниндидер тренингларда түгел, бәлки, конкрет эш-гамәлләре белән үрнәк биргәннәре, хыялларын чынга ашырып күрсәткәннәре өчен рәхмәт аларга!

*Сезнең хыялый редакциягез.*

**Редакция советы:**
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фарит Рафкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВ Разил Исмәгыйлевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы:
«ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче:
«ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

**Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла**
**Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә**

**«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә**
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә
Ярты елга язылу бәясе: **942 сум 00 тиен**

**«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:**
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

#татарстанның 100 җәүһәре
#бары тик татарстанда
«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНА 100 ЯШЬ

## ЕВРОПАНЫ ӘСИР ИТКӘН ХОР

2008 елда озак эзләнүләрдән соң Казанның Арча зиратында музыкаль медиевист Степан Смоленскийның кабере табыла. Аның исеме совет чорында онытыла төшә, гәрчә ул бөтен дөньяга билгеле шәхес булса да. Чиркәү җырларын өйрәнүче-тикшерүче буларак, галим Степан Смоленский вокаль-хор җырларына өйрәтү буенча уникаль методика, тавышны үстерү буенча аерым ысуллар эшли. Казаннан Мәскәүгә күчеп киткәннән соң, Степан Васильевич Мәскәү чиркәү җырлары Синодаль училищесының директоры була. Аның хезмәтләренә Чайковский, Римский-Корсаков, Рахманинов соклана, ә хор үзе бөтен Европаны әсир итә!

© «Татарстан» журналы
WWW.PROTATARSTAN.RU

# ЭЧТӘЛЕК

## акыллы гамәлләр

**4. Татарстан – мөмкинлекләр республикасы**
Президент нинди бурычлар куя

**8. Булачак мегаполисы**
Иске шәһәргә яшьлек алып кайтучы концепция турында

**14. Рэп татар телен сакларга булышырмы,**
яисә Музыка ничек итеп телне һәм традицияләрне саклап кала ала

## игелекле эшләр

**26. Рәсем сәнгате**
Мураллар ни турында сөйли

**34. Кемдер югала, кемдер таба...**
Гөмбәчеләр кемнәрнең йокыларын һәм тынычлыкларын алалар

**40. Йөрәк авазы**
Ятимнәр ничек ата-ана назын таба

**46. Үзенчәлекле балалар дөньясы**
Кондуктив балалар бакчасы кемгә булышыр

**50. Мостай Кәрим**
Таш өстендә гөлләр үстергән шагыйрь

**56. Мәдәният**
Мингол Галиевнең тормыш линиясе

## мәңгелек кыйммәтләр

**62. Гади кешеләр – бөек тарих**
Мамадыш музее ничек итеп гасыр музеена әверелә

**65. Тукай: тормышы һәм язмышы**
Кадерле ядкәрләр кайда саклана

**68. Сугыш кайтавазы**
Җиңүчеләр буынының ике вәкиле аның турында нәрсәләр белгән

**72. Тарихи сәхифәләр**
Кем ул Хәсәнгата Габәши

**83. Татар авыллары**
Дүрт Өйледә ничә өй бар

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
**protatarstan.ru**

Акыллы гамәлләр

# 18.09

**Рөстәм МИҢНЕХАНОВ – С.Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залында Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына керешү тантанасында:**

– Безнең алдыбызда – зур, җентекле бердәм хезмәт тора. Алдагы биш елда республикабызның ничек үсәчәге, анда яшәүнең ни дәрәҗәдә уңайлы булачагы бездән тора. Безнең барыбызга да бу юлда уңышлар юлдаш булсын! Барыгызга да оптимизм, бәхет һәм иминлек телим!

# 15.09

**Ольга ЛЮБИМОВА, РФ мәдәният министры, – Казан ратушасында Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Мәдәният һәм сәнгать советы утырышында:**

– «Мәдәният» милли проекты чараларын бер кимчелексез тормышка ашырганнары өчен төбәк җитәкчелегенә аерым рәхмәт әйтәсем килә. 2019 ел нәтиҗәләре буенча куелган барлык бурычлар һәм максатчан күрсәткечләр үтәлгән. 70 тән артыграк объект төзелгән һәм капиталь төзекләндерелгән, 3 модельле китапханә, 5 виртуаль концерт залы, 6 кинозал ачылган инде. Татарстан – һәрвакыт безнең яңа проектларда пилот төбәк буларак актив катнашучы ышанычлы партнерыбыз.

Игелекле эшләр

Мәңгелек кыйммәтләр

# 3.10

**Марина ПАТЯШИНА, Роспотребнадзорның ТР буенча Идарәсе башлыгы, Татарстан Республикасы буенча баш дәүләт санитар врачы, – Хөкүмәт йортындагы киңәшмәдә:**

– Авыру очраклары теркәлгән 127 хезмәт коллективының 83 ендә хезмәткәрләрнең авыруына китерергә мөмкин булган кагыйдә бозулар ачыкланды... Нинди дә булса салкын тию авыруы билгеләре булган кешеләрне эштән азат итүгә контрольне көчәйтү аеруча мөһим.

акыллы гамәлләр

Акыллы гамәлләр

Мәңгелек кыйммәтләр

Игелекле эшләр

## Бу санда тәкъдим итәбез:

Татарстан **ни рәвешле** мөмкинлекләр республикасына әверелде

**Нинди** проектлар безнең киләчәгебезне яхшыртачак

Казанга **нәрсә** тарихи затлылыкны кайтарыр

Музыка **ничек** туган телне һәм традицияләрне сакларга булыша

# РӨСТӘМ МИҢНЕХАНОВ: ТАТАРСТАН – МӨМКИНЛЕКЛӘР РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТР Президентының Татарстан Дәүләт Советына Юлламасы**

## ХАКИМИЯТ ҺӘМ ҖӘМГЫЯТЬ ТУРЫНДА

**Хакимият органнарыннан кешеләр бүгенге көндә аларның ачык һәм аңлаешлы булуын, үзләрен борчыган мәсьәләләрдә ярдәм күрсәтүен көтә.** Фикерләрнең үзебезгә ошаганнарына гына түгел, бәлки һәрберсенә игътибар бирергә, аларны эш барышында исәпкә алырга һәм гражданнарга үз карашларыбызны дәлилләп җиткерә белергә тиешбез.

**Хакимият органнарына халык белән эшләүнең заманча барлык ысулларын үзләштерү шарт.** Бу безгә урыннардагы хәлләрнең чынбарлыктагы торышын белергә, тиз арада карарлар кабул итәргә, эшне җиренә җиткереп башкарырга ярдәм итәчәк.

Дәүләт идарәсен цифрлы нигезгә күчерү җәмгыять белән дәүләт хезмәттәшлеге өчен яңа мөмкинлекләр ача. **«Цифрлы Татарстан» проектын үстерүне дәвам итәргә кирәк.**

Халык белән кара-каршы элемтә системасын үстерүдә һәм социаль башлангычларны хуплауда гражданлык җәмгыяте институтлары һәм иҗтимагый оешмалар мөһим роль уйный. **Без аларның социаль әһәмияткә ия булган проектларына ярдәм итүне киләчәктә дә һичшиксез дәвам итәчәкбез.** Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасының бу эшчәнлектә тоткан роле көннән-көн үсә. Бу гамәлләрне башкарганда министрлыклар һәм ведомстволарның гражданнар тарафыннан хупланган гавами максатлары һәм бурычлары үтәлешенең сыйфатына иҗтимагый контрольне көчәйтергә кирәк.

## МӘДӘНИЯТ ҺӘМ ТЕЛ ТУРЫНДА

Республикада яшәүче һәр халыкның мәдәниятен, үзенчәлеген саклау һәм үстерү, милләтара һәм динара татулык тотрыклы тормышыбызның нигезен тәшкил итә һәм безгә ышанычлы адымнар белән алга барырга мөмкинлек бирә.

Казан Мәрьям Ана иконасы соборын төзүне тәмамлап киләбез, шулай ук 2022 елда Идел Болгарстанының Ислам динен кабул итүенә 1100 ел тулу уңаеннан бәйрәм тантаналары узачак. **Әлеге чараларны югары әзерлек белән, тиешле дәрәҗәдә уздыру күпмилләтле Татарстанның рухи, мәдәни мирасын һәм үзенчәлеген саклау юнәлешендә зур хезмәт куелуына ачык дәлил булачак.**

Балаларны һәм яшьләрне үзара ихтирам һәм милли-мәдәни үсеш рухында тәрбияләүгә аерым игътибар бирергә, аларның туган телне һәм мәдәниятне өйрәнүгә кызыксыну белдерүен хупларга кирәк.

Шундый проектларның берсен «Яңарыш» республика фонды гамәлгә ашыра. **Минтимер Шәрип улы Шәймиевнең зирәк җитәкчелегендә татар, рус һәм инглиз телләрендә белем бирелә торган «Адымнар» полилингваль мәгариф комплекслары төзелә.**

Тел – халыкның уртак байлыгы һәм мирасы, рухи яктан берләштерүче зур көч.

Бөтендөнья татар конгрессының бурычы – «Милләт җыены»нда кабул ителгән Стратегияне тормышка ашыру. **Без Марат Готыф улы Әхмәтов җитәкли торган Татар телен саклау һәм үстерү мәсьәләләре комиссиясенә дә зур өметләр баглыйбыз.** Бу эштә барлык хакимият органнары һәм иҗтимагый оешмалар катнашырга тиеш. Шул ук вакытта һәркемнең шәхси үрнәге мөһим.

Туган тел ул – иң әүвәл үз халкың белән күңелнең иң нечкә кыллары аша бәйләнеш. Мин һәрчак әйтә киләм: без туган телне саклау өчен барысын да эшләячәкбез. Бу – киләчәк буыннар алдында безнең әхлакый бурычыбыз.

Республикада яшәүче барлык милләт вәкилләренең – татарларның, русларның, чувашларның, удмуртларның, мордваларның, мариларның һәм башка халыкларның телен һәм мәдәниятен саклау өчен барлык шартларны булдырырга тиешбез. **Әлеге мәсьәләгә һәм республиканың күпмилләтле халкының берләшүенә зур әһәмият биреп, киләсе елны Татарстанда Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елы дип игълан итәргә дигән тәкъдим кертәм.**

## РОССИЯ КҮЛӘМЕНДӘ ХАЛЫК САНЫН АЛУ

Бөтен Россия күләмендә халык санын алу киләсе елда мөһим вакыйгаларының берсе булачак.

Республика Хөкүмәтенә, муниципаль берәмлекләр башлыкларына тиешле аңлату эшләре алып барып, бу эштә җәмәгатьчелекнең актив катнашуын тәэмин итеп, аны иң югары дәрәҗәдә оештыруны йөклим. **Халык санын исәпкә алу нәтиҗәләре икътисад, демография, социаль өлкәдә стратегик планлаштыру өчен генә түгел, һәр милләт өчен дә бик мөһим.**

## УҢАЙЛЫ МОХИТ ТУРЫНДА

Эшебездә без кешеләрнең мәнфәгатьләрен кайгыртуга, яшәү өчен уңайлы мохит булдыруга зур өстенлек бирәбез. Республика программалары һәм илкүләм проектлар нәкъ менә шушы максатларны күздә тотып гамәлгә ашырыла. Ил Президенты Владимир Владимирович Путинның милли максатлар турындагы Указын гамәлгә ашыру кысаларында безгә үзебезнең үсеш программаларына төзәтмәләр кертергә кирәк булачак.

Шул ук вакытта республиканың 2030 елга кадәр үсеш стратегиясе нигезендә безнең төп бурычларыбыз үзгәрешсез кала. Бу – кеше капиталын үстерү һәм тормышны яхшырту. Хакимиятнең барлык тармаклары һәм дәрәҗәләре эшчәнлеге нәкъ менә шуларны хәл итүгә юнәлтелергә тиеш.

**Безнең эшебез халыкның үз тормышыннан ни дәрәҗәдә канәгать булуыннан чыгып бәяләнә.**

Төзекләндергән һәм яңа мәктәпләр, балалар бакчалары, хастаханәләр һәм поликлиникалар, парклар һәм скверлар, спорт объектлары ачу, юлларны файдалануга тапшыру гадәти күренешкә әйләнде. Елданел безнең шәһәрләр һәм авыллар матурлана бара. Без бу масштаблы эшне республика программалары һәм милли проектлар кысаларында дәвам итәчәкбез.

**Шунысын да әйтергә кирәк: объектны төзү әле ул эшнең башы гына. Аны алдан ук кадрлар белән тәэмин итәргә, яшәешен оештырырга кирәк.** Монда тормыш кайнап торырга тиеш. Андый учреждениеләрне бары халыкка чынлап та кирәк һәм икътисадый яктан максатка ярашлы булган урыннарда төзү зарур.

**Проектларны гамәлгә ашырганда, халыкның фикерен исәпкә алу, аның белән хезмәттәшлек итү һәм киңәшләшеп эшләү бик мөһим. Тәҗрибә күрсәткәнчә, нәкъ менә шундый проектлар уңышлы була.**

**Күптән түгел Казансу елгасын төзекләндерү стратегиясен расладык.** Анда 30 километрга сузылган яр буе һәм 3 мең гектардан артык мәйданда урнашачак 12 парк төзү каралган.

**Моннан тыш, якындагы елларда без күпфатирлы йортларның 6,5 меңнән артык ишегалдын төзекләндерәчәкбез.** Быел планда – 1000 объект.

Туплаган тәҗрибәбез, һөнәр һәм күнекмәләребез төзекләндерү эшләре белән комплекслы шөгыльләнергә – яңартылган мәдәният йортлары, яр буйлары, парклар, ишегаллары үзара бәйләнгән һәм юллар белән тоташтырылган булуын тәэмин итәргә мөмкинлек бирә.

**Торак төзелеше өлкәсендә илкүләм проектны кабул итү нәтиҗәсендә безнең алга җитди бурычлар куелды.** Бу эшне торакны файдалануга тапшыруны арттыру максатыннан чыгып кына түгел, бәлки социаль тирәлек, транспорт, инженерлык тирәлеге объектларын төзүне, шулай ук эш урыннары булдыруны да күздә тотып, комплекслы итеп башкарырга кирәк.

Татарстан Республикасы Хөкүмәтенә Муниципаль берәмлекләр башлыклары Советы белән берлектә агломерацияләр өчен территорияләрне планлаштыруның бердәм документларын әзерләүне тәэмин итәргә, шулай ук әлеге территорияләрне комплекслы үстерүгә идарәнең нәтиҗәле алымнарын эшләргә кирәк.

**Бу безгә, «яшәгән урынымда эшлим» дигән принципка нигезләнеп, шул исәптән сәнәгать мәйданчыкларын оештыру аша да, яңа эш урыннары булдырырга мөмкинлек бирәчәк.**

Кече шәһәрләрне һәм авылларны комплекслы үстерү бурычлары шулай ук хәл ителергә тиеш.

Биредә эш урыннары булдыру бик мөһим.

## СӘЛАМӘТ ЯШӘҮ РӘВЕШЕ ҺӘМ СӘЛАМӘТЛЕКНЕ САКЛАУ

**Безнең планнарда – беренчел медицина-санитария ярдәме күрсәтү өлкәсендә матди-техник базаны яхшыртуны дәвам итәргә, онкология белән чирләүче балаларны дәвалау өчен яңа ысуллар кулланыла торган үзәк, Чаллыда һәм Әлмәттә Республика клиник онкология диспансеры филиалларын, Әлмәт балалар шәһәр хастаханәсенең хирургия корпусын, шулай ук Казанда күз авыруларын дәвалау хастаханәсе** һәм башка шундый заманча медицина объектлары төзергә ниятебез бар.

Тармакны кадрлар белән тәэмин итү элеккечә үк көнүзәк мәсьәлә булып тора. Киләсе елда гына да Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына 400 гә якын табибны, тулаем

PRESSA



исәпләгәндә 2 меңнән артык белгечне эшкә җәлеп итәргә кирәк булачак.

Медицина тармагын цифрлы технологияләр нигезенә кору шулай ук мөһим бурыч булып тора. Бу эш иң беренче нәүбәттә төрле белешмәләрне һәм тикшеренү узган авыруларга табиб бәяләмәләрен тиз арада тапшыру мөмкинлеге кебек мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән булырга тиеш.

**Дәүләт һәм хосусый медицина учреждениеләренең электрон медицина карталары булдырылган бердәм цифрлы контурын төзү шарт.**

Хәзерге шартларда югары технологияле медицина ярдәме күрсәтүнең кичектерелгән процедураларын, авыруларны планлы төстә хастаханәләргә салу юнәлешендә үтәләсе эшләрне тәмамларга кирәк.

Диспансеризация – халыкның ел саен планлы рәвештә медицина тикшеренүләре узуына аерым игътибар бирелергә тиеш. Тирән тикшеренүләр үткәрү авыруларны башлангыч чорда ук ачыкларга мөмкинлек бирә.

Сәламәтлекне саклауның иң яхшы ысулы – аны ныгыту, сәламәт яшәү рәвеше алып бару, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнү. **Безгә алга таба да гражданнарның төрле категорияләре шөгыльләнә алырлык спорт инфраструктураларын үстерүне дәвам итәргә кирәк.**

Балаларның һәм яшьләрнең җәйге ялын оештыру да аларның сәламәтлеген ныгыту яхшы этәргеч бирә. **Икенче ел рәттән без лагерьларны үзгәртеп кору буенча комплекслы программаны гамәлгә ашырабыз.** Барлыгы 94 лагерьны яңартырга ниятлибез. Аларның һәркайсы яшь буынның сәламәтлеген кайгыртуга юнәлдерелгән эш алып бару өчен универсаль мәйданчык хезмәтен башкарачак.

## ФӘН, МӘГАРИФ, ГАИЛӘ ҺӘМ ТӘРБИЯ ТУРЫНДА

Тарихыбыз һәм мәдәниятебез белән ихластан горурланучы, ата-бабаларыбыздан югары әхлак һәм батырлыкны мирас итеп алган, республикабызның һәм күпмилләтле Россиянең чын ватанпәрвәрләрен тәрбияләү мөһим бурыч булып тора.

**Яшьләргә үз мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен шартлар тудыру эшен һичшиксез дәвам итәргә кирәк.** Нәкъ менә яшьлек чорына әзләнү хас, һәм ахыр чиктә кеше өчен үзенең яшәү һәм үсеш урынын сайлый. Яшьләр үз язмышларын республика белән бәйләсен өчен, без барысын да эшләргә тиешбез.

**Без, һичшиксез, балалы гаиләләргә булышлык итү эшен дәвам иттерәчәкбез.**

**Сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикле, социаль яктан якланмаган һәм ярдәмгә мохтаҗ гражданнар, төрле сәбәпләр аркасында авыр тормыш хәлендә калган кешеләр һәрвакытта да даими игътибар үзәгендә булырга тиеш.** Безнең тарафтан тормышка ашырыла торган барлык проектларда аларның мәнфәгатьләре максималь дәрәҗәдә исәпкә алынырга тиеш.

Татарстанда мәдәниятне үстерүгә, аның инфраструктурасын камилләштерүгә зур игътибар бирелә. **Иң мөһиме – безнең мәдәни объектларыбыз һәркем өчен уңайлы, теләп йөри торган урын булырга тиеш.** Матди-техник базаны үстерү һәм ныгыту белән беррәттән, тарихи-мәдәни мирасны саклау, иҗат коллективларына һәм мәдәният әһелләренә ярдәм итү, тармак өчен кадрлар әзерләү юнәлешендә зур эш алып барыла. Мәдәният буенча советның күптән түгел уздырылган беренче утырышында әлеге һәм башка өстенлекле мәсьәләләр тикшерелде. Алар Татарстан мәдәниятенең киләсе 10 елда үсеш стратегиясе проектына кертелергә тиеш.

**Республиканың югары мәктәбе һәм фәнни оешмалары алдында икътисадның реаль секторы белән перспективалы үсеш юнәлешләре буенча тыгыз хезмәттәшлек алып баруны тәэмин итү кебек җитди бурыч тора.** «Фән» милли проекты кысаларында Казан федераль университетында ачылган «Планетадагы сыек углеводород запасларын нәтиҗәле үзләштерү» дөнья дәрәҗәсендәге фәнни үзәкне мисалга китерергә була.

## ИКЪТИСАД ҺӘМ БИЗНЕСКА ЯРДӘМ ТУРЫНДА

Халыкның тормыш сыйфатын яхшырту һәм аның иминлеген тәэмин итү нәтиҗәле икътисадка нигезләнә. Бүгенге көндә нефть-газ-химия комплексында республика өчен стратегик әһәмияткә ия кайбер инвестиция проектлары тормышка ашырыла. Быел «Татнефть» компаниясенең «ТАНЕКО» проектын гамәлгә ашыра башлавына 10 ел тула. Инвестицияләрнең гомуми күләме 424 млрд сумнан артып китте. Нәтиҗәдә республикада чыгарыла торган нефтьнең яртысыннан артыгы үзебездә эшкәртелә. Әлеге проект буенча эш дәвам итә. **Быел яңа производстволарга 55 млрд сум күләмендә инвестицияләр кертү планлаштырыла.**

Шулай ук «ТАНЕКО» проектының мөһим нәтиҗәсе – республиканың нефть эшкәртү сәнәгатендә үз инжиниринг компетенциясен булдыру. Шуны да билгеләп үтәсем килә: икътисадның башка секторларына да үз компетенцияләрен үстерү зарур.

**Дөнья һәм Россия полимерлар җитештерү базарларында көндәшлек көчәйгән шартларда «ТАИФ» Компанияләр төркеменең яңа производстволарын ачуны һәм гамәлдәгеләрен яңартып коруны кыска вакыт эчендә тәмамларга кирәк.** Бу – «Түбән Кама Нефтехим»да яңа ЭП-600 олефин комплексы, «Казан Органик синтез»да полимерлар җитештерүне арттыру, шулай ук яңа генерация куәтләрен булдыру проектлары. Моннан тыш, «ТАИФ-НК»ның калдыкларны тирәнтен эшкәртү комплексын көйләп-эшләтеп җибәрүне тәмамларга кирәк. Аны сафка бастыру республикада нефть чималын эшкәртүнең тирәнлеген арттырырга мөмкинлек бирәчәк.

Җитештерүнең нәтиҗәлелеген арттыру максатында оборона-сәнәгать предприятиеләренә, Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы белән берлектә, производстволарны диверсификацияләү өчен, гражданнар өчен чыгарыла торган продукциянең перспективалы базарларын исәпкә алып, үз техник-технологик мөмкинлекләрен анализларга кирәк.

Икътисад үсеше нәтиҗәле өстәмә энергетика куәтләрен булдыруны таләп итә. Гомуми куәте 1,4 гигаваттлык 5 станцияне яңартып кору федераль программага кертелде. Алар арасында 850 мегаваттка исәпләнгән Зәй ГРЭСын яңартып кору буенча зур проект бар. Яр Чаллы җылылык-электр үзәгенә кагылышлы мәсьәлә һаман да әһәмиятен җуймый. Хөкүмәткә, «Татэнерго» белән берлектә, әлеге объектны федераль программага кертү мәсьәләсен карап тикшерүне йөклим.

**Бизнеска ярдәм күрсәтү инфраструктурасы эшлекле һәм инвестицион активлыкны арттыруга көчле этәргеч бирә.** ТР Икътисад министрлыгына, район башлыклары белән берлектә, сәнәгать парклары һәм мәйданчыклары эшенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне һәм аларны тормышка ашыруны йөклим.

**Безнең төп бурычыбыз – эшкуарлар өчен, кече һәм урта бизнесны үстерү өчен уңайлы шартлар булдыру.** Күпләр моны әлегә кадәр тулысынча аңлап бетерми. Үз эшеңне башлап җибәрү, яңа производстволар ачу, эш урыннары булдыру – чын мәгънәсендә, олы хөрмәткә һәм дәүләт ярдәменә лаеклы зур хезмәт. Әлеге максатларда республикада финанс, белем бирү, милек мәсьәләләренә кагылышлы, шулай ук базарларга юл ачу кебек ярдәм чараларының тулы бер комплексы гамәлгә ашырыла.

Эшкуарларга маркетплейс инфраструктурасы мөмкинлекләреннән активрак файдаланырга кирәк.

Икътисадның динамикалы үсеше күп очракта продукция җитештерүнең барлык циклларына бәйле процессларның цифрлы нигезгә корылу дәрәҗәсенә бәйле. Сәнәгатьтә ясалма интеллект һәм әйберләр интернеты нигезендә цифрлы технологияләрне һәм карарларны кулланышка кертү тиз арада иң уңышлы бизнес-карарлар кабул итәргә, җитештерү чыгымнарын киметергә, хезмәт җитештерүчәнлеген һәм компаниянең базарда көндәшлеккә сәләтлелеген арттырырга мөмкинлек бирә.

**Шушы максатларда без ИТ-парк базасында Цифрлаштыру мөмкинлекләре үзәген – үзенә күрә «киләчәк фабрикасы» төзергә планлаштырабыз.** Әлеге үзәктә гамәли тәҗрибә алу республика компанияләренә 4.0 Индустриясе мөмкинлекләрен эзлекле һәм максатчан рәвештә үзләштерергә ярдәм итәчәк.

Хөкүмәткә, тулаем алганда, цифрлы нигезгә күчүне тәэмин итү өчен төп тармакларны цифрлаштыруны иң югары дәрәҗәсенә җиткерү буенча карарлар эшләргә, бу тармакның һәрберсен цифрлаштыруның торышына, кадрларның әзерлегенә бәя бирергә кирәк.

Предприятиенең киләчәген кайгыртучы җитәкче, беренче чиратта, үзенең коллективы турында уйларга тиеш. Бу кадрларның даими рәвештә яңа технологияләрне, дөнья күләмендә иң яхшы тәҗрибәләрне үзләштерүенә һәм, һичшиксез, аларның лаеклы хезмәт хакы алуына да кагыла.

Моннан тыш, предприятиеләр экологик иминлекне тәэмин итүне җитди контрольдә тотарга тиеш.

Бүгенге көндә республика предприятиеләрендә чистарту корылмаларының 80% ка якыны норматив таләпләренә җавап бирми. Хуҗалык итүче субъектларның һәм тиешле хакимият органнарының әлеге мәсьәләне хәл итүдә катгый чаралар күрүен сорыйм.

АСК өлкәсендә авыл хуҗалыгы җитештерүенең нәтиҗәлелеген арттыру буенча эшне дәвам итәргә кирәк. Һичшиксез, яңартып кору, яңа технологияләрне кулланышка кертү, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү процесслары белән идарә системасының нәтиҗәлелеген арттыру хезмәт җитештерүчәнлеген арттыра, шулай ук хезмәт шартларын яхшыртуга, эш хакын арттыруга һәм, иң мөһиме, әлеге тармакка яшьләрнең килүенә этәргеч бирә.

Бүген без, нигездә, фермерлык хәрәкәтен булдыру этабын уздык, дип әйтергә мөмкин. Аны тагын да үстерү киләсе унъеллыкка бурычыбыз булып тора. **Һәрбер фермерлык хуҗалыгы авылның таянычы һәм авыл җирлегенең ышанычлы хезмәттәше булырга тиеш. Үз чиратында хакимият органнары инициативалы фермерларга булышлык күрсәтергә тиеш.**

Хәзерге вакытта дөньяда хәләл продукция куллану үсә бара. Бу товар җитештерүчеләребезнең продукцияләрен экспортлауны арттыру өчен яхшы мөмкинлек.

Агросәнәгать комплексында авыл хуҗалыгы продукциясен чит илләргә чыгаруны ике тапкыр арттырырга, терлекчелек һәм үсемлекчелектә селекция эшен яхшыртырга һәм ветеринария иминлеген тәэмин итү буенча барлык чараларны күрергә кирәк. **Агросәнәгать комплексын тагын да нәтиҗәлерәк эшләүче һәм көндәшлеккә сәләтле тармак итү – безнең уртак бурычыбыз.**

М-7 автомобиль юлының, Түбән Кама һәм Чаллы шәһәрләрен урап, Кама күпере аша уза торган участогын, шулай ук Казан шәһәренең көньягыннан Идел күпере аша салыначак югары тизлектәге М-12 трассасын, «Шәле–Баулы» автомобиль магистрален, Зур Казан бокрасының икенче чиратын һәм метрополитенның икенче линиясен төзү эшен тәмамлау стратегик проектлар булып тора.

**Без транспорт инфраструктурасы объектларын төзекләндерү, торак пунктларыбызны асфальт юлларга тоташтыру, фермерлык хуҗалыкларына керү юллары салу эшен дәвам итәчәкбез.**

Әлеге барлык проектлар, иң беренче чиратта, гражданнарның тормышын яхшыртуга юнәлдерелгән.

**Татарстан – мөмкинлекләр республикасы, биредә һәркем үзенең уй-ниятләрен тормышка ашыра ала.** Иң мөһиме, без бергә! Димәк, без барысын да булдырабыз! Без бергә! Безнең көч – бердәмлектә!

# КИЛӘЧӘГЕБЕЗНЕ ЯХШЫРТЫРГА ТИЕШЛЕ ПРОЕКТЛАР

# КАЗАН ЯҢА КАГЫЙДӘЛӘР БУЕНЧА

Фото ТР Президентының рәсми сайтыннан (Рөстәм Кадыйров)

**Татарстан башкаласында Тарихи җирлекне тотрыклы үстерү концепциясе эшләнде. Тарихи үзәктәге төзелешләрне тәртипкә салу методикасы Россиядә беренче тапкыр масштаблы документка әверелде, ул «шәһәр төзелеше конституциясе» дигән рәсми булмаган статус та алырга өлгерде. Аны гамәлгә керткәннән соң, шәһәрне нәрсә көтә?**

**Автор:**
Ольга Туманская

Һади Такташ урамындагы күпфункцияле комплекс.

Концепция ике ел дәвамында эшләнә. Аны әзерләү төркеменә, архитекторлардан һәм шәһәр төзелеше белгечләреннән тыш, социологлар, тарихчылар, культурологлар, юристлар керә. Ә тикшеренүләр һәм регламентлар җыелмасы биналарның архитектурасына гына түгел, урамнар, ландшафт һәм хәтта тарихи урыннардагы шәһәр тормышына дә кагыла.

## АНЫК КАГЫЙДӘЛӘР – ИҖАТ ӨЧЕН ИРКЕНЛЕК УЛ

Документ барлыгы 2225 гектарны колачлый, бу – гомуми шәһәр мәйданының 4 процентган бераз гына артыграк өлешен тәшкил итә һәм аның тарихи җирлеге территориясе булып тора, анда бүген меңгә якын тарихи бина, 36 музей, 25 бакча һәм парк, 9 югары уку йорты һәм 7 театр урнашкан.

Ни кызганыч, шәһәр үзәге тигез үсеш алмаган, читтәрәк калган җирләр төзекләндерелгән үзәктән шактый калыша, сурәтләргә төшерерлек матур архитектура манзаралары күршесендә – максат-бурычлары бик шикле заманча биналарны күрәбез. Дилемма килеп чыга, шулаймы?

– Бүген Казан республиканың матур тышкы киемен тәшкил итә, шуңа да карамастан үзәкне туристлар өчен түгел, ә үзебез өчен тәртипкә салу, җыештыру белән шөгыльләнер вакыт җитте, – ди проект төркеме җитәкчесе Олег Маклаков. – Әлбәттә, сүз сүтү-җимерү турында бармый. Концепция бөтенләй башка карашны күз уңында тота. Концепция буенча төгәл регламентлар кертеләчәк, билгеләнгән парадигма кысаларына сыймаган бина хуҗаларында төзелешкә бәйле ниятләр барлыкка килгәч, алар да үз участокларын кагыйдәләргә туры китереп яңартачак дигән сүз. Әмма мәсьәләнең икенче ягы да бар. Башка масштабтагы яңа, матур архитектура үрнәкләре – уңайлы, комплекслы шәһәр төзелеше мисаллары барлыкка киләчәк. Ә инде шул рәвешле әйләнә-тирә мохит үзе таләп итә башласа, вазгыять акрынлап үзгәрәчәк.

Сүз дә юк, тарихи территория – девелоперлар һәм архитекторлар өчен майлы калҗа, әмма әле бер кочак килештерүләр, рөхсәтләр һәм проблемалар да бар. Проектны әзерләүчеләр ышандырганча, концепция төзүчеләргә һәм инвесторларга өстәмә кыенлыклар тудырмаячак. Киресенчә, ул мондый проектларны килештерү вакытын 15 айдан 8 айга кадәр киметергә һәм аларны уңышлы үтеп чыгу процентын 75 тән 90 га кадәр арттырырга мөмкинлек бирәчәк. Ничек итепме? Анык кагыйдәләр һәм эш регламентлары ярдәмендә!

– Бурычыбыз – шәһәр структурасын саклап калу, шуңа күрә без төзелешнең минималь кирәкле параметрларын тәкъдим итәргә, калганын архитекторлар ихтыярына калдырырга тиеш, – дип шәрехли Олег Маклаков. – Әмма мәсьәләнең икенче ягы да бар: бары тик төгәл, анык кагыйдәләр генә иҗат өчен иркенлек бирә.

Иллюстрациялар Тарихи җирлекне тотрыклы үстерү концепциясен эшләүчеләр төркеме тарафыннан бирелде

## ТАРИХЫБЫЗНЫ ТӨЗИБЕЗ

Без шәһәр үзәген шактый тыгыз урын итеп күрергә күнеккән, ә анда бушлыклар бар икән! Алар, нигездә, тарихи үзәк читләрендә урын алган. Андыйлар аеруча Болак артында– Нариманов, Тукай, Камал урамнарында күп, шулай ук Бишбалта бистәсендә, Подлужная урамында, Б кварталында... Шәһәрнең тарихи үзәк территориясенә ревизия үткәреп, проектны әзерләүчеләр файдаланылмый яткан 123 га җир таба.

Тагын бер ресурс исә Казанның нәкъ үзәгендәге – Профсоюз, Бауман, Кремль урамнарындагы йортлар арасындагы кулланылмаган мәйданнардан гыйбарәт.

Бакча божрасы фрагменты. Толстой урамы. Хәзерге вакыттагы торышы.

Өч киртә: инженер дамбасын, автомагистраль һәм тимер юлны – каршылыктан тарихи шәһәр белән Иделне бәйләүчегә әйләндерү – концепцияне эшләүчеләр алдында торган бурычларның берсе.

Әлеге эчке ишегалларын актив тормышка тарту һәм җәяүлеләр күп йөри торган урынга әйләндерү мөмкинлеген исәпкә алганда, үзәкнең үсеш потенциалы шактый зур.

Искә алынган урамнарга кагылышлы үсү-үстерү бурычлары шактый анык – аларның күләмле-пространстволы тарихи структурасын саклап калу һәм, мөмкинлек булган урында, өлешчә яңадан торгызу. Ә комплекслы яңа төзелеш күздә тотыла торган территорияләр белән нишләргә?

Концепция барлыгы 8 районны колачлый: Яңа Татар бистәсе, сәнәгать территорияләре (Пләтән, Дары, Бишбалта бистәләре), Б кварталы һәм Өченче тау районы дип исемләнгән территориядәге совет чорында төзелгән йортлар, шулай ук Чехов базары һәм Госпиталь бакчасы тирәсе, Подлужная урамы һәм «Россия тимер юллары» карамагындагы коммерция кварталы. Әлеге периферия территорияләре һәм бистәләре бик төрле. Аларны барысын да бер кысага кертеп карарга ярамый! Шунлыктан аларны аерым участокларга бүлеп эш итү турында карар кабул ителә, һәркайсы өчен анык критерийлар билгелиләр. Критерийларга төзеләчәк биналарның типларына, алардагы планлаштыру төрләренә, катлар санына (үзәкнең иң «биек» районында йортлар җиде каттан артмаска тиеш), түбәләргә, фасадларга, төсләр палитрасына карата куелган таләпләр керә. Шул рәвешле, шәһәрнең тарихи структурасына охшатып, буш участокларда төзелеш башлау мөмкинлеге туа.

– Сүз бу территорияләрдә борынгы биналарны торгызу турында бармый (тарихи кыйммәткә ия булган биналардан кала һәм аларның барлык сызымнары сакланган очраклардан тыш). Без башка

бурычны күздә тотабыз. Без массакүләм төзелеш, гадәти төзелеш өчен киңәшләр, ысуллар тәкъдим итәбез, – дип аңлата Олег Маклаков.

Тарихи контекстның күчермәсен булдыру урынына аны исәптә тотып эш итү. Концепция архитекторларга һәм төзүчеләргә нәкъ менә шуны тәкъдим итә һәм тарихи территорияне схематик рәвештә өч зона – архитектур регенерация, адаптация һәм интерпретация зоналарына бүлә. Оригиналь төзелеш сакланып калган беренче зона өчен архитектур үзгәрешләргә, эшчәнлеккә иң катгый таләпләр билгеләнгән. Икенче зонага бүген буш урыннар күп булган территорияләр керә, әмма бу урыннарның пространство структурасы турында мәгълүмат сакланып калган, димәк, аларны яңадан торгызырга мөмкин. Өченче зона – интерпретация – үзәк белән чиктәш территорияләргә кагыла, аларда элек тарихи әһәмияткә ия биналар булмаган, димәк, анда кварталлы төзелеш һәм катлар санының билгеле бер таләпләренә туры килә торган заманча архитектура үрнәкләре барлыкка килергә мөмкин.

«Сантехприбор», вертолет заводы урнашкан сәнәгать территорияләрендә дә үсеш өчен потенциал бар. Реновация, яңарту турында сүз кузгалганда, бу мәйданчыклар инде күптәннән искә алына. Үзәкнең коньяк өлешендә, «Нәфис» предприятиесе урнашкан якта, Маклаков сүзләренчә, завод-фабрикалар бик нык утыра һәм аларны күчерү турында сүз бармый. Әмма киләчәктә, бәлки, алар Мәскәү һәм Санкт-Петербург предприятиеләре үрнәгендә үз технологик процессларын оптимальләштерә, җитештерү мәйданнарын җыйнакландыра һәм җәмәгать киңлекләре өчен мәйданнар бушата алыр.

Бакча божрасы фрагменты. Толстой урамы. Проектта каралган тәкъдим.

## ЯШӘРГӘ, ЭШЛӘРГӘ, ЙӨРЕРГӘ

Якындагы 15 елда үзәктә торак мәйданнары 700–800 мең кв. метрга артачак, ә халык саны ике тапкыр күбәергә мөмкин. Планлаштыруның иң югары чиге – якынча 75 мең кеше. Шулай итеп, халык тыгызлыгы гектарына 40 кеше тәшкил итәчәк, бүген бу санның 20 кеше тәшкил итүен дә искә алу урынлы. Кунаклар өчен тарихи территорияләрне килеп-күреп китү мөмкинлегенә дә кулайлана һәм кала үзәге елына 70 млн кунак кабул итә алачак. Гомумән алганда, сүзләр бик матур, ләкин ачыклык, төгәллек булсын иде.

– Бу, күбесенчә, торак фонды, иҗтимагый һәм яшеллекле киңлекләр балансын саклау шарты белән үзәкнең мөмкинлекләрен исәпләүне белдерә, – дип сөйли Олег Маклаков. – Искә алынган 123 га мәйданда эш болайрак башланачак: 70% – яңа торак төзелеше, 20% – инде булган мәйданны тыгызлау һәм реконструкцияләү (кайдадыр өстәмә кат, янкорма төзү, кайдадыр ишегалды территорияләрен үзгәртү) һәм 10% – буш торган тарихи, иҗтимагый биналарны һәм офисларны яңадан профильләштерү. Тик кабатлап әйтәм, бу – максат түгел, ә гомуми потенциалны исәпләү. Аны исә иҗтимагый һәм яшеллекле киңлекләрне, инфраструктура, транспорт йөкләнешен исәпкә алып эшләү зарур. Девелоперлардан: «Мондый регламент белән төзләш алып барудан файда юк!» – дигән тәнкыйть сүзләре ишетелеп тора бит. Без исә үз исәп-хисапларыбыз белән раслап күрсәттек: үзәктә икътисадый эшчәнлек алып барырга була, хәтта регламентларны һәм чикләүләрне исәпкә алганда да, уңышлы инвестиция кертемнәре ясарга мөмкин. Әйе, бу – периферик зонада шап-шоп иттереп тугыз катлы

йортны күтәреп куюга караганда катлаулырак процесс, әмма монда – тарихи мохит икәнен, проектлаучы өчен шуннан да читенрәк нәрсә юклыгын аңларга кирәк.

Әмма тораклы үзәк белән кешеле, җанлы үзәк – бер үк нәрсә түгел. Аны нәкъ менә җанлы үзәк итү өчен, проектны әзерләүчеләр төркеменә, аерым алганда, социологлар һәм культурологлар кертелгән иде. Алар Казанның матди булмаган мирасын игътибар үзәгендә тота. Төп өч сорауга җавап эзләнә. Тарихи биналарда яки территорияләрдә нинди яңа эшчәнлек алып бару максатка ярашлы һәм аларны кем карап тора ала? Яңа төзелеш яки территорияне мәдәни яктан үстерү проектларында нинди кыйммәтләрне һәм принципларны саклау мөһим? Һәм, ниһаять, мондагы халыкның шәһәр үзәгенә булган юридик кына түгел, символик хокукларын да ничек исәпкә алырга?

Боларга җавап бирү өчен массакүләм сораштыру, әңгәмәләр, экспедицияләр үткәрелә. Теге яки бу урында уннарча ел яки хәтта гасырларча эшчәнлек төре үзгәрми торган урыннар билгеләнә. Казанлылар һәм кала кунакларының шәһәр үзәгенә мөнәсәбәте һәм аларның таләп-теләкләре нинди булуы ачыклана. Әйтик, сорашып белешүдә катнашучыларның 33 проценты табигатьтә ял итү урыннары җитми дип зарлана, 17 проценты үзәктә спорт объектлары күбрәк кирәк, дип саный, ә казанлыларның 15 проценты мәгариф учреждениеләрен яклый. Белгечләр алдан фаразлаганча, кешеләр Казан үзәгенең матурлыгына сокланганлыкларын, аның тарихының саклану дәрәҗәсеннән канәгатьсезлекләрен белдерә һәм парковкалар җитмәүгә зарлана...

Ә хәзер, әйдәгез, концепция гамәлгә ашырылган дип күз алдына китерик. Шәһәр нинди икътисадый нәтиҗә алачак? Хәер, хыялланып исәпләмәсәк тә мөмкин – проектны әзерләүчеләр барысын да санаган инде. Әйтик, 40 млрд сумга кадәр шәхси инвестицияләр җәлеп ителергә, туризмнан керемнәр 62,5 млрд сумга артырга мөмкин, 9 мең кеше өчен яңа эш урыннары булдырылачак, ә физик затларның керем салымы хисабына елына 1 млрд сумга күбрәк акча керәчәк. Менә шундый тел шартлатырлык нәтиҗә.

Шул ук ноктадан Н.Ершов урамының хәзерге вакыттагы күренеше.

## ӨЧ НИГЕЗЛЕ МЕГАПОЛИС

Казанлыларның борын-борыннан килгән (һәм грандиоз!) бер хыялы – Идел ярына чыгу мөмкинлеге. Төзекләндерелгән яңа Идел яр буе елга портыннан Киров дамбасына кадәр дәвам итәр, ә аннары Казансу елгасының Кремль яр буе белән тоташыр дип планлаштырыла.

– Бу, мөгаен, бөтен тарихи җирлек өчен иң колачлы вакыйгадыр, – дип саный Олег Маклаков. – Тимер юлдан гыйбарәт каршылыкны узу һәм барлык аркылы (Г. Камал, Т. Миңнуллин, Н.Чернышевский) урамнарны Иделгә чыгару – проектлаучылар өчен катлаулы сынау.

Проектны тормышка ашыру глобаль үзгәрешләр таләп итә, шулар арасында – тимер юлга караган хуҗалык корылмаларын күчерү зарурлыгы. Шәһәр өчен әлеге кыйммәтле территорияне шул рәвешле генә бушатырга мөмкин. Хәер, тагын бер катлаулы мәсьәлә бар – Зур Казан боҗрасы магистрале яр буена юл ачу өчен өстәмә киртәгә әверелергә мөмкин. Кала халкының төрле мәнфәгатьләре үзара каршылыкка киләме? Мәсьәләгә комплекслы караганда, барысын да хәл итеп була, дип ышандыра архитектор. Бу – бүген башлана торган киләчәк проекты, Россия тимер юллары белән территориядә милекне үзгәртеп кору, яңадан төзү турында сөйләшүләр башланган инде.

Себер заставасын торгызу буенча проектта каралган тәкъдим. Авторлары: С. Саначин, Т. Меженцева (күперне реставрацияләү).

Әйе, Казан – өч акватория шәһәре. Болай гына әйтү җиңел дә! Туган шәһәребез рельефы турында без ни генә беләбез соң?! Татарстан башкаласы яссы, тигез урында түгел, Кремль калкулыгыннан Казансу һәм Иделгә таба төшә барган өч террасада утыра. Аның тагын бер байлыгы – тарихи бакчалар һәм агачлыклар.

– Проблема шунда ки, шәһәр буйлап йөргәндә генә, аның табигый үзенчәлекләрен тою бик авыр, – ди җәмәгать киңлекләрен үстерү концепциясен тәкъдим иткәндә архитектор Анна Новикова. – Тау битләре буйлап менеп булмый, тарихи бакчаларның бер өлеше шәхси милек коймалары артына яшеренгән. Казандагы матур урамнарның потенциалын әле ачарга кирәк. Концепциядә моны хәлдән килгән хәтле тулырак эшләргә мөмкинлек бирәчәк берничә тәкъдим бар.

Проект авторлары тәкъдимнәренең тәүгесе – тарихи бакчалар һәм агачлыкларны 26 км озынлыктагы өч Бакча боҗрасына берләштерү. Беренчесе – Кремль тирәсендә, икенчесе – Пушкин урамы буйлап, өченчесе – Горький паркыннан башлап. Әгәр бу ният тормышка ашса, тарихи җирлектәге иҗтимагый киңлекләрнең өчтән бере диярлек Европа тарихи шәһәрләренең «яшел» стандартына җавап бирерлек дәрәҗәдә яшеллеккә күмелеп утырачак.

– Бездә йөз яшьтән өлкәнрәк биналар әллә ни күп калмады, әмма шундый озак яшәр агачлар бар ки, кайберләренең яше ике йөзнең арьягында! – ди Анна Новикова. – Агачлар һәм ландшафт да шәһәр тарихы турында истәлекләр саклый, һәм без шул табигый үзенчәлекләрне саклау һәм үстерүгә кагылышлы идеяләрне тәкъдим итәбез.

Җәяүләп тәпили-тәпили генә кала тарихы белән танышу – бихисап казанлыларның күптәнге хыялы. Шул ук вакытта аларның 26 меңе мактанып куя алачак: үзләре яшәгән өйдән Бакча боҗраларына кадәр килеп җитү өчен, күп дигәндә, 20 минут вакыт кирәк!

Себер заставасы. Э. Турнерелли. Литография, 1839.

Хәзерге вакытта шәһәр үзәгендә барлыгы 18 парк һәм сквер саклана торган ландшафтлы объектлар булып санала. Алар арасында Ленин бакчасы, Черек күл бакчасы, Эрмитаж бакчасы һ.б. бар. Чынлыкта исә тарихи җирлек территориясендә 55 яшеллекле территория бар, тик алар әлегә мондый статуска ия түгел.

Әйе, яңа яшеллекле мәйданнар булдыру турында сүз бармый – алар бар инде! Уңайлы итәргә, төзекләндерергә һәм җәяүле юллары белән берләштерергә генә кирәк. Шул чакта Казансу ярыннан Пушкин һәм Татарстан урамнары буйлап Иделнең үзенә кадәр барып җитәргә мөмкин булачак.

Фото: Булат Рахимов

# «БУ МУЗЫКА МӘҢГЕ БУЛАЧАК...»

**Автор:** Ольга Туманская

**Музыка туган телне һәм гореф-гадәтләрне саклауның ышанычлы ысулы була аламы? Ничек кенә әле! Хип-хоп, электро, фолк, рок... һәм, белмәссең, бу эштә бәлки андеграунд эстрададан уздырып та җибәрер?**

Фото Рөстәм Нурисламовның шәхси архивыннан

«Үпкәләмә, яме» җырына клипны социаль челтәрләрдә беренче атнада ук 300 мең кеше караган. Аны шиналар складында нибары бер кичтә төшергәннәр. «Үпкәләмә, яме» – K-RU (Рөстәм Нурисламовның) яңа «Милләт» альбомындагы треклардан берсе. Бу рэперның тавышы тәүге тапкыр «нуленче» еллар уртасында, SNICKERS URBANиЯ урам культурасы яшьләр фестивалендә колакка чалынган иде. Эмин һәм «Каста» белән илһамланган, фортепиано һәм баян буенча музыка мәктәбен тәмамлаган үсмер ул чакта әле рэпны русча укый. Бүген исә ул: «Нәкъ менә рэп миңа татарчаны яхшырак өйрәнергә булышты», – ди.

– Мин татар гаиләсеннән, өйдә без татарча сөйләшәбез. Көнкүрештә бит ул гадирәк, әмма яхшы текст язарга җитәрлек түгел.

Һәм K-RU кулына сүзлек ала, эти-әнисеннән киңәш сорый, филолог дусларын җәлеп итә, китап һәм журналлар укый... Рөстәм әйтүенчә, башлап җибәргәндә барлык ысуллардан да файдалану яхшы. Беренче текстын язарга аңа татар рэперы Шәкүр булыша. Татар телендәге икенче трек исә инде хитка әйләнә.

– Мин үземнең татар музыкасына ниндидер яңалык кертә алуымны, үз стилем булуны аңладым. Юк, минем аудиториям тараймады, киресенчә, артты. Мине русча тыңлап өйрәнгәннәр дә беркая да югалмады, алар минем татарча текстларымны,



мәсәлән, французча рэп кебек кабул итте. Хәзерге заманда чикләр җуела, алар белән бергә гореф-гадәтләр дә югала – халыклар үзенчәлеген югалта. Мин яшьләр кызыгып тыңларлык татарча музыка язарга тырышам. Машиналарында тавышны бар куәтенә ачып, шәһәр буйлап җилдерергә оялмаслык булсын. Ана телен онытмасыннар, үзара татарча сөйләшсеннәр иде минем яшьтәшләрем дә.

Мондый яшьләрнең иҗаты чыннан да туган телне сакларга һәм үстерергә булышырмы икән? Бу соравымны мин Yummy Music беренче татар индилейблын оештыручы Ильяс Гаффаровка юллыйм.

– Иң әүвәл, ул ана телен хәзерге заманда кулланырлык өлкә булдыра, – ди ул. – Теләсә нинди яшь кеше контекст эчендә яши. Музыкаль аудитория заманча музыкаль платформалар контекстында яши, заманча музыкаль гаммәви мәгълүмат чараларын һәм блогерларны укый. Мондый аудиториягә дә контент кирәк, рус телле яки инглиз телле музыканы куллану белән беррәттән, аның татар телендә җырлый торган модалы музыкаль төркемнәр һәм башкаручыларны тыңлау, социаль челтәрләрдә күзәтү, концертларына йөрү мөмкинлеге дә булырга тиеш. Алай гына да түгел, башка телләрдәге сыйфатлы музыканы тыңлаучы меломаннар ана телендә язылган продуктны югарырак та бәяли, чөнки ул аларга музыкаль жанр җәһәтеннән генә түгел, бәлки тел ягыннан һәм башкаручы күтәргән темалар җәһәтеннән дә якын.



Фото: Алексей Воробьёв

### ИЛҺАМЛАНДЫРУЧЫЛАР

Бар нәрсә дә табигый үсештә, дип инандыра безне Ильяс Гаффаров. Заманча татар музыкасында мондый үсеш, мәсәлән, тулаем Россия, Украина яки Казахстандагыга караганда бераз соңрак башланган. Әлеге процесс якынча «нуленче» еллар уртасыннан, ITTIFAQ, ALQANAT, Mubai кебек аерым төркемнәр һәм башкаручыларның татар телендә дә сыйфатлы рэп, рок яки фьюжн иҗат итеп булуын үз үрнәкләрендә күрсәткәннән соң күзәтелә. Әлеге заманча бәйсез татар артистлары плеядасын исә Австралиядән world music җырчы Зуля Камалова, «Сак-Сок» фолк-рок төркеме, фин татарларының Başkarma фолк-рок төркеме кебек инде легендага әйләнгән шәхесләр илһамландырган. Алар заманча музыка өлкәсендә кыю эзләнүләргә нигез салган, 2000нче елларда исә алардан аерым музыкаль агымнар һәм субкультуралар үсеп чыккан. Бүген исә, үз чиратында, татар яшьләре бергәлекләре, яшь язучылар, дизайнерлар, клипмейкерлар алардан илһам ала...

### ГАСЫРЛАР АША КҮПЕР

Миңа «It'smore» җыры ошый. Мин аны берничә тапкыр рәттән тыңлыйм. Электрон яңгыраш башта сихерле. Үзенә ияртә, аннары минем йөрәк тибешемне ешайта. Мин аңарда үз йөрәгемнең тибешен ишетәм, ә инглиз сүзләре тезмәсендә ниндидер таныш гыйбарәләр ишетелгәндәй була... Һәм менә кабатлана торган авазлар бөтенләй инглизчә булмаган «Очып китмә» гыйбарәсенә әйләнә.

3 сентябрьдә Австрия җырчысы, мульти-музыкант, битбоксер һәм видеограф AYGYUL үзенең социаль челтәрләрдәге сәхифәләрендә тиздән дөнья күрәчәк «It'smore» синглының тышлыгын урнаштырды. «Бу җыр – вакыт һәм пространствода коллаборация: кечкенә татар авылыннан чыккан татар халык көе, еллар һәм буыннар аша сәяхәт итеп, 2020 елда минем Венадагы студиямә килеп ирешә, анда үзенең яңа йортын тапты һәм минем электро-поп-битларыма кушылды», – дип язды җырчы. Заманча, европача яңгыраучы синглга AYGYUL үз ватаны өчен берьюлы берничә «сәлам» керткән – баярак искә алган «Очып китмә» гыйбарәсен һәм моннан 100 елдан артык яздырылган иске пластинкадагы татар халык җыры «Сандугач» сэмплларын бик оста кушкан. Җырның темпы минутына 116 тибешне тәшкил итә. «Бу очраклылык түгел, бу – мин туып-үскән Татарстан коды», – дип шәрехли Айгөл. Шул рәвешле, аның җыры төрле буыннар арасындагы бер гасырлык күпергә әйләнгән. Әлеге сингл-Yummy Music лейблының музыкантлар һәм Г.Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм сәнгать институты белән бергә башлаган «Бакыр» проектының беренчесе. Революциягә кадәр үк Казанда чыгарылган бәһаләп бетергесез бакыр пластинкалар нәкъ менә институт фондларында сакланган да инде. Әлеге бакыр кисәкләре – татар халык көйләре һәм авторларның музыкаль әсәрләренең беренче документаль язмалары.

– Аларның яңгырашы бик кызыклы һәм үзенчәлекле – ни дисәң дә, бу бит музыканы механик юл белән яздыру ысулы. Бу татар музыкаль әсәрләренең тавыш форматында сакланган тәүге чыганагы, – ди Ильяс

Фото: Юлия Бидер

Гаффаров. – Безне әлеге пластинкалар илһамландырды. Без аларны бик яхшы сыйфатта санлаштырдык һәм безнең электрон музыкантларыбыз белән бергә заманча музыкаль әсәргә әйләндердек, аларны бер җыентыкка туплап, санлы вариантта да, пластинка һәм дискларда да чыгарырга хыялланабыз. Плейлистны исә шулай төзергә ниятлибез – кеше башта оригинальны, аннары аның йөз елдан соңгы интерпретациясен тыңларлык булсын. Егерменче гасыр башы белән егерме беренче гасыр башы музыкаль мирасы арасында менә шундый күпер салыначак.

Сүз дә юк, бу инде яңалык түгел, Уфадан Марат Татурас эмбиент белән курай яңгырашын берләштергән иде инде. Яисә Россиядәге иң йогынтылы этнографик лейблларның берсе – Нальчиктан Ored Recordings: традицион музыка башкаручыларын эзләп, алар иң ерак авылларга барып җитә, аларны яздырып кайтып, әлеге «консервланган» культурадан көндәшлеккә сәләтле заманча продукт ясый. Алар барысы да Казанга TAT CULT FEST яңа татар мәдәнияте фестиваленә чакырылган иде, анда үзләренең идеяләре белән безнең җирле музыкантларны да кызыктыра алдылар. Ә инде яшь энтузиастлар үз милли мирасларын актуальләштерү өстендә эшли икән, димәк, ул саклау урыннарында тузан җыеп ятмый, ә яшәвен дәвам итә.

Кабат «It'smore» синглын исемә төшереп, мин уйга калам: ә бәлки, вакытта гына түгел, фәзада да буыннар һәм мәдәниятләр бәйләнешен ничек булдырырга, дигән сорауга җавап нәкъ менә шулдыр? Яшьләр йөрәгенә нәкъ менә шул ачкыч, «бүрәнкәдер» – аның аша замананың котырган ритмнары белән бергә әлеге йөрәкләргә күп гасырлык мәдәният һәм традицияләр үтеп керә. Күптән булып онытылганнар чынга әйләнә һәм ерак Венадан минутына 116 тапкыр тибеп бөтен дөньяга тарала...

## «БУ ШУЛАЙ ЭШЛИ ДӘ!»

«Бу фестивальгә эләгү турында хыялланганнар – һәм инде алар биредә!»– дип игълан итә Казанның Juna инди-фолк төркеме музыкантларының сәхнәгә чыгуын Борис Гребенщиков.

– Борис Борисович – без бик күптәннән бирле бару турында хыялланган «Части Света» фестиваленең арт-директоры, – дип сөйли Juna төркемендә укулеледә уйнаучы Александра Мостафина. – Анда ничек килеп эләгүебезне без әле һаман да аңламыйбыз. Август азагында фестивальне оештыручылардан хат алдык, алар БГның безне сайлап алуын хәбәр итте. Башта үз күзебезгә үзебез ышанмадык – мондый хәлнең булуы мөмкин түгел иде чөнки. Бәлки, безне Петербургтагы «Музыка мира» фестивален оештыручылар тәкъдим иткәндер – онлайн тавыш бирүдә җиңеп чыгып, без быел аларның сайлап алу турын үткән идек.

Juna төркеменең тарихы озын – музыкага гашыйк егет-кызлар КФУда укыган чакта ук берләшкән булган. Нигездә университетта үткән чараларда чыгыш ясаганнар. Татар теленә исә очраклы гына кучкәннәр, дип әйтергә дә була.

– Без бик тынгысыз – бөтен фестиваль, конкурсларда катнашырга тырыша идек, – дип сөйли төркемнең вокалчысы Ания Фәйзрахманова. – Менә бервакыт «БикаФест» яшьләр музыка-поэзия фестиваленең конкурсантлар эзләвен күрдек. Катнашырга булдык. Әмма татар җырын әзерләргә кирәк бит! Чит кеше трегын (ул Мубай җыры булып чыкты, безгә бик ошады) алып, ул чактагы состав – джембе, клавишлар һәм укулеле – белән башкарудан «акыллырак» нәрсә уйлап тапмадык. Һәм, беләсезме, халыкка ошады, үзебезгә дә ошады – шуннан башланып китте инде!

Һәм менә алар инде БГ фестивалендә чыгыш ясый, Казанда исә үзләрен күптән таныйлар инде. Яңа альбомнарын Татарстан башкаласында тәкъдим иткәннән соң, Мәскәү, Петербург, Уфа, Екатеринбург кебек зур шәһәрләрдә дә чыгыш ясарга планлаштыралар...

...Өч музыкаль сәхнә, дизайн-маркет, арт-объектлар, хореографик сәхнә һәм фудкорт – Казанда өченче тапкыр TAT CULT FEST фестивале үткәрелде. Беренче тапкыр уздырганда, публиканың игътибарын локаль музыкантларга җәлеп итү өчен, фестивальне оештыручыларга аның программасын чит илләрдән килгән йолдызлар белән «ныгытырга» туры килгән иде. Быел исә инде чит ил хедлайнерларыннан башка да ерып чыканнар – җирле башкаручыларны тыңларга көн саен 40 меңләп кеше килгән. Чыгыш ясаучылар арасында Juna да булган.

– Без татар телендәге локаль продуктны тыңлау һәм мөмкин кадәр күбрәк таратуның җәмгыятебез һәм медиабазарның табигый ихтыяҗына әйләнүен телибез, – ди Ильяс Гаффаров. – Әмма ул заманча, бәйсез һәм көндәшлеккә сәләтле продукт булырга тиеш. Нәкъ менә аны иҗат итү һәм популярлашты-

Фото: Алексей Воробьёв

ру процессында кешегә үз туган телендә сөйләшү ихтыяҗын сакларлык тел контексты туа да инде.

– Минем өчен бу шулай эшли дә! – дип ышандыра Juna төркеменнән Ания. – Җырлар миңа татар телен онытмаска, тагын да камилләштерергә булыша. Хәтерлисезме, балачакта, инглиз телен өйрәнгәндә, җырлар иң нәтиҗәле чаралардан берсе иде?!

## МУЗЫКАГА ӨСТӘМӘ БУЛАРАК...

«Бәхеткә, татар музыкасы миңа бала чагымнан таныш. Ул минем асылыма сеңгән, дип әйтеп була. Бу бик мөһим. Балаларның туган телдәге җырларны бик кечкенәдән ишетеп үсүе мөһим. Ихтимал, бу һәркемгә дә хас түгелдер, әмма минем өчен ана теле һәм татар музыкасы ватанымнан еракта бик мөһим булып чыкты».

Зуля Камалова, татар чыгышлы Австралия җырчысы, – Казанда еш кунак һәм татар җырын дөньяда иң танылган башкаручылардан берсе. Ана теленең чит илдәге популярлыкка берничек тә комачауламавын үзенең иҗаты белән дәлилләп, нәкъ менә ул Татарстандагы күп кенә музыкантның илһамландыручысы булып тора.

– Безнең заманда һәр музыка юнәлешенең үз урыны бар, – дип сөйли ул. – Татар диаспорасыннан тыш, мине яхшы музыка яраткан башка кешеләр дә тыңлый. Ихтыяҗ дәрәҗәсе исә эшне алга җибәрү өчен никадәр тырышлык куюга бәйле. Аңлашыла ки, чагыштыру бик үк гадел түгел, әмма безнең заманда, ресурслар булса, популяр медиа шәхескә әйләнү әллә ни катлаулы түгел.

– Заманча татар музыкасының үз өстенлеге бар, – ди Ильяс Гаффаров. – Аңарда әле этнографик мәгънә, «подтекст» сакланган. Шунлыктан аның белән кызыксыну Россия музыкаль индустриясе кысалары белән генә чикләнми.

Сүз уңаенда, моңа мисаллар да бар инде. Чехия, Германия, Дания – бу илләрдә Juna музыкантларының килүен көткәннәр иде. Планнарны пандемия генә бозды. Алар турында чит ил меломаннары кайдан белгән соң? Интернет – бүген бу, мөгаен, популярлыкны арттыруның чикләрне белми торган иң шәп чарасыдыр. Ильяс Гаффаров, Juna музыкасы Европа сәхнәсе контекстында искиткеч гармонияле яңгырый, дип саный.

– Европада хәзер теләсә нинди этник азчылыкка аеруча игътибар бирелә. Мәсәлән, Финляндия һәм Чехия мегаполисларында яшәүчеләр татар бергәлегенә бик хәерхаһлы. Әлбәттә, безнең музыка бары тик сыйфатлы яңгыраган очракта гына аларның игътибарын җәлеп итәчәк.

Әмма биредә, ватаннарында да, талантлы музыкантларның иҗаты татарча белмәүчеләр өчен дә кызыклы. Шул ук TAT CULT FEST фестивале рус телендә сөйләшүче меломаннарның да игътибарын яулады. Алай гына да түгел, Ильяс Гаффаров әйтүенчә, алар тыңлаучыларның яртысын диярлек тәшкил иткән.

– Бу публика заманча татар музыкасына битараф түгел, ул үзен әлеге процессның бер өлеше дип тоя. Бирегә шулай ук сөйкемле яшьләр арасында рәхәтләнеп ял итәргә теләүчеләр дә җыела.

– Музыканың телне сакларга сәләтлеме-юкмы икәнен без берникадәр вакыт үткәч кенә белә алырбыз. Әмма аның кызыксыну тудыра алуы – бәхәссез! Һәр концерттан соң безгә татарча белмәүче кешеләр дә яза – текстларны, тәрҗемәләрен сорыйлар. Кайберәүләр татар теленең яңгырашын бездән беренче тапкыр ишетә – бу гадәттә Татарстаннан читтә күзәтелә, – ди Juna төркеменнән Саша Мостафина.

Сүз уңаенда, үзчикләүнең иң актив айларында Yummy Music каталогының стримнары саны хәтта йөз меңгә җиткәләгән. Димәк, заманча татар треклары релизларын тыңлау өчен, кешеләр максатчан гамәлләр кылган. Аларны беркем дә бернәрсәгә дә мәҗбүр итмәгән – бу аларның үз хаҗәте һәм ихтыяҗы булган.

Ерактан яхшырак күренә, диләр. Альтернатив татар музыкасын Австралиядәге Зуля Камалова ничек күзаллый?

– Аның ничек үсүен күреп, мин бик сөенәм. Мәйнстрим белән мин бик кызыксынмыйм. Икесендә мин чыгыш ясаган өч TAT CULT FEST фестивале әле алда эшләнәсе эшләрнең шактый булуын күрсәтте. Әмма иң мөһиме – татар телен һәм заманча татар мәдәниятен үз иткән энергияле, дәртле яшьләр бар, алар моңа йөрәген дә, җанын да кызганмый.

Яр Чаллы
90.2 FM

Казан
93.1 FM

Тәртип радиосы

ТАТАРСТАНГА
«ТӘРТИП»
КАЙТА!

Реклама 12+

# игелекле эшләр

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

**Бу санда тәкъдим итәбез:**

Югалганнарны **ничек** табарга һәм коткарырга

Ятимнәр **ничек** ата-ана назын таба

Кондуктив балалар бакчасы **кайда** төзелә

Мингол Галиевне **ничек** консерваториягә алганнар

# НАТА СМИРНОВАНЫҢ 365 ТАПКЫР КОЯШНЫ ОЗАТУЫ

*Һаваларда – көз сулышы*

Ната Смирнова фотолары.

**Ничек уйлыйсыз, «Татарстан» фотографлары эштән бушаган арада нишли? Алар... күк йөзен фотога төшерергә ярата. Кемдер – таң атканны, ә кемдер – кояш баешларын, үзенең режимына карап. Ната Смирнова кояш баешларына ияләшкән, чөнки йокларга соң ята – фотографияләрне эшкәртә. Компьютердан ял итәр, һава сулап алыр өчен балконга чыга – ә анда... әнекәйгенәм, кояш шундый итеп байый! Йөгереп кереп фотоаппаратын ала да һәм менә күкнең бөтен матурлыгы – гасырлар кесәсендә.**

**Ел саен Натаның «кояш баешлары флешкасы» 365кә арта! Югыйсә иң яхшы дигәннәрен биш яки унны сайлап ал да тынычлан, фотограф бит инде! Әмма һәр көннең кояш баешы кабатланмас шул! Аларның һәркайсы – безнең тормышта бердәнбер.**

**Көзнең могҗизага тиң кояш баешларын «Татарстан» журналы көндәлек мәшәкатьләр һәм бәйрәмнәр ыгы-зыгысында күрми-сизми калганнар өчен бүләк итә: һавадагы көз сулышын тоеп калсыннар дип...**







Казан. Космонавтлар урамы, 18 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт дивары. Авторлары: Caktus һәм Maria, 2019 ел (Италия)



Фото: Александр Ефремов

# МОНУМЕНТАЛЬ РЕНЕССАНС

**Автор:** Ксения Сёмина

**«...Карт образындагы һөнәрче юнып-чокып милли бизәк төшерү белән мәшгуль, аның бизәге исә салмак кына туган як табигатенә кушылып китә. Әүвәлге буыннар киләчәкне әнә шулай күзаллаган, шул хыял җимешләрен хәзер безгә татырга туры килә...», – дип аңлата Казанның үзәк базары каршындагы КФУ бинасына ясалган яңа муралын Татарстанның күренекле рәссамы, стрит-арт остасы Рөстәм Сәлимгәрәев (QBic).**

**Бу – 2020 елның җәендә рәссамның Татарстан башкаласындагы, ким дигәндә, өченче колачлы эше. Гомумән алганда, соңгы берничә елда Казанда мураллар саны шактый артты. «Татарстан» редакциясе моны ничек аңларга икәнен ачыкларга тырышты.**

Казан. Бондаренко урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт дивары. Автор: Pixelpancho (Италия).

## РОБОТ НӘРСӘ ТУРЫНДА СӨЙЛИ?

«Мураль - дивар сынлы сәнгате, монументаль рәсем сәнгате әсәре» - Ожегов редакциясендә 1992 елда чыккан аңлатмалы сүзлектә муралга шундый билгеләмә бирелә. Бүген бу сүздә нечкәлек билгесе куелмый. 2012 елда узган «Like It. Art» стрит арт һәм граффити халыкара фестивале, бер әңгәмәдәшемнең сүзе белән әйткәндә, «рөхсәт белән бәреп керү»гә әйләнә. Россия, Украина, Польша, Италия, Германия, Испания, Сербия һәм Бельгиядән килгән рәссамнар ул чакта өч дистәгә якын Казан объектын бизи. Аларның күбесе хәзергәчә сакланган һәм хәтта сигез елдан соң да актуаль күренә. Шуңа күрә «мурал» мәсьәләсен без шул вакытта ясалган картиналарның берсе аша өйрәнә башладык. Италия рәссамы Пиксельпанчоның «Елизавета. Һәм без очучы булачакбыз» муралында кулларына самолет модельләре тоткан килеш болында басып торган робот һәм пионер сурәтләнгән. Әлеге мурал Бондаренко урамы, 20 нче йорт адресы буенча урнашкан йорт диварын бизи. Арт-объектның җәмәгатьчелек тарафыннан ничек кабул ителгәнен без нәкъ менә белешергә тырышып карадык.

– Бу бер конкурс иде, төрле чит ил рәссамнары рәсемнәр ясады. Әнә теге соңгысын бөекбританияле ясаган, шуңа күрә анда «Елизавета» дип язып куелган, – дип аңлата безгә 18 яшьләр тирәсендәге кыз, Пиксельпанчо муралына таба ишарәләп.

– Сезгә бу мурал ошыймы?

– Әйе инде, кызык кына.

– Туристларны кызыксындырырга мөмкин, – дип өстәп куя көтмәгәндә кызның юлдашы.

Чираттагы респондентыбыз – урта яшьләрдәге хатын-кызның тел төбендә шик-шөбһә, ышанып бетмәү хисе тоемлана:

– Нигездә, миңа йортларга рәсемнәр ясау идеясе ошый. Барысына да рәттән ясарга түгел, әлбәттә. Билгеле бер урыннарда булса, кызык. Әлеге граффитига килгәндә исә, ул миңа ошамый. Мин монда ни сурәтләнгәнен аңламыйм. Мөгаен, ниндидер фэнтези яки әкияти стильдәге сурәт яхшырак булыр иде. Әмма безнең районны начар белүчеләргә кая ничек барырга икәнен шушы рәсемнәр ярдәмендә аңлату бик җайлы.

Аннары без, үз тәэсирләре белән уртаклашуны сорап, «Елизавета» фотосын дусларга һәм танышларга җибәрә башлыйбыз. «Бу бит Туполев һәм ул самолетлар төзергә өйрәткән Советлар Союзы аллегориясе», – дигән җавап килә берсеннән. Икенче хәбәрдә: «Бу сурәт дөньяның баштанаяк үзгәрүе турында. Элек кешеләр роботларны өйрәткән, хәзер роботлар – кешеләрне. Авиатөзелеш районында «Елизавета»га лаеклы бәя бирерләр иде», – диелә.

– Моны Дамир Бозик ясады, ә без аны, нигездә, төрле психоделик рухтагы «музей төннәре»ндә катнашучы буларак беләбез, – ди Рәдиф Кәшапов.

## УНИКЕ КАТЛЫ МӘГЪНӘ

– Бервакыт таныш егетләр Миллениум күпере астында Боб Марли сурәтен ясарга теләүләре турында сөйләде. Мин аларга кухняда утырып Джимми Хендриксны тыңлаган Фатыйх Әмирхан белән Виктор Цойны ясарга киңәш иттем. Менә бу кызык булыр иде, – ди Yummy Music лейблы креатив директоры, журналист һәм экскурсовод Рәдиф Кәшапов.

Без Татарстан урамындагы 64 нче йорт янында басып торабыз. Аның диварындагы муралга Тукай портреты төшерелгән. Янәшәдә генә – җиләк-җимеш сата торган ларек һәм «Ключ здоровья» су сату автоматы. Кешеләр безнең муралны каравыбызны да, муралның үзен дә кызыксынып күзәтә.

– Моны Дамир Бозик ясады, ә без аны, нигездә, төрле психоделик рухтагы «музей төннәре»ндә катнашучы буларак беләбез. Аның стиле – төрле фантастик мотивларны катнаштыру. Биредә Тукай да ничектер әкияти булып чыкты. Миңа калса, бу – бик яхшы образ. Немец галиме Михаэль Фридерих үз монографиясендә* төрле белгечләрнең Тукай образын ничек үзгәртүе турында язган: сәяси контекстка карап, шагыйрь әле исламга мәдхия җырлаучыга, әле халыкны яклаучыга, әле буржуазия вәкиленә әйләнеп куйган. Гомумән, шундый фикер дә яшәп килә, имеш, безгә билгеле Тукай портреты чынлыкта һич тә аныкы түгел, чөнки шагыйрь ул кадәр матур ир-егет булмаган, – ди Рәдиф.

– Ә аның бераз пропорциональлекне бозып сурәтләнүе сине борчымыймы? – дип сорарга кирәк табам.

– Ул чакта берни дә ясамыйча, фото гына да элеп куярга булыр иде, – дип каршы төшә Рәдиф. – Һәйкәлләр алар янында хәтер көннәре үткәрү өчен кирәк. Ә мураллар – алар янында медитацияләүгә бирелер өчен. Автоматтан су сатып аласың да медитация башлана. Миңа калса, Бозик үз бурычын үтәде. Мондый сурәтләр күңел төпкелендәге бер кылны тартып куярга тиеш. Бездә бит барысы да агитплакатлар рухында ясала. Ә мондый сурәтләрдәге героизация күренешне ничектер читкә этәрә. Мин Җәлилне Моабитнең җәза урыннарында түгел, ә ялда вакытында күрергә теләр идем. Ник дигәндә, Моабит турында күпләр белә, ә Җәлилнең тормышта нинди булганлыгын белүче аз.

Рәдиф сөйләгәнчә, тарихчы һәм ислам белгече Альфрид Бустанов тикшеренүләре нәтиҗәсендә Әлмәт рәссамнары Ризаэтдин Фәхретдин сурәтләнгән үзенчәлекле мурал концептын булдыруга ирешкән.

– Анализ – ул һәрвакыт яхшыга гына. Ул күбрәк булсын иде әле. Әгәр син йорт кадәр зур сурәт ясыйсың икән, аның мәгънәсе дә шулкадәр үк булырга тиеш, – ди Рәдиф. – Менә Хәйдәр Бигичев турында сөйләп, күп нәрсә ясарга мөмкин. Аның шәхесе турында, рухи травмасы һәм катлаулы язмышы турында, гомумән, тулы бер байопик төшерергә була.

– Ә туристлар аңлармы?

– Әгәр бу (һәм бу гына түгел, ә гомумән, мохит) җирле халык өчен эшләнсә, туристларга да кызык булачак. Хәтта ниндидер «шаккатыризм» өчен дә җаен табарга була. Мәсәлән, «Амур» кунакханәсен бөтен тулысынча Тукай рәсеме белән бизәргә мөмкин.

* Фридерих М., «Габдулла Тукай как объект идеологической борьбы», Казань, Татарское книжное изд-во, 2011.




– Сыйфатлы мурал булдыру өчен кирәкле ике төп нәрсә – текә рәссамнар һәм сурәт төшерелергә тиеш урын белән мөмкин кадәр күбрәк бәйләнеш, – дип үзенең фикерен белдерә Антон Хитров.

## БЕЗ КӨТМӘГӘН ЕЛМАЮ

– Россиядә урам сәнгатенең дәрәҗәсе әллә ни югары түгел. Берлинда, әйтик, берәр танылган рәссамның муралы күчемсез милек бәясен арттыра. Бездә түрәләр моны сәнгать һәм шәһәр йөз-кыяфәтенең бер өлеше буларак түгел, ә модалы вак-төяк дип кабул итә, – дип саный журналист Антон Хитров. Без Бауман урамы уртасында басып торабыз. Кирәк-ярак кибетләр һәм кафелар өстендә – иреннәрен селфи төшәр өчен бөрештереп куйган Мона Лиза сурәте. Без нәкъ менә шушы мурал турында фикер алышырга җыелдык.

– Сыйфатлы мурал булдыру өчен кирәкле ике төп нәрсә – текә рәссамнар һәм сурәт төшерелергә тиеш урын белән мөмкин кадәр күбрәк бәйләнеш. Арт-объектның теге яки бу урынга мөнәсәбәте бик мөһим. Биредә яшәүче һәм эшләүче кешеләр өчен мурал ярдәмендә өстәмә мәгънә җиткерелә. Әгәр дә Бишбалта бистәсендәге бетон диварларга диңгез төеннәре сурәтен төшерсәк, алар халыкка бистә тарихы турында хәтерләтеп торачак. Кайчандыр кораблар төзегән җирдә яшәвең үзе бер горурлык бит, – дип үз фикерен белдерә Антон. – Моннан тыш, бу төр символлар кунакларга әлеге урынны аңларга һәм истә калдырырга булыша. Ивановода конструктивистик рухтагы вокзал төзекләндерелдә, аның архитектурасын саклап калдылар. Вокзал холлына туку станогы куелды. Аны тотып-капшап карарга була. Син шунда ук сүзнең ни хакында барганын аңлыйсың.

Безнең артта да, алда да халык Мона Лиза фонында фотога төшә. Мин шөкәтсез поролон атлар кайчан килеп чыгар инде дип көтәм, тик алар күренми.

– Урам сәнгате әйләнә-тирә мохит җитәрлек дәрәҗәдә «сөйләшми» торган урыннарда – йокы районнарында, сәнәгать зоналарында, тимер юлларда барлыкка килә. Анда мурал ориентир булырга, ниндидер җирле проблеманы хәл итү өчен ясалырга мөмкин. Ә без хәзер – мәгънәләргә бай тарихи үзәктә басып торабыз, тулаем караганда, бу – стрит-арт өчен кулай урын түгел. Тик әлеге сурәтнең төп проблемасы – аның локациягә, ясалган урынына бәйләнеше юклыгында. Бауман урамы һәм Мона Лиза бер-берсенә ничек бәйләнгән? – дип дәвам итә Антон. – Моннан тыш, биредә рәсемнең сыйфатына карата да сораулар күп. Әгәр син шедевр әсәрне күчереп ясыйсың икән, бәлки аны үзенчә төшенеп карарга я булмаса, күчермәне сыйфатлы итеп ясарга кирәктер. Урамны ничектер көтелмәгәнрәк, кызыграк итәсе урынга, без аны тагын да күңелсезрәк, гадәтирәк һәм тапталганрак итәргә маташабыз. Менә дигән үрнәк – Әлмәт проекты. Казан да җентекле уйлап эш итүгә лаек. Һәм моны монда сәяси ихтыярга гына сылтап калдыру дөрес булмас.

– Ул вакыттан соң күп нәрсә үзгәрде. Әмма Дәрвишләр бистәсенең йөзе элеккечә кала бирә – «сталинка»лар, «хрущевка»лар, завод, мәдәният йорты. Кыз сурәтенең ни аңлатканын әйтү кыен. Анысы – өметле киләчәктер, дип ышанасы килә, – ди Динә Әхмәтова.

## ОПТИК АЛЛЮЗИЯ

– Монументаль сәнгать һәрвакыт тышкы шәһәр мохитенең бер өлеше булды. Күптән түгел совет чорында ул витражлар һәм мозаика панноларыннан гыйбарәт иде. Хәзер мондый әсәрләр иҗат итә алырлык осталар калмады диярлек. Бу традицияне мураллар дәвам итә, – ди Татарстан сынлы сәнгать дәүләт музееның баш фәнни хезмәткәре – милли сәнгать буенча директор киңәшчесе Динә Әхмәтова. – Казанда һәм республикада кызыклы, игътибарга лаек рәссамнар бар. Әмма әлегә бездә сыйфатлы эшләр ничектер тәртипсезрәк рәвештә туып тора. Ә менә Әлмәттә шундый проектны тормышка ашыруда бик шәп тәҗрибә бар. Тикшеренүчеләр төркеме берничә ай дәвамында җирле мәдәниятне, фольклорны, заманча көнкүрешне өйрәнгән. Шуның нигезендә мураллар өчен сюжетлар эшләнгән. Хәзер алар 20 гә якын, һәм проект әле дәвам итәчәк кебек. Мондый инициативалар – шәһәр һәм республиканың пиар-кампаниясенә бик зур өлеш кертә. Андый проектлар күбрәк булсын иде.

Динә Әхмәтова Дәрвишләр бистәсендә туып-үсә һәм шунда яши. 2020 елда бу микрорайонда Себер рәссамы Василий Каптырев иҗат иткән мурал янына безнең белән барып кайтуын сорыйбыз.

«Мин үз алдыма ниндидер фәлсәфи мәгънә тудыру яки хәзерге җәмгыятьнең иң кискен социаль проблемаларына кагылу бурычын куймыйм. Киресенчә, зур шәһәр ритмында күренмичә, тоелмыйча калган вакыйгаларга яки мизгеллек хәл-очракларга игътибар юнәлтергә телим», – диде Каптырев бер әңгәмәсендә. Бинаның ян диварында без яшеллек һәм төрле зурлыктагы колонналар фонындагы кыз сурәтен күрәбез. Ул кулына кечкенә агач өй тоткан. Бу йорт 30 нчы елларда Дәрвишләр бистәсенә нигез салган эшче бараклар образы кебек тоела.

– Сугышка кадәр ул шәһәр тибындагы бистә иде. Аннары бирегә Ленинград заводы эвакуацияләнә, ә завод белән бергә 1,5 меңгә якын белгеч тә килә. Шуңа күрә кызның уң ягындагы ростралы колонналар шул чорны символлаштыра булса кирәк, – дип шәрехли муралны Динә Әхмәтова. – Икенче колонналар исә, мөгаен, озак еллар районның йөрәге булып торган мәдәният йортын чагылдырадыр. Совет чорында Дәрвишләр бистәсендә нигездә интеллигенция яшәде. Мәдәният йортына кызыклы кешеләр килә иде. Ул вакыттан соң күп нәрсә үзгәрде. Әмма Дәрвишләр бистәсенең йөзе элеккечә кала бирә – «сталинка»лар, «хрущевка»лар, завод, мәдәният йорты. Кыз сурәтенең ни аңлатканын әйтү кыен. Анысы – өметле киләчәктер, дип ышанасы килә.

# АВИАТҮГӘРӘКТӘН ДӘҮЛӘТ ЗАКАЗЫНА КАДӘР

**«Татарстан» һәрвакытта да Татарстан сәнәгатенең легендар коллективлары һәм хөрмәткә лаек эшчеләре турында рәхәтләнеп сөйли. Бүген – Валерий Побежимов җитәкчелегендәге «ЭНИКС» АҖнең югары класслы белгечләре, алар предприятиегә бик яшь көенә, үзгәртеп корулар чорында авиамодельләштерү түгәрәгеннән килгәннәр, ә бүген дөньякүләм дәрәҗәдәге пилотсыз оча торган аппаратлар җитештереп, илебезнең «оборонка»сы сагында торалар.**

Генераль директор – баш конструктор Валерий Побежимов белән икътисад һәм финанс мәсьәләләре буенча баш белгеч Энҗе Побежимова.

КАИны тәмамлаган перспективалы студентлар үзләренең озын һәм мавыктыргыч хезмәт юлын еракта калган 1980 нче елларда ук башлаганнар. Энтузиаст, романтик, ватанпәрвәр яшьләр үзгәрүгә таба барган дөньяда яңа мөмкинлекләр күреп алалар һәм үзләренең авиамодельләштерү өлкәсендәге белемнәрен гамәлдә кулланып карарга уйлыйлар. Казанның спорт мастерлары һәм СССРның авиамодельләштерү буенча җыелма командасы егетләрен яраталар, эшкә билгеләнергә вакыт җиткәндә аларга ихтыяҗ зур була. Валерий Побежимов ул вакытта авиамодельләштерү түгәрәге белән җитәкчелек итә һәм амбицияләре көчле булган уйлап чыгаручы-новаторларны яңа фирмага чакыра.

– Мин предприятиенең иң беренче хезмәткәрләренең берсе, динозавр, музей экспонаты дияргә дә була, – дип елмая баш конструкторның юнәлеш буенча урынбасары Вадим Львович Кузьминский. – 1982 елда «Спорт авиациясе» тәҗрибә-конструкторлык бюросы оешмасында без планерларның тәҗрибә үрнәкләренең проектлары белән шөгыльләндек. Гражданнар авиациясендәге үзгәртеп корулардан соң, конструкторлык бюросы коллективы хәрби сәнәгатькә – «Сокол» конструкторлык бюросының перспективалы эшләнмәләр бүлегенә күчте. Бүгенгедәй хәтерлим: мине 1983 елның 30 апрелендә эшкә алдылар, әмма без 1982 елның көзеннән эшли идек инде. Безнең диплом эше, бик сирәк очрый торган хәл, чынбарлыкка әйләнде – безнең музейда аның белән таныша аласыз. Хәзерге вакытта компаниядә мин очыш динамикасы һәм оча торган аппаратлар белән идарә итү системасы белән шөгыльләнәм, эксперт булып торам һәм хәрби частьлардан БПЛА операторларына консультацияләр бирәм.

1988 елда Побежимов җитәкчелегендә тикшеренү үзәге оеша. Компания 1997–1998 елларга туры килгән катлаулы чорны кичерә, ул вакыттагы кризис сәнәгатьтә хезмәткәрләрне коры энтузиазмга гына эшләргә мәҗбүр итә. Җитәкченең тырышлыклары нәтиҗәсендә команданы саклап калу мөмкин була һәм, 2000 еллардан башлап, оешманың үсешендә яңа чор башлана. 2003 елда фәнни-тикшеренү үзәге «ЭНИКС» Ябык акционерлык җәмгыятенә әйләнә. Бүген әлеге компания – төрле билгеләнешле пилотсыз авиация комплекслары эшләү, җитештерү һәм аларны сериялап сату өлкәсендә илебездә әйдәп баручыларның берсе.

> – Без барыбыз да әр-яңадан тотынырга әзер булган энтузиастлар идек. Еллар узгач, ул вакыйгаларны искә төшерәм дә ул вакытта үзебезнең дөрес юл сайлавыбызга инанам. Менә 30 елдан артык инде – «ЭНИКС» – очыш траекториясендә! – ди компаниянең җитәкчесе Валерий Николаевич Побежимов.

– Мине дә оешмага нигез салучыларның берсе дип санарга була, мин биредә беренче көннәрдән үк. Авиамоделистлар арасыннан, минем өчен дә якын тема – һәрвакыт шул эшкә тартыла идем. Хәзер инде гомерем пилотсыз авиация белән бәйле, 35 елым шушында үтте, – дип сөйли юнәлеш буенча баш конструктор Илдар Рәис улы Якупов. – Безне ул вакытта чын мәгънәсендә «банда» дип йөртәләр иде, Кулибиннар дип. Барысы да шушы фикердәшләр командасыннан оешып барлыкка килде. Шуңа да без вакыт дип тормадык, акча юк дип тормадык – компанияне «күтәрдек». Безнең алга куйган максатларыбыз бар иде, без шуңа омтылдык һәм нәтиҗәләргә ирештек.

– Бирегә 1984 елда килдем. Без хатыным белән «ЭНИКС»та баштан ук эшлибез дияргә була. Монтажлаучы булдым, аннан соң югары белем алгач, конструктор булып эшли башладым һәм Илдар Рәис улы командасында җитәкче вазыйфага кадәр үрләдем, – дип сөйләде юнәлеш буенча баш конструктор урынбасары Сөләйман Әнвәр улы Саттаров. – Хәзер инде балаларыбыз да – Айрат улым белән Илсөя кызым да биредә эшли. Икесе дә – инженер-конструктор.

Компания эшләнмәнең бөтен циклын тәэмин итә (планердан башлап, бортка урнаштырыла торган радиоэлектрон җайланмага кадәр), беренче сызымнардан башлап, кулланылыштан сервиска кадәр. Казан компаниясе җитештергән продукциянең төп кулланучылары – Россия Федерациясенең Оборона министрлыгы һәм көч структуралары. «ЭНИКС» Акционерлык җәмгыятенең фәнни-тикшеренү эшләнмәләре пилотсыз очкычлар өлкәсендә еш кына көнбатыштагы үрнәкләрдән өстенлеккә ия була, һәм алар илебез хәрбиләренә яудан соң иң җитди бурычларны үтәргә, солдатларыбызның гомерен саклап калырга, уңышлы итеп разведка ясарга ярдәм итә. Татарстанда җитештерелгән югары сыйфатлы җайланмаларны хәзерге вакытта илнең һәм җир шарының төрле почмакларында – Калининградтан Курилгача, Кырымнан Сүриягә кадәр, шулай ук Мароккода, Алжирда, Гарәп Әмирлекләрендә табарга була.

– Без барыбыз да авиамодельләштерүдән чыккан кешеләр, анда мин халыкара класслы мастер булып

Реклама. Фото: Александр Ефремов; «ЭНИКС» АҖ

Сулдан уңга: Илдар Якупов, Сөләйман Саттаров, Игорь Нагибин, Вадим Кузьминский, Зөфәр Идиатуллин, Зөфәр Ваккасов.

торам. Коллективка 1983 елда Валерий Николаевич чакыруы буенча килдем. «ЭНИКС»ның көче шунда: без бердәм коллектив, бер-беребезнең тормышына битараф түгел, без кунакка йөрешәбез, бергәләшеп походларга чыгабыз, балыкка барабыз. Авыр чакларда да без аларның вакытлы гына булуын белә идек. Бер-беребезгә таяндык һәм аякта басып калдык, – ди югары квалификацияле тәҗрибәле белгеч, тәҗрибә җитештерүенең ябыштыру участогы бригадиры Зөфәр Котдус улы Ваккасов. Ул предприятиедә яшь кадрларның остазы да булып тора. – Бүгенге көнгә оча торган аппаратлар эшлим, биредә җитештерелә торган барлык модельләргә дә минем өлешем кергән дияргә була. «ЭНИКС» АҖндә эшләгәндә минем тарафтан меңнән артык фюзеляж, канатлар һәм композиция материалларының төрле детальләре эшләп чыгарылды. Барлык самолетлар да минем куллар аша үтте.

Һичшиксез, оешманың «лаеклы» кешеләре исемлегенә һәрвакытта да ышанычлы терәк булган финанс белгечләрен – исәп-хисап һәм салым өлкәсендә югары класслы белгеч, баш хисапчы Зифа Сәлим кызы Коновланы һәм икътисад һәм финанс мәсьәләләре буенча баш белгеч, фирманың ветераны Энҗе Мигъран кызы Побежимованы кертергә була. Компания кооператив булганда әле, аңа баш хисапчы да, планлаштыручы да, кадрлар бүлеге дә, юрист та булырга туры килә. «ЭНИКС»ның принциплары арасында – тормышка күтәренке кәеф белән караш һәм сәламәт яшәү рәвеше. Шуңа да компаниянең үзенең хоккей командасы булуы гаҗәп түгел. Аның капитаны һәм тренеры – механика-җыю эшләре слесаре Зөфәр Рәхим улы Идиатуллин. Боз дружинасының составына 19 кеше керә, алар арасында хезмәткәрләрнең балалары да бар. 2020 елның гыйнварында Казанда узган Бөтенроссия корпоратив фестивалендә ул үз төркемендә 1 нче урынны алган.

– Компаниянең әйләнеше берничә миллиард сум тәшкил итә, иң күп сатыла торган эшләнмә – Е95М мишене, аның буенча ПВО системалары, мәсәлән, күпләргә таныш «Игла» һәм «Панцирь» ПЗРКлары ата. 800 дән артыграк шундый мишень эшләнгән. Шулай ук берничә йөз пилотсыз-разведчик очкыч җитештерелгән. Россиянең БПЛА белән җиһазландырылган подразделениеләре ерактанрак күрә һәм алга куелган бурычны үтәгәндә, үзләрен куркынычсызрак тоя, – ди генераль директорның беренче урынбасары Игорь Владимирович Нагибин. – Пилотсыз разведка «кайнар нокта»ларда безнең солдатларның гомерләрен саклый. Еш кына җитештерелгән продукция өчен безгә хәрби бәрелешләрдән югалтуларсыз чыккан хәрбиләр рәхмәтләрен җиткерә. Әйтергә кирәк, Россия командасы 2020 елгы армия укуларында безнең техника белән беренче урынны яулады.

Акционерное общество ЭНИКС

«ЭНИКС» АҖнең хоккей командасы Казанда узган Бөтенроссия кышкы корпоратив фестивалендә.

«Татарстан» журналының махсус проекты

# ДӨНЬЯНЫ ЯХШЫГА ҮЗГӘРТҮЧЕ КЕШЕЛӘР

1

Автор: Алсу Дәүләтшина

## АЙГҮЗӘЛ ХӘЙРИЕВА: ТАБАРГА ҺӘМ КОТКАРЫРГА

**Ул безнең янга эшләпә киеп килде. Шундый көяз-купшы, өрфиядәй нәфис һәм бераз гына кыланчык. Шул ук вакытта максатчан, көчле һәм тәвәккәл дә үзе. Айгүзәл Хәйриева – ««Эзләү үзәге» ирекле эзләү-коткару берләшмәсе» җитәкчесе. Ул аны үзе оештырган, кешеләрне эзләү һәм коткаруда һәрвакыт шәхсән үзе катнаша – барысына да хәбәр итә, эзләүне оештыра, маршрутлар төзи, чытырманнарны айкый һәм... урманда адашкан гөмбәче әби-бабайлар турында чираттагы вакыйгасын сөйләгәндә, тыела алмыйча елый...**

### ШӘХСИ ТРИГГЕР

– Эзләү үзәге – минем күптәнге идеям. 2013 елдан бирле алып барылган эшчәнлегем шуңа китерде. Мин үзем Яр Чаллыдан, һәм бервакыт шунда сыйныфташларым белән очрашуга кайткан идем. Без биегән-җырлаган, аралашкан арада, башка кешеләр күз алдында бер бәндә бер баланы ирексезләп машинага утырткан. Алай гына да түгел, машинасы баткан, җүнсез бәндә янәшәдәгеләрдән төртеп чыгаруларын үтенгән, алар булышканнар һәм, монда ниндидер сәерлек булуын күрә торып, кызга ярдәм итмәгәннәр. Ташбаев һәм сигез яшьлек Василисаның язмышы – күпләргә мәгълүм вакыйга. Бу мин сыйныфташларым белән күңел ачкан көнне, нәкъ шул сәгатьтә булган хәл. Һәм шул ук шәһәрдә. Мин вакыйгаларны һәрчак вакыт буенча анализлыйм: бу кайчан булган һәм мин ул чакта кайда булганмын. Бу очрак минем башыма сыймаслык хәл иде: ни өчен кешеләр шундый игътибарсыз булып чыккан? Кыз машинага үзе утырмаган бит, бик күпләр аны ирексезләп утыртканны күреп торган... Хәзер, урамда йөргәндә дә, миндә рефлекс уянган кебек була: әгәр бала урамнан ялгыз бара икән, миңа, һичшиксез, шундук ачыкларга кирәк – кемнеке ул? Кем каршы алды аны? Бу чыннан да аның әтисеме, әбисеме? Әгәр бала белән олы кеше арасында аралашуның табигый, дустанә икәнен күрәм икән – тынычланам.

Шундый төшенчә бар – триггер: миндә әлеге реакцияне нинди вакыйга кабызып җибәргән, бу нәрсәдән башланган. Василисаны эзләгән арада, мин барысын да анализладым һәм бу өлкәдә никадәр тәртипсезлек булуын аңладым. Минем яраткан сүзем «оптимальләштерү», бөтен нәрсәдә тәртип-пөхтәлек яратам. Ә ул чакта анархия иде, әзерләнгән кешеләр юк иде. Бөтенесе булышырга тели, әмма һәркайсы үз кырында агроном.

Мин, нәтиҗәле булсын өчен, эзләү процессын тәртипкә салырга ниятләдем. Алайса, менә хәзер сезнең белән мин, хирург урынына басып, авыруга операция ясарга тотынган кебек була бит:

Фото: Александр Ефремов; «Эзләү үзәге» архивыннан

ул йә сихәтләнәчәк, йә җан тәслим кылачак. Монда иреклеләр җыелса да, алар бу эшкә әзер булырга, нишләргә кирәген төгәл белергә тиеш.

## ТАБИГАТЬ БЕЛӘН УЗЫШЫП

Татарстанда эзләү үзәге бер генә түгел. Яр Чаллыда «Василиса», Түбән Камада – «Эз», Алабугада – «Өмет» отряды, Казаннан ОРСО ирекле кинологлары... Безнең бурычыбыз – кешеләрне эзләү һәм коткару өчен ресурсларны берләштерү, шулай ук иреклеләр отрядларын өйрәтү һәм җиһазлау. Без берләштерергә тырышкан арасында дәүләт оешмалары да, бизнес та, югарыда атап үткән коллективлар да бар. Бу эштә кеше никадәр күбрәк булса, шулкадәр яхшырак. Без табигать белән узышып эшлибез: адашкан кеше янына кайсыбыз алданрак барып җитә – йә без аны коткарырга өлгерәбез яисә табигать аны үзендә калдыра.

Безнең «Эзләү үзәгендә» инде биш елдан артык шуның белән шөгыльләнүче иреклеләр эшли, алар башкаларны да өйрәтә ала. Төрле һөнәр ияләре булган әлеге энтузиастлар буш вакытларында эзтабарлар әзерләү белән дә шөгыльләнә. Моның өчен бер тиен акча да алмый. Кызганычка, хәзер мондый кешеләр һаман азая бара, һәм кайвакыт эзләгәндә техник яктан көч җитми. Кешеләрнең чит кеше кайгысына битарафлануы түгел бу, бәлки алар, әлекке дәрәҗәдә акча алу өчен, хәзер төп эшләрендә күбрәк булырга тиеш, чөнки бәяләр үсә, тормыш итү кыйммәтләнә. Кешеләрнең эзләү белән шөгыльләнергә вакыты калмый булып чыга.

Иреклеләрнең мондый игелекле эшләре үзләренә берәр төрле файда да китерсә, бик яхшы булыр иде. Мәсәлән, теш дәвалауда ташламалар, яисә ниндидер салымнарны киметү, яисә балаларын түләүсез түгәрәкләргә йөртү... Ә нигә юк? Чит илләрдә бу хәл гадәти.

## УКЛАР, НОКТАЛАР, ТАМГАЛАР, ТРЕКЛАР...

Бүген бездә, мөмкинлекләренә карап, кырыклап кеше эзләүгә чыга ала. Аңлашыла ки, бернинди штат та юк. Без берләшмәгә килеп кушылганнарны гына түгел, төрле эзләү-коткару отрядларына йөргән иреклеләрнең һөнәри дәрәҗәләрен күтәрергә булышабыз. Бу процесс ничек бара?

Шәһәр буйлап ориентировкалар урнаштырабыз. Бизнес-структуралар белән килешәбез – кеше югалуы турында алар үз мәйданчыкларында сөйли ала. Күп еллар элек, Мәскәү янындагы бәби табу йортыннан Матвей Ивановны урлаганда, безнекеләр Казан аэропорты белән килештеләр һәм анда һәр 15 минут саен: «Игътибар! Бала урланган!» – дип игълан итеп тордылар. Адашкан кеше юлны тизрәк тапсын өчен, урманда уклар куябыз. Бу тенденция безгә Европадан килде, беренче булып моны Санкт-Петербург эзләү отрядлары кабул итеп алды, аннан соң – без.

Әмма иң мөһиме – эзләү эше. Кеше урманда адашканда, ГТХМ ның якынча биш кешесе һәм бер полиция хезмәткәре эзләргә чыга һәм, әйтик, югалган әбине эзли башлый. Ә территория бик зур. Шундый термин бар – «эзләү квадраты» – 500 гә 500 метр. Һәм шундый квадратлар саны 25 булырга мөмкин. Бу кеше югалган урынның уртача статистик ареалы. Әгәр әлеге дә баягы биш-алты кеше йокы-ялсыз, бертуктамый эзләсә дә, адашкан әбине бер айдан артык эзләячәк. Чөнки һәм квадратны карап чыгуга кимендә биш сәгать вакыт кирәк. Димәк, иреклеләрне саны күбрәк булган саен, әбине табу мөмкинлеге арта, эзләү вакыты шактыйга кими.

**– Ә эзләүче үзе адашырга мөмкинме?**

– Эзләүчеләр барысы да өйрәтелгән. Беренчесе – торган урыныңны билгеле белү. Компас ярдәмендә. Гөмбәче төньяк һәм көньякның кайда икәнен бер минуттан гына билгеле алса, безнекеләргә секундтан да әзрәк вакыт җитә. Барысында да туристлык навигаторы бар. Нокталар, тамгалар куябыз, аннары әлеге трекларны кушабыз һәм анализлыйбыз – бу треклар буенча, кардиограммадагы кебек, әлеге кишәрлекнең никадәр төгәл карап чыгылган булуы күренә.

Әзерлекле кешеләр үзара сөйләшмиләр, игътибарларын читкә юнәлдермиләр – адашкан кеше гомере өчен берничә минутның да бик кадерле булуын алар бик яхшы белә. Бездә бер кыз бар иде, урманда сызгыч белән йөргән кебек – аның треклары шулкадәр туры, идеаль булып чыга иде.

**– Сез эзләүнең кайсы этабында кушыласыз?**

– Адашуын аңлаган кешегә шундук «112» номерына шалтыратырга киңәш итәбез. Безнең Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы белән килешүебез бар, алардан сигнал алуга, эзләү эшләренә кушылабыз.

Әлбәттә, элегрәк, 2013 елларда, беренче иреклеләр махсус хезмәтләрне шаккатыралар иде – индеецлар кебек йөгерешәләр, ихластан булышырга тырышалар, ләкин нишләргә кирәген үзләре дә белеп бетермиләр. Махсус хезмәтләргә кайчак, адашмасыннар өчен, әлеге «ярдәмчеләрнең» үзләрен дә күздән югалтмаска туры килә.

2013 елдан 2016 елга кадәр мондый вакыйгалар бөтен ил буйлап күзәтелде. Кайсыдыр бер төбәктә эзтабарлар бер кешенең сараен да яндырды хәтта.

Алар югалган кеше шул сарайда дип уйлаган, ачып керсәләр – беркем дә юк. Хуҗасы, әлбәттә, ачулана башлаган. Нәтиҗәдә хуҗаны кыйнаганнар, ә сарайга ут төрткәннәр.

Шунлыктан оештыру эше мөһим – без нәкъ менә шуның белән шөгыльләнәбез дә.

## ӨЧ КӨН КӨТМӘСКӘ

**– Ничә кешене коткаруда катнаштыгыз?**

– Безнең куллар аша 700 очрак үтте. Бу, 700 кеше коткарылган, дигән сүз түгел. Димәк, без шулкадәр мөрәҗәгатьне кабул иткәнбез һәм теге яки бу дәрәҗәдә эзләүдә катнашканбыз.

Хәзер кешеләр үзләрен дөрес тота башлады инде. Алайса элек бит ничек иде: өч көн көтәбез, аннары гына эзлибез. Кем уйлап тапкандыр ул өч тәүлек көтүне. Ихтимал, бу СССРда мобиль элемтә булмаганга шулай күнегелгәндер. Кешенең өч көн буе элемтәгә чыкмавын тыныч кабул иткәннәр – барып җитмәгәндер, телеграмма җибәрә алмагандыр... Хәзер эзләү шундук башлана. Һәм бу бик мөһим. Ата-ана: «Балабыз югалды!» – дип шалтырата, кайвакыт шул «югалды» һәм «табылды» арасында ярты сәгать кенә вакыт үткән була. Һәм Аллага шөкер, таптык дип, үзләре шалтыраталар. Шалтыратып ярдәм сораулары да яхшы, вакыт югалмый. Кечкенә балалар суга бата, картлар әллә кая китеп адаша... Без югары технологияләр чорында яшибез, ә картлар кайвакыт кесә телефоныннан да шалтырата белми һәм шуңа югала. Бөтен җиргә видеокамера куелган кебек, әмма без эзләгән урыннарда һәрвакытта да булмый, яисә алар эшләмәскә мөмкин.

## СЕЗОНЛЫ «ЮГАЛТУЛАР»

**– Күп кеше югаламы?**

– Ковидка бәйле рәвештә мөрәҗәгатьләр саны артты. Күрәсең, карантин чорында өйдә утырудан туеп, кешеләр урманнарга бара һәм... югала башлады. Җитди булмаган гаризалар да күп. Бөтенесе, кеше югалган, дип уйлый, ә ул рәхәтләнеп елга буенда ял итә икән...

Сентябрьдә мәктәпкә барасы килмәгән балалар кача башлый. Кайберләренең укуда, сыйныфташлары, укытучылары белән аралашуда проблемалары бар. Ягъни мондый хәл килеп чыкмасын өчен, бала белән алдан ук сөйләшергә, аңлатырга кирәк. Җавапсыз мәхәббәт аркасында да үсмерләр өйдән чыгып китә, яисә дуслары белән бергә берәр кая чыгып китә, яисә ниндидер артистның икенче шәһәрдәге концертына бара... Сабыйлар һәм үсмерләр дөньяны өлкәннәр кебек түгел, башкача күрә. Кем белән булса да урамда танышалар, шуңа кунакка керәләр, мавыгып уйный башлыйлар – әти-әниләре исә шул арада эзләп хәлдән тая...

Яз-көз – психик тайпылышлары булган кешеләрнең югалу чоры. Җәй азагы һәм көз – барысы да урманга гөмбәгә ашыга. Һәм ике сәбәп буенча югала: адашалар яки сәламәтлекләре кинәт начарая. Һәм бу хәл картлар белән генә түгел, яшьләр белән дә булырга мөмкин. Инсульт хәзер яшь кешене дә аямый – теләсә кайчан һәм теләсә кайда аяктан егарга мөмкин, хәтта телефоннан да шалтыратырга өлгерми калу ихтималы зур. Шунлыктан без урманга беркайчан да ялгыз гына бармаска, һәрвакыт телефонны янда йөртергә киңәш итәбез. Юлны табу өчен махсус җайланмалары булган безнең эзтабарларыбыз да берәм-берәм йөрми. Әгәр хәлең начарланса, синең җиһазларың үзләре ярдәмгә чакыра алмый бит. Урманга кимендә икәү барырга кирәк. Әмма кешеләр нигәдер һаман ялгыз юлга чыга һәм югала. Хәтта урманга машина белән кергәннәре дә, пычракка батып, чыга алмаска, адашырга мөмкин.



## 1 нче очрак

### НАВИГАТОРДАН ФАЙДАЛАНА БЕЛМӘГӘН

Күптән түгел өлкән яшьтәге ир-ат урманга гөмбәгә китә. Аның телефоны, анда исә навигатор бар, дип, улы да борчылмый. Әмма бабай телефоныннан файдалана алмый.

Өлкәннәрне дә, балаларны да урманга үзләрен генә җибәрергә һич ярамый! Бабайны көчкә эзләп таптылар.

## 2 нче очрак

### ТЕЛЕФОН ЯРДӘМЕНДӘ ТАБАЛАР

Күптән түгел Әгерҗе районында кешеләр адашкан. Машинада. Ярый әле без телефон буенча кая барырга кирәклеген аңлата алдык. Кояш бар иде, шуңа карап чыктылар. Элемтә яхшы икән, адашкан кешегә телефоны буенча ярдәм итеп була. Интернет булса, тагын да җайлырак – адашучыларны тиз табарга мөмкин.

## 3 нче очрак

### ҖИҢЕЛ КОТКАРУНЫҢ БЕР МИСАЛЫ

Бу хәл Казанның төньягындагы урманда була. Хатын-кыз адаша, телефоннан шалтыратып, нәрсә күрүен сөйли, квартал баганасындагы саннарны да укый. Кайда икәнен шундук аңлап алалар. Телефоннан өйрәтеп торалар: кояш кайсы якта – сулда. Кояшка каршы басыгыз. Ызанны күрәсезме? Күрәм! Шуның буйлап барыгыз! Урман уртасыннан шулай чыгаралар. Беркемгә дә эзләргә дә, бензин әрәм итәргә дә туры килми. Җиңел коткару очрагына бер мисал бу.

## 4 нче очрак

### КОТКАРМАУГА БЕР МИСАЛ

Мондый табылмаган кешеләр дә бик күп – аларның кая киткәнен беркем дә белми һәм кайдан эзләргә икәне дә мәгълүм түгел. Мәсәлән, профессор Мягченков. 2018 елда югалган. Ул булырга мөмкин булган җирдән бик озак эзлиләр, әмма тапмыйлар. Гәрчә шундый хәлләр дә булгалый: югалган кеше үзе өенә кайта, тик безгә бу турыда хәбәр итмиләр, һәм ул һаман табылмаган санала.

## 5 нче очрак

### КОМАНДА ЭШЕ

2020 елның 1 августында Михаил Васильевич Лисин (1951 елгы) Тукай районының Бриз бакчачылык ширкәте янындагы урманга гөмбәгә китә. Адаша, якыннарына шалтырата. Әмма юлны үзем табам, дип ышандыра. Төнгә каршы да кайтмагач, туганнары коткаручыларга һәм иректә эзләүчеләргә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Элемтә еледән-еле өзелә, кешенең кайда булуын ачыклау мөмкин түгел. Кая таба барганын, нәрсә күрүен, күпме баруын аның сүзләре буенча гына беләләр... Инде 2 август көнне икенче тапкыр эзләргә чыгалар, исемен әйтеп кычкыралар – юк, табылмый. Һәм менә «Эз» отрядыннан Виталий үзеннән ерак түгел арып агачка сөялгән бер гөмбәчене күреп ала. Йөгереп килеп: «Сез Михаилмы?» – дип сорый. Ир-ат җиңел сулап куя: «Әйе, мин ул», – ди.

Кешене табу – команда эше ул. Урман зур, барлык кишәрлекләрне карап чыккач кына нәтиҗәгә ирешергә мөмкин. Кемнеңдер кишәрлеге буш булачак, кемнекендәдер адашкан кеше табылачак. Төгәл мәгълүмат булмаганда, кешене табу мөмкин түгел. Эзләүне киңәшләшеп оештырмаганда, адашучыны табуы кыен. Ә кайвакыт исә яхшы әзерлекле иректә отрядлар һәм профессиональ коткаручылар, урманчылар бергә эш итеп тә, тапмаска мөмкин. Шунлыктан урманга ялгыз бармагыз, үзегез белән телефон, компас, шырпы, навигатор алыгыз, якыннарыгызга үзегезнең кая баруыгызны төгәл аңлатыгыз.

## 6 нчы очрак

### ГӨМБӘЛЕ СӘФӘР

Без Республика көнен урманда каршыладык, дияргә дә була. Иртүк Тукай районындагы Боровецк урманына өйрәнүләр үткәрергә киттек. Эзтабарыбыз Алёна Макарова, шуннан соң гөмбә дә җыярга ниятләп, урманга кергәч, Лидия исемле дустын эзләгән әбигә тап булды. Әбигә инсульт булган икән, шуңа ул акрын йөри, ә менә дусты алгарак киткән дә, хәзер беркайда да күренми.

Без барыбыз бергә эзли башладык. Элемтә даими өзелә, яныбыздагы әби һаман ялгызы аерылып китмәкче һәм дустын үзе эзләмәкче була: «Без инде 35 ел буе дус, һәм мин аны бер тапкыр да югалтканым булмады!» – аның төп дәлиле. Нәтиҗәдә адашкан әби телефон буенча элегрәк әйтмәгән нәрсәләр – күл, ызан турында сөйли башлады. Без аның кайда икәнен аңлап алдык та, Лидияне таптык. Аларга әйбәтләп аңлаттык: урманда ничек дөрес юлны табарга, адашканда кая шалтыратырга, бер-берсеннән ерак китмәскә. Гөмбәчеләр өчен иң гади кагыйдәләр бу. Беренче әби, Тамара, безгә бик рәхмәт укыды. Шулай итеп, без гөмбә тапмадык, әмма гөмбәчеләрне таптык – безнең эштә иң мөһиме шул да бит инде.

**Тукай районының Боровецк урманында адашучыларның бик күп булуы «Эзләү үзәге» энтузиастларын кагыйдәләр җыелмасы чыгарырга мәҗбүр иткән:**









## МӨРӘҖӘГАТЬЛӘР ИҢ ЕШ БУЛГАН УРМАН МАССИВЛАРЫ:

- Яшел Үзән районы;
- Биектау районы;
- Марий Эл;
- Минзәлә районы;
- Лениногорск районы;
- Бөгелмә районы;
- Лаеш районы;
- Питрәч районы;
- Тукай районы Боровецк урманы;
- Балык Бистәсе районы.



## УРМАННАН НИЧЕК ЧЫГАРГА

### Укларны ОРСО иреклеләре түбәндәге урманнарда урнаштырды:

- – Яшел Үзән һәм Әйшә янындагы урман массивында;
- – Казна урманы массивының бер өлешендә – Озерный – Новониколаевск – Бишнә – Ивановское (М7 трассасы өстендә) торак пунктлары арасындагы;
- – Займище һәм Васильево станцияләре арасындагы урман массивында – тимер юл тармагыннан өстәрәк;
- – Пановка – Красный Восток – Тимошкино торак пунктлары арасындагы урман массивында;
- – Матюшино тракты һәм Вороновкадан (Лаеш районы) сулдарак урман массивында, Матюшинодан Лаеш районының Орел авылына кадәр (яр буендагы урманның бер өлешендә), Лаеш янәшәсендә (торак пункттан сулдарак);
- – Лаеш һәм Питрәч районнарындагы Күн – Татар Янтыгы – Среднее Девятово – Каипы – Бима-Карповка – Питрәч торак пунктлары арасындагы урман массивларында;
- – Балык Бистәсе районындагы Шомбыт – Мельничный Починок – Новый торак пунктлары янәшәсендәге урман массивында;
- – Саба аучылык заказнигында (Саба районы Лесхоз бистәсе янындагы урманда);
- – Түбән Кама янәшәсендәге Корабельная урманында;
- – Биектау районында, Гарь бистәсеннән югарырак Наратлык авылына кадәр урманда.

### «Эзләү үзәге» ирекле эзләү-коткару берләшмәсенә» 1 июльдән 30 сентябрьгә кадәр 470 мөрәҗәгать кергән. Шулардан:

- 26 – эзләүдән баш тартканнар (яки мөрәҗәгать итүче баш тарткан, яисә мәгълүматны тикшергәндә беркемнең дә югалмавы ачыкланган: мәсәлән, бурычлы кешене эзләп табарга тырышу очрагы булган. Суга батучыларга кагылышлы мөрәҗәгатьләр дә бирегә карый, чөнки без аларны эзләмибез – бу водолазлар һәм ГТХМ коткаручылары эше һ.б.);
- 5 – ялган гариза (акылга зәгыйфьрәк кешеләрдән булмаган туганнарын таптыру турында һ.б.);
- 219 – кабул ителгән;
- 41 – урманда адашканнарны эзләү;
- 178 – шәһәр эчендә югалганнарны эзләү;
- 65 – балалар (0дән 17+ яшькә кадәр);
- 131 – өлкәннәр (18дән 51+ яшькә кадәр);
- 73 – картлар (52+ яшьтән башлап).
- Югалганнар барлыгы – 219.
- Исән табылганнар – 200.
- Табылганнар, үлеләр – 9.
- Эзләү процессында – 10.

# ЕКАТЕРИНА КУЗНЕЦОВА: КҮРДЕМ ДӘ ЯРАТТЫМ

2

Автор:
Татьяна Вафина

**«Иҗади натура... Чәчләрем чаларса да, һәрчак яшь... Ике бала, тик аларны мин тапмадым... Минем язганнарым – яралы җаннар өчен пластырь...»**

**Sporttykit – Екатерина Кузнецова, уңышлы блогер – үз сәхифәсенә язылучыларга ничек йорт салуы, бакчада казынуы, зәңгәр йомырка китерә торган гаҗәеп тавыклар тотуы, балчыктан могҗизалы савыт-саба ясавы, бию дәресләрендә очрашып кавышканнан бирле, ире белән ишегалдында болай гына, кәеф күтәрү өчен генә биюе турында матур итеп, чын күңелдән сөйли. Ләкин күп очракта – уллыкка алынган ике бала әнисе булуның нинди зур бәхет икәнлеге турында... Күптән түгел ул «Дети, домой!» дип аталган китап чыгарды, ул басма – уллыкка бала алырга теләп, ниндидер сәбәпләр аркасында соңгы карарны кабул итә алмый йөрүчеләр өчен бер ярдәмлек. «Татарстан» бу китап белән һичшиксез танышты һәм авторы белән Казанда очрашты – Новосибирскидан килгән сәяхәтчеләр гаиләсенең безнең Курчак театрына сокланып йөргән чагы иде. Сүз арты сүз – һәм менә кояштай җылы һәм якты ханым белән танышып, аның кечкенә генә көндәлек сөенечләрне ихлас ярата белүеннән бүген әле «Инстаграм» челтәренә чуммаган кешеләрнең дә үзләренә көч-куәт алу мөмкинлеге бар.**

Фотолар Екатерина Кузнецованың шәхси архивыннан

## «ДЕТИ, ДОМОЙ!»

**– Катя, сезнең популяр, кызыклы, башкаларныкына охшамаган үз блогыгыз бар инде, сезгә мөкиббән язылучылар да бихисап. Баланы уллыкка-кызлыкка алу турында постларыгыз үзе бер китап кебек, аерылып булмый. Теләсә кайсы китапка караганда да колачы киңрәк. Аның кәгазь вариантын нигә чыгарырга булдыгыз?**

– «Инстаграм»да шактый зур аудиторияне колачлавыма карамастан, бөтен кешенең дә анда утырмавына иманым камил. Чөнки ни дисәң дә, бу социаль челтәр фотолар, визуаль күренешне күздә тота. Аудиториям шактый зур булса да, тәрбиягә бала алып, ата-ана булырга теләгәннәрнең барысы да бу «китап»ны укымый, күрми.

Тәрбиягә, уллыкка бала алучы ата-ана өчен мәктәпләрдә, бәлки, «Инстаграм» челтәрендә беркайчан да аралашмаган кешеләргә китабымны бөтен ил буенча киңәш итә алсыннар иде. Китапны кулга тоту да, зур-зур текстларны уку да уңайлы. Өстәвенә, «Инстаграм»да бу темага кагылышлы барлык постларны табарга кыен, ул бакчачылыкка караган язмалар, нинди дер видеолар, тормышта үз урыныңны эзләү турындагы постлар белән буталып беткән. Меңләгән пост арасыннан үзеңә кирәкне табу бер дә җиңел түгел.

Китапта исә барысы да аңлаешлы һәм күнегелгән рәвештә, тәртип белән тупланган. Өстәвенә, «Инстаграм»га кергәч, кешеләрнең кирәкле темасына чумып, башыннан ахырына кадәр һәрнәрсәне укып чыгарга вакыты да юк... Менә шуңа күрә «Дети, домой!» китабы дөньяга күрде дә инде.

**– Күпләр, уллыкка бала алгач, моны төрле сәбәпләр аркасында яшерергә тырыша. Кемдер баланың, үсеп җиткәч, үз әти-әнисе түгел икәнен белүен теләми. Кайчак үзләренең бала таба алмаганлыкларын белгертәсе килми. Һәм башка шундый сәбәпләр... Сез исә бу хакта бөтен дөньяга сөйлисез, мәгълүмат җиткерүнең төрле ысулларын кулланып, тәҗрибәгезне уртаклашасыз. Ни өчен? Язмыйча тора алмыйсызмы? Әллә миссиягез шундыймы?**

– Уллыкка алуга карата мөнәсәбәтнең үзгәрүен телим, бу гамәлне популярлаштырасы килә. Тагын да күбрәк кеше моның нормаль күренеш икәнен аңласын өчен. Мин үз үрнәгемдә һәм үз китабым белән кешеләргә баланы уллыкка-кызлыкка алу турында сөйләшергә ярагaнын, алай гына да түгел, моның кирәк эш икәнен җиткерергә телим. Бу хакта никадәр күбрәк сөйләсәк, шулкадәр күбрәк кеше бу гамәлдән курыкмый башлаячак, шулкадәр күбрәк кешедә тәрбиягә алган балалар барлыкка килергә мөмкин.

Мин үзләре бала таба алмаган, әмма уллыкка алу турында уйлап та карамаган бик күп кешене беләм. Аларга бу эш нинди дер куркыныч, каршылыклар белән тулы нәрсә булып тоела. Алар уллыкка бала алу бик катлаулы, ә андый баланы тәрбияләү искиткеч авыр эш дип саный. Минем бу хакта авыз тутырып сөйләшәсем, чынлыкта барысы да башкача икәнен аңлатып бирәсем килә.

## МӘХӘББӘТ НИЧЕК ТУА?

**– Уллыкка-кызлыкка бала алу процессында сез кичергән иң зур кыенлык һәм иң зур шатлык нинди?**

– Баштагы мәлдә, беренче тапкыр әни булган вакытымда, бик авыр булды: чәршәмбе көнне иртән әни булу уемда да юк иде, ә кичкә инде ана кешегә әйләндем дә куйдым. Дөрес, ярты ел чамасы без менә хәзер бала эзли башларбыз дип уйлаштырып йөрдек. Һәм кинәт чын-чынлап эзләргә керешкән көнне үк таптык. Кичен мин бөтенләй чит, бөтенләй таныш түгел сабыйга әни булдым. Мин бу кызны беренче тапкыр күрдем – һәм менә мин инде аның әнисе. Өч көннән соң янына хастаханәгә кереп яттым, тикшеренеп йөргән вакыты

**“Балаларга карата мәхәббәт хисе үзеннән-үзе барлыкка килде – бернинди гормоннар да юк иде, әни кеше туачак нарасыен яратып өлгерә торган берничә айлык йөклелек чоры да булмады. Һәм кинәт мин үзенә карата бернинди хис тә кичерми торган сабый барлыкка килә һәм, акрынлап, әнә шул юктан барга әйләнгән хистән тамчылап-тамчылап мәхәббәт туа...**

иде. Ягъни өч көн эчендә мин ана вазыйфасына тулысынча кереп чумдым: аны карыйм, ашатам, төннәрен уянам, һәм болар барысы да ниндидер эмоциональ әзерлексез килеш килеп чыкты. Мин ул вакытта бер атна эчендә җиде килограммга ябыктым. Ялгышканмын, бөтен тормышымны үзгәрткәнмен, хәзер ул беркайчан да элеккечә булмаячак кебек тоелды. Бик авыр уйлар иде ул. Мин уллыкка бала алырга әзерләндем, махсус ата-аналар мәктәбен уздым, үземне бу эшкә әзер дип уйладым. Асылда исә коточкыч авыр булып чыкты. Тик ике атнадан соң инде мин бик бәхетле хатын идем. Кызым белән бер-беребезне бик тиз яраттык. Тик менә хастаханәдә яткан беренче атна, табибларның төрле күңелсез нәрсәләр сөйләгән, мине орышкан вакыты гаять авыр булды. Ә улымны алганда мондый хәлдә калмадым, һәрнәрсәне эшли беләм идем инде.

Ә иң нык сөенгән чагым – кызымны бик нык яратуымны аңлаган, тойган вакыт. Улымны бик нык яратуымны аңлагач та, шундый ук хис кичердем. Ягъни күпмедер җайлашу, ияләшү вакыты таләп ителде, шунысын да искә алыйм: кызым белән мондый адаптация шактый тиз булды, бер айдан мин аны бик ярата идем. Ул бик тиз күнегеп, елмаюыма җавап бирә башлады. Улым белән процесс озаграк барды. Дөресен генә әйткәндә, мин аны бик тиз яраттым, ә аның ягыннан боз авыррак эреде. Бу баладан туганда ук баш тартканнар, әлеге хәл үзен сиздерми калмый. Мондый балалар, гомеренең беренче көннәрендә генә булса да, әни белән торып калган сабыйларга караганда авыррак ияләшә. Балаларга карата мәхәббәт хисе үзеннән-үзе барлыкка килде – бернинди гормоннар да юк иде, әни кеше туачак нарасыен яратып өлгерә торган берничә айлык йөклелек чоры да булмады. Һәм кинәт мин үзенә карата бернинди хис тә кичерми торган сабый барлыкка килә һәм, акрынлап, әнә шул юктан барга әйләнгән хистән тамчылап-тамчылап мәхәббәт туа... Әйтерсең, мин туфракка орлык чәчәм, ә аннан зур, бик көчле, куәтле, шатландыра торган мәхәббәт, үзара аңлашуга өйрәткән, һәрнәрсәне гафу итәргә сәләтле, чып-чын мәхәббәт үсеп чыга. Һәм бу хис бик күп төсмерле – минем өчен ана булу менә шул инде. Ягъни аларга чын ана булу хәлемнән килмәсә дә, мин үз балаларын бик нык яратучы ана була алам. Бу – минем өчен иң зур шатлык.

## УЙДЫРМАЛАР ҺӘМ ЧЫНБАРЛЫК

**– Ирегез белән бию кичәсендә танышуыгыз турында укыдым. Кызыгыз танышуга кадәр үк булган кебек... Бездә тулы булмаган гаилә бала ала аламыни?**

– Уллыкка-кызлыкка бала алу турында ялгыш фикерләр күп. Әлеге китапны мин нәкъ менә шуңа күрә яздым да инде.

Бездә өйләнмәгән ир-атка да, кияүдә булмаган хатын-кызга да баланы уллыкка алу тыелмый. Бу хакта сүзләр барысы уйдырма гына. Чынлыкта исә кызыбызны беренче ирем белән яшәгән вакытта алдык, аннары без бөтенләй башка сәбәпләр аркасында аерылыштык.

Соңрак мин Вованы очраттым, тик Никитаны уллыкка алганда без әле өйләнешмәгән идек.

## ЧЫН БУЛМАГАН ЧЫН ЯЗУЧЫ

**– Сез бик иҗади кеше, ахрысы. Биисез дә, тәлинкәләр дә ясыйсыз, өегез дә үзенчәлекле, китаплар да язасыз... Ә белемегез (Катя генетик булырга укыган) мондый талантларны күз уңында тотмый кебек, бигрәк тә әдәбият өчен ят өлкә. Шуңа да карамастан нәкъ менә әдәби сәләтегез аеруча якты чагыла. Сез ничек шундый ихлас постлар һәм күңелгә үтеп керә торган китаплар язучыга әйләндегез?**

– Мин үземнең чын язучы түгеллегемне һәрвакыт әйтә киләм. Яза белмим дигән фикер күңелгә кереп калган иде. Рус теле һәм әдәбияты белән дус түгел син, иншаларны начар язасың, дип, миңа мәктәптә үк сеңдереп тордылар, һәм язу эше минем өчен түгел дип үз-үзем белән килешкән дә идем. Шуңа да карамастан язмый булдыра алмадым – уй-фикерләремне уртаклашасым килде. Чөнки мин шундый кеше – күңелем ачык. Мин әле «Инстаграм»га кадәр үк, бик-бик иске социаль челтәр – «Живой журнал»да үз блогымны алып бара башладым. Тормышыбызда нинди вакыйгалар булганын гына язып тордым, кешеләр мин кичергән хис-тойгыларны үзләрендә дә сынап карый алырлык булсын дип, бәян кылырга тырыштым. Шулай итеп, күрәсең, үземдә нининдидер әдәбилек мускулы ныгып, үсеп киткән һәм мин... язучы булып киттем. Хәзер исә моның ник кирәклеген аңласа, һәркем язарга өйрәнә ала, дип саныйм. Язмаларымның төп максаты – үзем белгәннәргә өйрәтү. Әйтерсең лә, кемгәдер үз күлмәгемне, үз тормышымны, шатлыкларымны, хис-тойгыларымны биреп торам. Үз хисләремне төп-төгәл итеп тасвирлап, укучыга җиткерә алганда, ихлас рәхәтлек тоям. Бу китабым да нәк шулай язылган. Аны укыган һәркем, әйтерсең, дустыма, тормышымның ниндидер бер өлешенә әверелә. Блогымда да кемдер: «Син язганнар күңел өчен бер гимнастика ул», – дип әйтсен өчен язам. Чөнки мин текстка керткән хис-тойгыларны үзендә кичергәндә, кеше гүя минем белән парлашып биегән сыман бит. Мин моңа ничек ирешәм? Сүзне җиткерү, куллану серләрен бик күп өйрәндем. Постларыма һәм китабыма карата кешеләр язган бәяләмәләрдән чыгып, моны уңышлы башкарам кебек.

## ТОРМЫШМЫ ӘЛЛӘ ЯСАЛМА ПОПУЛЯРЛЫКМЫ?

**– Сәхифәгездәге нәрсәләр: йорт, ирегез, биюләр, балалар – чын бәхет... Болар блогыгызны популярлаштыру өчен эшләнмидер. Чөнки барысы да ихлас, ясалмалык бөтенләй юк кебек. Моңа ничек ирешә алдыгыз? Гаилә бәхетегезнең сере нидә?**

– Юк, бу – уллыкка бала алу турында блогны ясалма популярлаштыру түгел. Шунысы да бар: блогымда яза башлаган вакытта кызыма инде биш яшь иде. Мин бала алуда пиар, реклама ясамадым. Максатым шул блог ярдәмендә кешеләргә уллыкка бала алу үзенчәлекләре турында сөйләү иде, алар шунда күп сорауларына җавап тапсын, мөмкин кадәр күбрәк кеше безнең тормышны күрсен һәм шуңардан үзенә көч-дәрт алсын, дидем. Миңа калса, блогның ни өчен кирәклеген һәрчак аңлап эш итү зарур, ә аны үстерү чаралары бик күп ул. Моның өчен үзенчәлекле тема да кирәк түгел, башка кешеләрдән аерылып тору да таләп ителми. Һәр кеше уникаль, һәм үз блогын үстерергә теләгән һәркем моны эшли ала, тик моның өчен үз тормышыңны үзгәртергә кирәкми. Кешеләр сиңа ышансын, әчкерсезлек шарты саклансын өчен, үз тормышың турында ничек бар, шулай сөйләргә кирәк. Мин нәкъ шулай эшлим дә. Бернине дә бизәмим, ничек бар, шулай җиткерәм. Үз блогымны чын күңелдән алып барам.

## «ҮЗЛӘРЕНӘ КАЙТАРЫП КАЛДЫРАМ»

**– Тискәре комментарий язучыларга ничек җавап бирәсез? Чөнки фикер-карашларыгыз белән бөтенләй килешмәүчеләр дә бар бит. Әле кайберәүләр бу дөньяга бөтен нәрсәне тәнкыйтьләү өчен килгән кебек. Аларны уку, сүзләрен күңелгә якын алу кәефне кыра, күңелне төшерә.**

– Язылучыларым арасында андый усаллар юк диярлек, чөнки аудиториям иркле рәвештә җыелган кешеләрдән тора. Ягъни сәхифәмә мәҗбүриләп, ихтыярсызлап ядырылган кешеләр юк. Блогны үстерү өчен еш кына гивлар кулланыла, мәсәлән: бер блогер нидер бүләк итә, ә моңа кызыккан һәркем аның иганәчеләренә язылырга тиеш. Мин язганнарны укып барырга тиеш кешеләр булмасын өчен, блогымны үстергәндә андый алымнарны бөтенләй кулланмадым диярлек. Чөнки яза торган нәрсәләрем – минем өчен гаять шәхси, артык мөһим өлкә, кемне дә булса аны күзәтеп торырга мәҗбүриләү урынсыз. Бу – тормышым турындагы сериал, шулай дисәк тә була. Кешеләргә минем сәхифәм ошасын, аларга кызык булсын дип тырыштым. Шуңа күрә усаллар, явызлар юк диярлек. Әлбәттә, кайча-



гында очраштыргалыйлар, кешеләр бик төрле бит, үз фикерен әдәпле рәвештә җиткерә белмәүчеләр дә бар. Сәхифәмне алып барган 2,5 ел эчендә андый комментарийларны үз хисабыма дип кабул итми башладым. Миңа адресланган нәрсәләрне үзләренә кире кайтарырга тырышам. Әгәр, мәсәлән, миңа берәр әшәкелек язалар икән, ниндидер әшәкелек күрәсең икән, бу миңа түгел, ә синең үзеңә кагыла, сине характерлый дип җавап бирәм. Шул рәвешле үзләренә кайтарып калдыру бик булыша. Сәхифәмә язылучылар тормышымның бик кечкенә өлешен генә күргәнен һәм шуннан чыгып нәтиҗә ясаганын белеп эш итәм. Алар чынлыкта нинди кеше икәнлегемне белә дә алмый, чамалый гына ала. Әгәр сәхифәдә күргәннән ниндидер тискәре нәтиҗә ясыйлар икән, бу – минем турында түгел, ә аларның үзе турында.

## БАЛАЛАРЫМНЫҢ БАШКА ДӨНЬЯДА ҮСҮЕН ТЕЛИМ

**– Егерме елдан соң гаиләгезне, балаларыгызны ничегрәк күз алдына китерәсез? Бу хакта уйланганыгыз бармы?**

– Тормышымны үзгәртеп кору тәҗрибәсе һәм рухи бөтенлеккә юлым балаларыма да тормышта бәхетнең төп чыганагы булган әнә шул бөтенлеккә ирешергә нык ярдәм итәр, дип бик өметләнәм. Әйе, балаларымның гомер юлы шактый фаҗигале башланган, алар эти-энисез калган. Тик мин үз аңлатмаларым, мәхәббәтем, җылы кочагым белән аларга бу бушлыкны тутырырга ярдәм итәрмен, шулар аша тулыканлы һәм бәхетле тормышка илтәчәк күпер төзергә булышырмын, дип өметләнәм. Мин алар өчен яхшы әни булырмын, дигән өмет белән яшим.

Үсеп җиткәч, үткәннәргә әйләнеп карамыйча, балачакларында булган хәлләрне үз хисапларына кабул итмичә, ул вакыйгаларда үзләрен, биологик ата-аналарын гаепләмичә, бәхетле яши алсыннар иде, дип телим. Кирәкмәгән гаепләү-бәяләүләр белән мәшгуль булмасыннар иде. Мин нык гаилә булып калырбыз, дип өметләнәм: бәйрәмнәргә бергә җыелырбыз, балаларым миңа оныкларымны ышанып калдыра алыр, ирем белән бергә гомер кичереп, өебезне төзеп бетерербез. Ягъни мин бергә булу юлын сайлаган мөстәкыйль кешеләрне күз алдына китерәм. Хыялымдагы гаиләм менә шундый.

Китап язуымның тагын бер сәбәбе балаларымның киләчәгенә бәйле. Мин балаларымның башка дөньяда үсүен бик телим. Ул дөньяда баланы уллыкка-кызлыкка алу ниндидер батырлык яки шундый куркыныч эш-гамәл дип түгел, ә ата-ана булуның бер ысулы буларак кабул ителсен. Хәзерге вакытта исә аларның чит бала булуы күп кешеләрдә ниндидер хорафатлар тудыра, ә мин мондый хәлнең үткәндә калуын телим. Улым-кызым үсеп җиткән заманда, ятимне уллыкка алу нормаль күренеш дип каралсын иде.

## БАЛАГЫЗ ИНДЕ ТУГАН!

**– Уллыкка бала алырга теләп, ниндидер сәбәпләр аркасында соңгы карарны кабул итә алмый йөрүчеләр өчен төп киңәшегез нинди?**

– Тәрбиягә бала алучы ата-аналар өчен яхшы бәяләмәләр яулаган мәктәп табарга һәм шунда укып чыгарга. Чөнки мондый мәктәп уллыкка бала алуны шарт итеп куймый, ләкин ул куркуларыңны, сәбәп-максатларыңны, тәрбиягә алынган балалар турындагы күзаллауларыңны тәртипкә салырга, ачыкларга ярдәм итә һәм, бәлки, икеләнеп йөри торган кешенең акылында нидер үзгәртеп тә куяр. Ә инде андый мәктәпне узып та, соңгы адымны ясарга барыбер курыкканнарга һәрвакыт шундый тарих сөйлим...

Күз алдыгызга китерегез әле: сез тәрбиягә бала алырга теләдегез, димәк, сезгә дигән бала, мөгаен, инде тугандыр яки анасы аны карынында йөртәдер, тик ул инде аңа хәзер үк кирәк түгел. Һәм менә ул дөньяга килде, ди, ә сез һаман куркып читтә торасыз. Ул сезнең өчен туган, сезнең улыгыз яки кызыгыз булу өчен туган. Ул шундый кечкенә, бер ялгызы һәм ул сезне көтә! Сез карар кыла алмыйча куркып торган арада, ул инде кайдадыр шунда сезнең белән очрашуга әзерләнә, әмма бу адымны эшли алмый, чөнки бик нәни әле, аның белән очрашуга сез генә бара аласыз.

Кызымның инде кайдадыр барлыгы, кайдадыр яшәве тойгысы, миңа күп еллар элек аны эзли чыгарга этәргеч булды һәм табарга булышты.

## Пост 1

### ЛӘКЛӘК ЯЛГЫШСА...

Сез миңа, балалар үзләренең тәрбиягә алынганлыкларын беләмени, дип язасыз. Мондый нәрсә турында сөйләргә дә куркыныч бит.

Куркынычмы? Юк. Уллыкка алуда, гомумән, бернинди куркыныч юк. Баланың – әнисе, ә әни кешенең көтеп алынган сабые барлыкка килә. Барлык ямьсез нәрсәләр бала гаиләгә алынганчы булган. Һәм бу – балаларның хатасы түгел һәм аны төзәтү дә аларга йөкләнмәгән. Шулай килеп чыкты ки, бәби алып килергә тиешле ләкләк ялгышып куйды. Менә шул чакта куркыныч иде... Әниләренең яңашәдә булмавын аңлаган вакытта балаларыма куркыныч иде. Тик боларның барысы да – артта. Ләкин булган хәлләрне сөртеп ташлый алмыйбыз. Балаларыма аларны ничек көткәнемне, эзләгәнемне сөйләү куркыныч түгел. Аларның кичерешләрен уртаклашу да куркыныч түгел, чөнки мин, өлкән кеше. Балалар үсеп җитәр дә, эти-әниләрен табып, шулар янына китеп барыр дип тә курыкмыйм. Чөнки мин балаларым өчен табып үстергән үз әниләре булуымны төгәл беләм. Һәм бу – мәңгелеккә.

## Пост 2

### БӘХЕТ НИНДИ УЛ?

Матурлыкны һәр вак-төяктә күрә белү – минем өчен бәхет әнә шундый. Иртәнге чыкның үләндә көмештәй ялтыравы, коелган яфракларның кыштырдавы, өлгергән арыш башакларының кояшта чеңләве ул. Кызымның толымыннан коңгырт чәчләрнең качып чыгуы һәм кечкенә шәфәкъ-тә аның фәрештәне хәтерләтүе. Елмайганда, Никитаның бит очларында чокырчыклар барлыкка килү. Иртән мине күрүгә, Мониканың шатлыктан арткы аяк очларына басуы һәм төлкенекедәй койрыгын болгавы. :)) Газон чапкыч артыннан тигез сусыл яшел үлән теземе калуы һәм җәйнең татлы хуш исе таралуы. Күлдәге болытлар чагылышында яңгыр тамчыларының божралар ясавы. Сөекле иремнең соры күзләре тирәли барлыкка килә торган елмаю җыерчыкларының нур чәчүе. Чи балчыкка абага яфракларыннан сырлы бизәкләр төшүе. Кояш нурларының агач ботаклары аша үтеп чыгып, йөзебездә сипкелләр белән ярыша-ярыша биешүе... Һәр тапкырында мин сокланып катып калам, елмаям, тирән сулыш алам да төсле бәхет ташларын мәңгелеккә саклау өчен йөрәк сандыгына салып куям. Авыр чакта мин аларны берәм-берәм хәтерләп-капшап, бер тулы учка җыям да йөрәгемнең салмак тибешендәге юатуга колак салам: «Бар да яхшы, Катя. Хәзер инде барысы да яхшы!» – ди ул.

## Пост 3

### ГАИЛӘБЕЗНЕҢ ТУГАН КӨНЕ

Алты ел ирем белән бер парда биибез. Гаиләбезгә исә ике ел. Артыбызда йорт калкып чыкты, тирә-ягыбызда бакча пәйда булды, ә яңашәбездә көн арты көн балалар, песиләр үсә, шуларга өстәп кош-корт һәм иң шәп эт тә бар. :) Ике ел эчендә – шундый кечкенә дә, һәм инде шундый зур да гаилә! Ул көн саен ныгый барсын иде! Монда тагын нәрсә өсти алам... Барысын да дөрес эшләдек бит, әйеме! :) Дәвам итәбез!

## Пост 4

### БАЛАЛАРЫМ ҮЛӘН КЕБЕК ҮСӘ

Дөресрәге, түтәлләрдәге яшелчәләр кебек. :) Шакмаклар яки курчаклар белән уйнаганнарыбыз турында хатирәләрем бик аз, ә аның каравы бакчага кагылышлары – муеннан. Бер яшьлек Линка белән ничек бәрәңге утыртубыз, нәни Никита белән борчак чәчүебез турында. Менә кызым петунияләргә су сибә, менә кечкенә чиләгенә кура җиләге җыя. Менә помидор үсентеләре утыртам, ә улым минем арттан аларны йолкып бара. :)) Балаларыма әнә шундый балачак теләдем дә мин. Өйдән яланаяк чыгып, чыклы үләндә тәпиләү, әтәч белән бергә кикрикүк кычкыру һәм оядан иртәнге ашка җылы, төсле йомыркалар алып керү, кура җиләге, бакча җиләге өлгергәнен көтү, эт белән ял итеп йөрү, күлләвектәге чукмарбашларның койрыкларына төртү... Әни кеше белән үсенте утырту, әти кеше белән газон чабу. Яңгыр астында бергәләп сикерә-сикерә, күк күкрәгәннән дә көчлерәк итеп чиный-чиный уйнау... Балаларымның ташландык хәлен бик яхшы хәтерлим. Хастаханәдәге палата, аның кәгазь белән ябыштырылган тәрәзәсе дә исемдә. Төсләре уңып беткән биләүсәле кувезларның тыгыз рәтләрен дә онытмыйм. Сабыйларның битараф, пыяла карашын хәтерлим. Онытасым килә, әмма моны беркайчан да булдыра алмам шикелле...

Әлеге ике сабыйның яңашәмдә, түтәлдәге кебек үсүенә әчке шатлыгым арта гына бара. Алар инде башкача булганын хәтерләмиләр дә.

## Пост 5

### ПРИЮТТАН АЛЫНГАН ЭТ

Иске такталардан корылган койма, йозаклы ике капка аша үтеп, тернәкләндерү базасы территориясенә кердек. Каршыбызга төрлечә өрә-өрә эт өере чаба. Кайсы – дүрт аяклы, кайсы – өч. Кайсыдыр колаксыз я күзсез. Алар бөтенләй явызлыкны белми иде. Күңел төпкеленә күз салып, «минем хуҗам түгел микән» дип белешергә генә тырышалар. Мин монда Кукла дип йөртелгән кечкенә саргылт маэмай янына килдем. Базага ул ике күзе дә шеш килеш эләгә. Тагын бер-ике атна соңарса, бөтенләй сукыраер иде, тик вакытында коткарып калалар. Көчеккәй бер читлектә, почмакка сыенып ята иде. Сузылган кулымны тыныч кына иснәде дә ялап алды. Күземә карамады да. Гәрчә муенчаклы бауда тыңлаучан һәм эшлекле кыяфәттә атласа да, гомумән, ул миңа бөтенләй карамады. Кушканны үтәп, машинага кереп утырды да база белән мәңгегә хушлашты. Өйгә кайтышлый, бөтен белгән эт исемнәрен кычкырып әйтеп бардым. Баксаң, аның исеме Моня икән. Ярый соң, Моня икән, Моня булсын, Моника. Манюня. :) Безнең гаиләгә рәхим итегез! Безгә син генә җитми идең! :)))) ■

# ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕЛӘР ӨЧЕН БАЛАЛАР БАКЧАСЫ

3

**Илья Школьников – үзенчәлекле бала әтисе. Ул үзе белән әнә шулай дип таныштыра. Аның гамәлгә ашырырга теләгән проекты миллионнар белән исәпләнә. Кондуктив балалар бакчасы – Россиядә беренче, һәм ул, башка бөтен яңа нәрсәләр кебек үк, иң беренче чиратта, Казанда барлыкка килергә тиеш. «Чөнки Казанда сине ишетергә мөмкиннәр, – дип саный Илья. – Башка төбәкләрдә алай түгел». Бу, әлбәттә, безнең каһарманга үзенчәлекле балалар бакчасы төзелешен башлар өчен бердәнбер сәбәп түгел. Беренче сәбәбе – бала туу һәм аның дәваланулар белән үтә торган кыска гына гомерендә очраган кыенлыклар.**

## НӘРСӘДЕР ЭШЛӘРГӘ КИРӘК

– Минем улыма дүрт яшь, исеме – Костик. Ул кулда булганда, сез аның нинди икәнен берничек тә күрә алмассыз. Аның интеллекты менә дигән, гәрчә башта аңа ДЦП диагнозын куйганнар иде, әмма аның психомоторик үсешендәге тоткарлыкларның сәбәбе башка булып чыкты. Ул аякларын һәм кулларын селкетә алсын өчен, безгә бик күп акчалар түгәргә кирәк. Аның каравы, без андый балалар белән ничек эшләргә икәнне беләбез. Әлегә ул бакчага йөрмәсә дә, сигез яшь тулгач, ул башкалар белән беррәттән мәктәпкә барачак. Ни өчен сигезме? Минемчә, баланың балачагы озаграк булган саен, яхшырак. Минем баланың исә беренче дүрт елында балачагы булмады да – барлык үзенчәлекле балалар кебек, аны да һәрвакыт дәвалап торалар бит. Ул бала түгел, ә пациент. Көн саен анализлар, табиблар, курслар. Каядыр алып баралар, нәрсәдер эшлиләр, моны тот, тегене... Кайчак бик авыр була, куркыныч хәтта. Балаларны тернәкләндерү үзәгенә алып килгәч, игътибар итсәгез, алар кабинетка керү белән кычкыра, елый башлый... чөнки аларга куркыныч, авыртa, балалар олыларның алардан ни көткәнен, ни өчен эшли белмәгәннәрен эшләргә мәҗбүр итүләрен аңламый. Ә аң ягыннан аларның бар да тәртиптә. Алар анализлый һәм нәтиҗәләр ясый – үзләренә беркем дә ярдәм итмәячәгенә төшенә. Кызганычка каршы, без әлегә андый балаларга ничек ярдәм итеп булуын белмибез. Ләкин нәрсәдер эшләргә кирәк икәнен ачык беләбез.

**– Үзенчәлекле балалар өчен үзенчәлекле балалар бакчасы булдыру идеясе шуның өчен барлыкка килдеме?**

– Әйе. Безгә Израильдән кондуктив педагог – Ида Игра килде, ул биредә, Казанда, безнең педагогларны балалар белән эшләргә өйрәтәчәк. Андый белгечне бирегә чакыру җиде миллион сум тора. Бу эштә бөтен нәрсә миллионнар белән исәпләнә. Күрәсең, кондуктив педагогика Россиядә шуның өчен дә тернәкләнеп китә алмагандыр: нәрсәгә генә тотынсаң да, миллионнар кирәк.

## ТАУ МӨХӘММӘТКӘ БАРМАГАНДА...

**– Сезнеке ничек килеп чыкты? Сез миллионермы?**

– Әкрен-әкрен, бер-бер артлы, хаталар өстендә эшли-эшли. 2018 елның июнендә без Израиль белгеченә – Джудуга эләктек. Аның үзенчәлекле балалар белән эшләү тәҗрибәсе бик зур. Ул Түбән Новгородта кабул итә иде. Безгә бик ошады. Бала бөтенләй еламады, нәтиҗәсе дә шунда ук күзгә күренерлек булды. Ул икенче килгәндә, без аңа языла алмадык. Аңа эләгергә теләүчеләр буа буарлык иде! Һәм менә хатыным һәм балабыз белән һавада йөргәндә башка бер идея килде: әйдә, белгечләрне үзебезгә чакырып карыйк, дим. Хатыным тәрҗемәче, укытучы минем, инглиз, немец, итальян телләрен белә. Шуңа да чит ил белгечләре белән аралашканда, кыенлыклар булмады. Ярты ел төрле белгечләр белән сөйләшүләр алып бардык, барысы да баш тартты. Безне белмиләр,

Фото: Александр Ефремов

безнең турыда мәгълүмат юк, чакырып китерер өчен үзәгебез дә юк. Бары тик Берлиннан Эрз Пилз гына килергә ризалык белдерде. Килде, башта һәрнәрсәгә сак карады. Әмма балалар янында ул саклыкның эзе дә калмый иде. Без бер тернәкләндерү үзәгендә арендага кабинет алдык, сигез көнгә ул сигез баланы кабул итте. Безнең балаларның перспективасы бар, алар белән шөгыльләнергә кирәк, диде. Без аңа шәһәрне күрсәттек, безнең кар көртләрен һәм... авыл хуҗалыгы министрлы бинасын фотога төшерде, бик ошады аңа. Хинкали ашарга алып бардык. Аңа безнең халык ошады. «Руслар бик сөйкемле», – диде. Һәм: «Тагын кемнәрне чакырдыгыз?» – дип сорады. Без чакырылганнарның исемлеген күрсәттек. Ул безгә аларның барысын да белэм, диде һәм һәркайсына шалтыратырга вәгъдә бирде. Сүзендә торды. Тагын берничә көннән безнең кулда Израиль, Испания, Германия,Франция, Бельгия кебек илләрдән килергә әзерлек белдергән иң шәп белгечләрнең исемлеге бар иде инде.

Апрельдә безгә Тель-Авивтан Ида Игра килде. Ул вакытта шаккатырды ул безне... Мәсәлән, балагыз белән нәрсә булды, дип сорый.

– Аягына басмый...

– Бөтенләй дәме?

– Бөтенләй дә.

Баланы алды да аягына бастырды һәм җибәрде:

– Нигә балагыз турында шулай дип әйтәсез? Менә бит баса! Ә нәрсә ашатасыз?

– Блендер аша гына чыгарып бирәбез.

– Кит инде! Мә әле, үскәнем, пәрәмәч ашап кара. Менә бит, ашый...

Миңа аның баланы мөмкинлекләренә карап бүлмәве ошады. Ягъни без инвалид кеше күрсәк, шунда ук аңа карата аерым мөнәсәбәт булырга тиеш дип уйлыйбыз. Ә аның өчен барысы да тигез. Израильдә бик күпләр шулай итә, диләр, чөнки алар кечкенәдән барысы бергә – бакчада да, мәктәптә дә, эштә дә. Алар моның норма булуына балачактан өйрәнә: үзенчәлекле балалар юк, бары тик төрле балалар гына бар. Алар гарип түгел, сәер түгел, куркыныч түгел, алар белән уйнап була, һәм алар нормаль балалар. Бу, әлбәттә, эти-әниләр өчен дә сынау – әгәр синең үзенчәлекле балаң гадәти балалар белән бер мәктәптә укый икән, аңа аерым игътибар булмаячагын да кабул итәргә кирәк. Башка балалар белән беррәттән аның башына портфель белән менеп төшәргә дә мөмкиннәр, шулай ук шаяртачаклар да – үпкәләргә кирәкми.

Ида Игра беренче тапкыр килгәндә: «Ничек сездә кондуктив балалар бакчасы юк? Ачыгыз!» – диде. Андый бакча ачу турындагы идея тынгы бирмәс булды. Бу исә иганәчеләр өчен шундый зур акчалар. Әлбәттә, ул акчаларны үзенчәлекле балаларның эти-әниләреннән алып була, күпләр түләргә дә әзер, әмма ул вакытта гадел булмаячак: акчалы кешеләр бакчага йөри алачак, акчасызлар – юк. Шуңа да катлаулы юл белән барсак барабыз, әмма бакча бушлай булачак, дип хәл иттек.

## ӨЧ ПИЛОТ ТӨРКЕМ

**– Ничә урынга исәпләнгән ул?**

– 120–150 урынлы бакча турында сүз бара. Бина мәсьәләсендә мэрия ярдәм итте – 220 кв. метр, анда башта өч төркем туплыйбыз. Статистика буенча Казанда ДЦП диагнозлы 1408 бала бар. Моңа тагын шушының яртысын, хәтта күбрәк тә өстәп була. Тагын генетик авырулы, шул исәптән эпиактивлык булган, эпилепсияле балалар. Ул авырулар да психомоторик үсешне тоткарлый. Ачылгач, төркемнәрдә алтышар бала булачак, ягъни 18 бала белән башлап җибәрәчәкбез. Безнең бурыч – безнең өчен бөтенесен дә эшләргә кирәкми, безгә ярдәм итәргә генә кирәк, дигәнне аңлату.

**– Педагогларны кайдан алачаксыз?**

– Кондуктив педагог булырга Венгриядә алты ел укыталар. Мондый план бар. Беренче тапкыр Ида безгә өч айга киләчәк: ике ай укыта, бер ай педагоглар белән бакчада эшли, анда конкрет очракны һәрбер бала мисалында сүтеп җыячаклар. Булачак педагоглар тупланган, барысы да педагогик белемле, кайберләренең башлангыч медицина белгечлеге бар. Киләчәктә алар таяныч булачак. Кондуктив педагог булырга теләгән кешеләр белән сөйләшкәндә, беренче эш итеп, шуны әйтәм: хәзер бу – сезнең тормышыгыз, шуны аңлагыз, дим. Ягъни мин аңа шундый һөнәр бирәм икән, соңыннан «Бу минеке түгел», диярлек булмасын.

Россиядә бер кондуктив педагог та юк. Һәм менә алар барлыкка киләчәк. Балалар бакчасы өчен әлегә шундый 15 педагог кирәк. Норматив буенча – ике балага бер педагог. Ягъни төркемдә алты бала һәм өч педагог. Нәкъ менә шушы нәтиҗә бирә. Алга таба, 2021 елда, без Иданы ике айлык интенсивларга чакырачакбыз. 2022 елдан мин инде икешәр педагогны Венгриягә укырга җибәрә башлаячакмын. Әгәр дә безнең яхшы дипломлы белгечләребез булсын, дисәк, уку кирәк. Дипломлы кондуктив педагоглар миңа 2028 елга гына кайтачак. Ягъни алты ел укырга кирәк, әгәр дә син үзенчәлекле баланың этисе яки әнисе икәнсең – биш ел.

**– Бу могҗиза кайчан булачак? Бакча кайчан ачыла?**

– Шушы ел ахырында. Әлеге вакытта бинада ремонт эшләре бара. Ул безгә бик туры килә, элек анда кибет урнашкан булган. Витриналы тәрәзәләр белән. Якты, метро станциясе, парк янәшәдә генә, каршыда балалар өчен мәйданчык бар. Кайчандыр аны су баскан булган, хәзер без идәнен яңадан кубарабыз, ә ул 20 сантиметрлы бетон, чүкеч белән ватарга кирәк. Штукатуркасын да кубарабыз. Аннан соң егетләр килеп, газ пушкалары белән эшләп чыгачак, гөмбәгә каршы эшкәрткәч, киптерәсе һәм өр-яңадан тигезләп, идән җәясе, штукатурлыйсы, чыбыклар сузасы була.

## ДУСЛАР, МОГҖИЗАГА ЫШАНЫРГА КИРӘК

**– Ә ул егетләр үзләре теләп киләме, волонтерлармы? Кемнәр алар?**

– Алар минем дусларым. Вакыт-вакыт волонтерлар да ярдәмгә килә. Без барыбыз да шундый эшләр белән шөгыльләнүчеләр, Кыш бабайларга, Пасха куяннарына, могҗизага ышанабыз... Чөнки могҗизага ышанмыйсың икән, мондый эшкә тотынма да.



**– Сезнең улыгызга дүрт яшь. Ел ахырында бакча ачылган очракта, ул анда 2–3 ел гына йөриячәк, алга таба аның мәктәпкә барыр вакыты җитә. Мәктәпне каян алырга?**

– Димәк, мәктәп ачачакбыз.

**– Сез бу эшләрнең барысын да балагыз өчен башлагансыз, ә балагыз икенче баскычка күтәрелсә яки тулаем сәламәтләнсә, сез алга таба болар белән шөгыльләнәчәксезме?**

– Әлбәттә, чөнки хәзер инде бу яшәү рәвеше. Әгәр дә минем балам сәламәт туган булса, мин, мөгаен, бу өлкәдәге проблемалар турында ишетеп тә белмәс идем. Һәм алар белән шөгыльләнмәс тә идем. Мин боларны балам хакына дип эшлим, киләчәктә аның гаиләсе булсын, эшкә йөри алсын, үзе теләгәнне эшли алсын дип. Үзең теләгән эш белән шөгыльләнү – олы бәхет бит ул. Мин гомерем буе үзем яраткан эшне эшләдем, яратмаган, үземә ошамаган эштә бер генә көн дә эшләгәнем булмады. Улымның да шулай яшәвен телим. Миңа аны кулларын, аякларын хәрәкәтләндерергә өйрәтә торган фельденкрайз белгечләре кирәк. Ә аяклардан, куллардан файдаланыр өчен – кондуктив педагоглар. Бездә аларның ни тегесе, ни бусы юк. Юк икән – булдырырбыз. Бакча юк – бакча ачарбыз. Мәктәп кирәк икән – төзербез. Университет кирәк булса – мөмкин булмаган эш юк. Шәһәр кирәк икән – шәһәр дә булыр. Мин яраклаша белмим, мин үземә уңайлы итеп яраклаштырам.

## БАШТА НӘТИҖӘ

**– Ата-аналар сезгә мөрәҗәгать итә башладымы инде?**

– Әйе, мөрәҗәгать итәләр. Хәтта исемлекләр төзелгән дигән имеш-мимешләр дә йөри. Әйе, әлеге балалар бакчасына йөриячәк балалар төркеме бар, мин берничә урынны үзем теләгән балага бирү хокукын яуладым дип саныйм. Алар – минем бала, педагогларның балалары һәм тагын ике-өч бала. Калган урыннар бар әле.

Әмма безгә башта нәтиҗә күрсәтергә кирәк әле. Менә без моны эшләдек, моны без үзебез оештырдык, сез менә боларына ярдәм иттегез, калганнарын без үзебез үттек, хәзер инде безгә тагын да зуррак бина бирегез, дип барыр өчен. 120–150 балага җитәрлекне, мәсәлән. Ул чагында инде, әйе, мин иганәчеләрдән акчаны ремонтка гына түгел, автобуска да сораячакмын. Балаларның бөтен нәрсәсе дә булсын өчен. Һәм бу бакчадагы һәр урын, әйе, иганәченең имидж рекламасы астында сатылачак – булсын! Сезнең логотип педагогларның формасында булсынмы – проблема юк. Боларның барысы да кадрда булсын, бу бит Россиядәге беренче кондуктив балалар бакчасы. Табигый, безнең белән кызыксыначаклар. Ул кызыксыну хәзер үк бар инде. Июль аенда гына да инстаграмда миңа язылучылар саны 495 иде, бүген анда 1500. Бу сан көн саен артып тора.

**– Кондуктив балалар бакчасы баш мие сакланган балаларга исәпләнгәнме?**

– Биредә кондуктив балалар бакчасы булачак!

– Барысы өчен дә. Кондуктив педагогика балаларны бүлми. Ягъни ятып торганнар, утыра торганнар, басып торучылар төркемнәре булмый. Катнаш була. Әлегә без 2–6 яшьлек балаларны алабыз. Сигез сәгатьлек эш көненә. Бала янында тәүлек әйләнәсенә, атнасына җиде көн була торган әниләрнең дә тормышын җиңеләйтәчәк ул, алар эшкә урнаша алачак.

**– Акча эшли башлаячаклар. Аларның күпчелеге ялгыз ана бит әле...**

– Ә ни өчен сез этиләр юк дип уйлыйсыз? Эш эти кешенең куркып калуында гына түгел... Әйе, яртылаш очракларда шулай ул. Ләкин эш анда гына түгел. Хатын-кыз тәүлегенә 24 сәгать, атнасына җиде көн бала белән. Психология ноктасыннан торып караганда, ишелеп төшкән проблемалар алдында югалып калалар. Ачыктан-ачык әйткәндә, психик яктан тыныч кеше өчен дә бик авыр. Хатын-кыз кемгә чыгара инде ачуын? Табигый, иренә. Кредитларын, фатир өчен, әнә шул курслар өчен түли торган ир монысына да түзәргә тиеш булып чыга... Бөтенесе дә түзә алмый. Әйе, безнең эштә этиләр аз. Әмма минем бик тә эти буласым килә иде. 29 яшемдә эти булдым. Һәм бик шатмын. Мин дөньядагы иң әйбәт баланың иң бәхетле этисе! Әлегә миңа балалары бакчага йөриячәк ике эти кеше ярдәм итә. Әмма мин балалар бакчасы эшенә эти-әниләрне җәлеп итмәскә тырышам. Чөнки мин барысының да балаларын ала алмаячакмын, кемгәдер урын юк дип әйтергә туры киләчәк. Ничек әйтәчәкмен аннан соң?

## ВОЛОНТЁРЛАРДАН ГРАНТЛАРГА КАДӘР

**– Хәзер сезнең турыда мәгълүмат дулкыны күтәрелгәч, ярдәм итәргә теләүчеләр бармы?**

– Әйе. Ләкин бу иганәче ярдәме түгел, күбрәк хәйриячелек. Мин аларны да шатланып кабул итәм. Акча күчерәләр, ике капчык цемент килеп алырга тәкъдим итәләр, тагын ниндидер материаллар. Киләм, алып китәм.

**– Төзеп бетергәч, сезгә җиһазлар кирәк булачак...**

– Җиһазны үзем эшлим. Кайберәүләр: «ГОСТ буенча кирәк бит, ничек инде үзегез?» – дип сорый. Кондуктив җиһаз буенча ГОСТ табып китерегез! Сәламәтлек саклау министрлыгында кондуктив педагогның кем икәнен белә торган берәр кешене булса да табып бирегез! Фельденкрайзның, АБМның һ.б. «Нәрсә соң ул кондуктив педагогика?» – диячәкләр...

**– Википедиядән алган белемнәр буенча, ул үзәк нерв системасы бозылган балаларның һәм өлкәннәрнең хәрәкәт итү һәм психик функцияләрен тергезүгә юнәлтелгән процесс...**

– Әгәр инде Википедиядә язылган сүзләр белән сөйләшсәк, дөрес. Нәкъ менә безнең балаларга килгәндә, алда әйткәнемчә, реабилитолог аякларны, кулларны хәрәкәтләндерергә өйрәтә, ягъни ул баланы кулларын һәм аякларын контрольдә тотарлык итә. Әмма реабилитолог юынырга, ашарга, ыштан кияргә һәм салырга, бәдрәфкә йөрергә, төймәгә басарга, кулын юарга, ашарга җылытырга өйрәтә алмый. Боларның барысына да кондуктив педагогика өйрәтә. Һәм иң мөһиме: анда бала бала булып кала. Процесс гадәти балалар бакчасында үтә торган балачакка интеграцияләнгән. Җырлар, рәсемнәр, уенчыклар, урамга чыгулар... Барысы да билгеле бер сценарий буенча, билгеле бер мотиваторлар белән эшләнә.

Балалар өчен даими рәвештә үсештә булу, туктап калмау, яңадан-яңа күнекмәләргә өйрәнү зур этәргеч булып тора. Әйе, кемдер аннан үз аякларына басып атлап чыгып китәчәк, мөстәкыйль рәвештә ашый алачак. Бу зур җиңү булачак. Әлегә бу өлкәдә бездә Хогвартс юк... ДЦП дәваланмый. Без шаман да, сихерче дә түгел. Әмма бу балачак өчен бакча, анда йөргән баланың җәмгыятьтә тулы канлы әгъза булу шансы арта. Бу зур эш, катлаулы һәм озакка сузылган. Әгәр кондуктив педагоглар, фельденкрайз-терапевтлар республиканың грантлар программасына керә алса – шәп булыр иде.

## ЭЗ

**– Димәк, бу сезнең миссия, шулаймы?**

– Мин хәзерге вакытта шушы эш белән шөгыльләнергә телим. Шушы эштә эз калдырырга телим.

**– Ун елдан соң сез бу эзне нинди итеп күрәсез?**

– Ун елдан соң бер генә бакча, бер генә мәктәп итеп күрмим. Алар күп булачак. Һәм тагын ун елдан соң андый бакчаларга 500–600 баланы кабул итәчәкләр. Аның грант программасы булачагына да шигем юк. Кондуктив педагог балалар бакчасында 50 мең сумнан да азрак алмаячак – монысына да шикләнмим. Минем педагоглар нәкъ шундый хезмәт хакыннан башлаячак. Чөнки ул физик яктан да (балаларны күтәреп йөртергә, утыртырга, йоклатырга кирәк булачак), рухи яктан да бик авыр хезмәт. Өстәвенә, даими рәвештә укырга, өйрәнергә кирәк булачак. Педагог үз эшен ихлас яратырга, балаларны яратырга һәм кызганмаска тиеш. Һәм бу искиткеч кызыклы эш! Чөнки мин үзем реабилитолог булырга укыячакмын. Укып чыгам да шушы балалар белән эшләячәкмен.

## ДӨНЬЯ ЯХШЫ ЯККА ҮЗГӘРӘЧӘК

**– Хәзер көчле тавыш белән «Шушы эш белән сез дөньяны яхшы якка үзгәртәсез» дип әйтсәне киләме?**

– Дөнья түгел. Нибары берничә кеше. Боларны күреп, дөнья яхшы якка үзгәрер дип өметләнәм. Кешеләр инвалидларга башкача карый башларлар, аларның нәкъ шундый ук кешеләр икәнен, бары тик аларга азрак ярдәм итәргә кирәген аңларлар. Инвалидлар үзләре дә фикерләү рәвешен үзгәртсә, аларга беркем дә бернәрсә дә тиеш түгел дип уйлый башласа – искиткеч. Гомумән, мин шундый фикердә: әгәр дә син бала өчен нинди дер яхшылык эшләргә телисең икән, елап утырма, тор да эшлә. Мин дә бернәрсә дә белми идем, бары тик эшли башладым һәм бетте. Ир кешенең «Эшли белмим» дигәнен күралмыйм. Ир кеше: «Ничек эшләргә икәнен күрсәт, эшлим!» – диярга тиеш. Алар белән сүзне: «Мин кемдер сезгә нәрсәдер тиеш дип саный торганнардан түгел», – дип башлыйм. Ихтимал, мин кемгә салым түлим, алар миңа тиештер. Әмма бизнес һәм кешеләр миңа берни дә тиеш түгел. Миңа да, безнең балаларга да.

## ИШЕТКӘНЧЕ КЫЧКЫРДЫМ

**– Ничек уйлыйсыз, татарстанлылар кеше хәленә керүчән халыкмы?**

– Бу эшне нәкъ менә Татарстанда башлавым өчен бик шатмын. Чөнки нәкъ менә Татарстан – татар, рус, яһүд, азәрбайҗан һәм башка халыкларның бердәмлеге – дөнья нинди булырга тиеш, шуның үрнәге. Израиль кешеләре (ә алар гарәпләр белән ничә ел сугыша?) миннән, сез анда ничек бергә яши аласыз, дип сораганда, болай дип җавап бирәм: «Татарстанда кеше турында сөйләшкәндә, аның милләте турында иң соңгы итеп искә төшерәләр, әгәр бөтенләй искә төшерсәләр». Чөнки ул әһәмияткә ия түгел. Татарстанлылар мәчеткә яки чиркәүгә йөри, һәм берәү дә кемдер икене гыйбадәтханәгә йөри дип, аны үтерергә кирәк, дими. Яки икенче милләттә дип, сугышырга җыенмый. Чиркәүләр, мәчетләр, синагогалар, католик чиркәүләр – болар өчен мин сөенәм генә. Миңа Татарстан ошый. Мин Питерда туып-үстем. Анда минем туган җирем, анда сулыш алуы да бүтән. Әмма миңа Питерга күчеп, шушы ук эш белән шөгыльләнә, дисәләр, мин баш тартыр идем.

**– Ни өчен?**

– Аңлыйсызмы, монда сине ишетәләр. Анда – юк. Ягъни биредә сине һәрвакытта да ишетәләр – бу функция җайга салынган. Миңа Казанда бик уңайлы. Гәрчә 2001 елда бирегә күчеп килгәч, күңел төшенкелеккә бирелде. Питерга дуслар янына кайтасы килде. Миңа биредә ошамады. Нинди авылга алып килделәр соң мине дип уйлый идем! Әмма Казан көннән-көн матурая бара. Хәзер инде мин чит ил кунакларын яр буена алып киләм – алар таң кала! Йомгаклап әйткәндә, бу шәһәрдә безнең барысы да килеп чыгачак! ■



**БЕЛЕШМӘ:**

Мостай Кәрим (Мостафа Сафа улы Кәримов) 1919 елның 20 октябрендә Башкортостанның Чишмә районы, Келәш авылында дөньяга килгән. Ул – Социалистик хезмәт герое, РСФСРның атказанган сәнгать эшлеклесе, Башкортостанның халык шагыйре, Салават Юлаев премиясе лауреаты.

1941 елда К.И.Тимерязев исем. Башкорт дәүләт педагогика институтының тел һәм әдәбият факультетын тәмамлый. Бөек Ватан сугышы башлангач фронтка китә. Бөек Ватан сугышыннан соң тормышын тулаем иҗатка багышлый.

1930 елларда ук яза башлый. 1938 елда «Отряд кузгалды» дигән беренче шигырь җыентыгы нәшер ителә; 1941 елда «Язгы тавышлар» дигән шигырь китабы чыга. Барысы 100дән артык шигърият һәм проза китаплары, 10нан артык пьеса җыентыклары дөнья күрә.

Мостай Кәрим 2005 елның 21 сентябрендә бакыйлыкка күчте. Уфаның мөселман зиратында җирләнгән.

# ТАШ ӨСТЕНДӘ ГӨЛЛӘР ҮСТЕРГӘН ШАГЫЙРЬ

**«Алла белән ничек сөйләшергә кирәклекне беләм мин. Ул шаштырып мактаганны ярата. Моны мин әллә кайчан инде Олы инәемнән төшенеп алдым.**

**– Әй, Ходаем, – дим мин. – Кодрәтең дә, рәхимең дә чиксез синең. Бар өметебез синдә генә. Изге ихтыярың белән сабыйлар тагы, тагы дөньяга яралсын. Сиңа иман китерер гөнаһсыз җаннар тусын!»**

**Автор:** Мөршидә Кыямова

Бу юллар Мостай Кәримнең «Озын-озак балачак» автобиографик повестеннән. Күп балалы гаиләдә тәрбияләнгән шагыйрь үзе дә, «мин иркенлектә үстем, мине орып-куркытып үстермәделәр. Ә бу сыйфат иҗатта иң мөһиме дә. Сәләт ул нинди дер богауларга, тәнкыйтьләргә бикләнеп, талант дәрәҗәсенә ирешә алмый», – ди.

Мостай Кәримне кечкенә чагында авыл малайлары Кендек дип үртәп йөрткәннәр. Бу үзенчәлекле кушамат аңа Олы инәе белән бала таптырырга ияреп йөргәнгә күрә бирелгән. Булачак шагыйрь тормышында, аның шәхес булып җитлегүендә Олы инәе дә зур роль уйнаган, күрәсең, чөнки әдипнең прозасында иң төп әсәрләреннән саналган повестьта әлеге образ төп урынны били.

Фотолар Мостай Кәрим исемендәге фондтан алынды

*«Олы инәем әле дә булса минем берчә кояшлы, берчә болытлы, берчә чәчкәле, берчә кар-буранлы язмышым яланының уртасында басып тора. Аның тирәсендә минем бөтен язмышым әйләнә. Ачык хәтерлим: гомеремдә мине беренче тапкыр җитәкләп алган кул – аның кулы булды. Аннан соң без җитәкләшеп бик күп йөрдек»*, – дип яза әдип әтисе Сафаның беренче хатыны турында.

«Әткәйнең балалык чоры күңелле һәм бәхетле мизгелләргә бай, – ди Мостай Кәримнең кызы Әлфия Кәримова. – Алар йортында Аллаһны һәрчак мәрхәмәт иясе буларак зикер иткәннәр. Балалар «Аллаһы орыр, Аллаһы җәзалар!» – дигән сүзләрне түгел, «Аллаһы ярдәм итәр, Аллаһы рәхимле, ул булышыр», – дигәнне ешрак ишеткән. Без үскәндә дә шулайрак булды. Олылар ачыктан-ачык Аллаһы Тәгалә турында сөйләшмәсәләр дә, без һәр вакыт рәхимле Аллаһның гаиләбез тормышында катнашуын тоеп үстек...»

## УКУЧЫГА КАНАТ КУЮЧЫ КАЛӘМ ИЯСЕ

Мостай Кәрим иҗат иткән әсәрләр дөнья кыйммәтләре үзгәргәч тә үз актуальлеген югалтмый, аларда тормышның тирән фәлсәфәсе, замана укучыларына да аңлаешлы, кызыклы булып кала бирә. Әсәрләре бүгенге көндә дә төрле телләргә тәрҗемә ителүдән туктамый. Киң кырлы иҗатчы – чын мәгънәсендә халыкчан әдип.

Башкортостанның халык язучысы шигырьләренә күп кенә җырлар да иҗат ителгән. Ә драма

Мостай Кәрим. 1940 ел.

1945 елның апреле. Балатон күле. Венгрия.

Хатыны Рауза белән. 1946 ел.

әсәрләре төрки халык театрлары сәхнәсеннән төшми. «Озын-озак балачак» әсәрен Мостай Кәримнең улы Илгиз Кәримов русчага тәрҗемә иткән. Биредә автор балачагы вакыйгаларын тасвирлый. Әлеге әсәр 2004 елда кино итеп тә төшерелгән.

Повестьтагы вакыйгалар башлыча язучының туган авылы Келәштә бара. Әсәр китап булып басылып чыккач, авыл халкы андагы образларны барларга тырышкан, кайберләре үзен, күршеләрен дә таныган. Бу автобиографик әсәр булса да, анда язучының фантазиясенә күп урын бирелгәнен дә истән чыгармаска кирәк. «Ә менә үз гаиләсе турында барсын да тормышыннан алып язды, – ди язучының кызы. – Мостай Кәримнең әтисе Сафаның ике хатыны булган. Иренә икенче хатыны Вазифаны беренче хатыны үзе сайлаган...»

Мостай Кәрим әсәрләренең жанр төрлелеге аның талантының бай мөмкинлекләрен раслый. Фикер иясе буларак ул әсәрләрендә җитди әхлакый-иҗтимагый проблемаларны күтәрә, ирония һәм зирәклек белән кеше идеалларының нинди булуын укучыларына күрсәтеп бирә. Иң мөһиме: авторның барлык әсәрләрен берләштерә торган алтын баганасы – кешеләргә игелек кылу һәм яхшы киләчәккә ышаныч, өмет уяту. Язучы буларак укучыларына ул яхшылыкның һәрвакыт өстен чыгуын төшендерә. Ә өмет һәм ышаныч бүгенге укучыга да иң кирәкле нәрсәләр бит инде!

Мостай Кәрим драматург буларак әдәбиятта аерым урын билэп тора. Аның драмалары буенча куелган спектакльләргә тамашачы махсус йөри. Шул ук «Ай тотылган төндә» драмасы, мәсәлән, 150 дән артык театр сәхнәсендә куелган. Режиссерларның Мостай Кәрим әсәрләренә еш мөрәҗәгать итүенең сәбәбе аның әлеге дә баягы халыкчан әдип булуында да түгелме икән?

Мостай Кәримнең кайсы милләт вәкиле булуы турында еш кына бәхәсләр чыга. Ә ул үзе исә: «Минем кайсы милләттән булуымны иҗатымнан эзләгез», – дип җавап бирә торган була.

«*Тарихи яктан минем халкыма ике кыйтга – Европа һәм Азия чигендә гомер сөрү насыйп булды. Бу кыйтгалар тоташкан җир генә түгел, ике мәдәният, ике тәкъдир – Европа һәм Азия язмышлары чиге дә*, – дип яза Мостай Кәрим үзенең бер китабына кереш сүзендә. – *Мин халкымның поэзиясе Шәрык шигъриятенең нурлы төсләрен, исерткеч хуш исен, олпат зирәклеге, кырыс тормыш хакыйкате, революцион яңгырашы, Көнбатыш шигъриятенең актив зиһенен үзенә алуы турында хыялланам*».

## ГАЗРАИЛНЕ ҖИҢГӘН СОЛДАТ

Мостай Кәрим иҗатта да, шәхси тормышта да бик бәхетле кеше була. Мөгаен, «Озын-озак балачак» повестенда үзе язганча, Аллаһы белән араларын төзек тоткангадыр. Бөек Ватан сугышы гарасатында авыр яралынып та, үлем тырнагыннан котылып кала, тормышның шактый кырыс сынауларын да егетләрчә горур җиңеп чыга. Сугыш афәтләрен күргән башка фронтовиклар кебек үк, Мостай Кәрим бәрелешләр турында бик аз сөйләгән. «Олыгайгач кына, теле сүтелә башлады», – ди якыннары. Китапларына кергән эпизодлар, белгәнегезчә, күбрәк шаян, шук хәлләргә нисбәтле. «Сугышта куркыныч идеме?» – дигән сорауга:

– *Әлбәттә, куркыныч, без яшь идек, әмма без ул куркуны җиңдек. Сугыш – ул хезмәт, зур хезмәт, солдатларның фидакарь хезмәте. Күпләр аңлаганча, тактика, стратегия генә түгел. Авыр, газаплы хезмәт нәтиҗәсендә җиңеп чыктык*, – дип җавап бирә.

Хатыны Рауза белән. 1975 ел.

1941 елда, югары белем алгач, ул Ярмәкәйгә укытучы булып китәргә тиеш була, әмма Бөек Ватан сугышы башлана. Яшь язучы, Кызыл Армия сафларына алынып, Муром элемтә училищесына җибәрелә. 1942 елның маенда кече лейтенант 17 нче мотоукчылар бригадасы артдивизионына элемтә башлыгы итеп билгеләнә. 1942 елның августында авыр яралана, ярты елга якын госпитальләрдә дәвалана. Терелеп яу кырына кире кайтканнан соң, фронт газетасы хәбәрчесе буларак алгы сызыкка озатыла. 1944 елның августында өлкән лейтенант Кәримов II дәрәҗә Ватан сугышы ордены белән бүләкләнә.

Бөек Ватан сугышында катнашкан хатын-кызларга дан җырлаганын, фронтның алгы сызыгында элемтәче кызларга ничек тә ярдәм итәргә тырышканын искә алган ветеран Мостай ага. *«Сугышта, һөҗүмгә барганда, «Советлар Союзы өчен!» – дигән фразаны ишетмәдем, ә гел: «Россия хакына!» – дигән шигарьләр яңгырый иде»*, – дип әйтә торган була ул. «Рус түгелмен, ләкин россиян мин», – юллары («Россиянмын» шигыре) юктан гына язылмагандыр.

«Мостай Кәрим – шигърияттә Салават Юлаев, Муса Җәлил юлларыннан йөреп, халык азатлыгы өчен барган яуда каләм дә, корал да тотып катнашкан кеше, солдат, шагыйрь... Менә шуңа күрә фашистлар Мостай Кәримнең дә күкрәгенә төбәп аттылар, мина ярчыгының берсе – сержант Фоминда, кабердә, ә икенчесе шагыйрь тәнендә калган. Әлеге ярчыкны ул үнике ел тәнендә йөрткән. Шагыйрь бу хакта сугыш бетеп, ун ел узганнан соң гына язган... Чыннан да, мондый тетрәткеч шигырьне үнике ел буе әрнү кичергән, шул тимер эремичә дошманга үче кимемәс шагыйрь генә яза ала», – ди Татарстанның халык шагыйре Илдар Юзеев.

Кремльнең Георгий залы КПССның 19 съезды, 1952 ел. Фотода: А. Фадеев, С. Бабаевский, М. Кәрим, Н. Черкасов, В. Кочетов, А. Корнейчук.

## МОСТАЙ КӘРИМ ИҖАТЫ – КИНО СӘНГАТЕНДӘ

Атаклы әдипнең әсәрләре гади тел белән әйтсәк, кино караган кебек укыла. Гади укучы өчен үтемле фәлсәфә, милләт йолалары, шәхес кичерешләре үтә дә затлы, аңлаешлы тел белән тасвирлап бирелә. Башкортостан табигатенең мәһабәт таулары, урман-сулары, авыл халкы, аларның яшәү рәвеше күз алдына килеп баса. Шуңа күрәдерме, Мостай Кәрим драмалары төрле милләт театр сәхнәләрендә бүген дә популярлыгын җуймый. Мостай Кәрим иҗатына кино сәнгате аша килүчеләр дә әдипнең мирасын яхшы беләләр. Язучы үзе исән чакта ук инде тулы метражлы фильмнар төшерелгән. Тик автор үзе исән чагында төшкән картиналардан канәгать булмаган. Аны гаять таләпчән иҗатчы буларак хәтерлиләр. «Ай тотылган төндә» фильмын шомлы, караңгы килеп чыккан дия торган була ул. Әсәр жанры ягыннан, трагедия булса да, алай ук төксе түгел, ди аның дәвамчылары. Чыннан да, Мостай Кәримнең трагедияләрендә дә ниндидер өмет чаткысы үзен сиздереп уза, үтәр көннең атар таңы бар дигән иман уята.

Мостай аганың әсәрләренә нигезләнгән кинолар да шактый. Башкорт кинорежиссеры Айнур Әскәров төшергән «Отряд Таганок» фильмы самими җылылык белән, милли җирлектә тудырылган.«Соңгы елларда гына да Мостай Кәрим әсәренә нигезләнеп ике фильм төшерелде, – ди Айнур Әскәров. – Мостай Кәримнең барлык әсәрләре диярлек экранга чыгарырлык. Шәхсән үземә аның «Ярлыкау» әсәре ошый. Аннан хәрби темага тулы метражлы кино эшләргә мөмкин. Бәлкем киләчәктә мин моңа алынырмын да әле. Мостай Кәрим экранлаштыру өчен бик кулай. «Отряд Таганок» фильмына килгәндә, Мостай Кәрим дәвамчылары фильмны җылы кабул иттеләр. Әлфия ханым, фильмны карагач: «Әлбәттә, монда автор язмаган нәрсәләр дә күп, әмма ул аларны язарга теләр иде», – дигәч, безгә бик күңелле булды. Бу сүзләрдән соң, без картинаны Мостай Кәрим рухында эшләгәнбез икән, дигән фикергә килдек. Мостай ага әсәренә нигезләнгән фильмда авторның персонажларын, характерларын, авыл исемнәрен алдык,



Улы Илгиз белән. 2003 ел.

шул ук вакытта үз фантазияләребезгә дә ирек бирдек. Сүз дә юк, бөек кешенең әсәрләренә фильм төшерү ул һәрвакыт җаваплылык таләп итә. Теге яки бу персонажны сурәтләү катлаулы, ә инде ул персонажны якыннан белгәннәр исән чагында – бигрәк тә. Һәр кешенең үз фикере бит. Күп очракта кабул итмәскә дә мөмкиннәр. Фикерләр еш кына бик төрле була».

Соңгы араларда Россия экраннарында зур уңыш белән барган «Сестренка» («Безнең өйнең яме» әсәре буенча, режиссёры – Александр Галибин) фильмында бәләкәй Җәмилнең олы йөрәге, гади бер башкорт авылында яшәүче кешеләрнең рухи матурлыгы тасвирлана.

## МОСТАФАДАН – МОСТАЙГА

Иҗатта да, тормышта да Мостай Кәрим – үткен сүзле, һәр нәрсәгә үз карашы булган горур шәхес. Тормышта комфорт яраткан, гаиләсен дә уңайлы шартларда яшәтергә омтылган. Якыннары белдергәнчә, байлыкка омтылмаган, нинди генә зур дәрәҗәләргә, танылу, дан-шөһрәткә ирешсә дә, гади кеше булып кала белгән. Үз иҗатының халыкка барып җитүен даими кайгыртып торган. Төрле очрашулар, иҗади кичәләргә еш йөргән, төрки халыклар белән очрашкан. Җәмәгать эшләрендә дә актив катнашырга җай тапкан. СССР Югары Советында депутат булып торган.

Әдип әңгәмәдәшен тыңлый белгән. Олы шәхескә күпләр сүз катырга кыенсынып торганда да ул үзенең гадилеге белән әңгәмәдәшенә җиңеллек китерә торган булган. Мостафа – «сайлап алынган, башкалардан өстен» дигән мәгънәдәге исем. Ә безнең героебыз киресенчә, даншөһрәткә күмелеп яшәсә дә, үзен гади тоткан. Аның саллы исеме Мостафаны Мостай дип үзгәртүе дә шул гадилеккә омтылу галәмәте түгел микән әле?

Башкортостанда Мостай Кәрим фонды актив эшли. Әлеге фонд 2013 елны улы Илгиз, кызы Әлфия һәм язучының оныгы Тимербулат Кәримовлар тарафыннан гамәлгә куела. Фондның төп бурычы – башкорт теле һәм әдәбиятына ярдәм итү. «Безнең бурыч – мәгърифәтчелек, – ди Тимербулат Кәримов. – Бу фонд халык әдибе һәм аның замандашлары – Рәсүл Гамзатов, Чыңгыз Айтматов, Кайсын Кулиев һәм башкалар иҗаты белән таныштыруга юнәлтелгән. Фонд мәктәпләрдә башкорт теле, әдәбияты, тарихы буенча академик программаларга булышлык итә. Студентларга, башкорт телен өйрәнүдә уңышларга ирешкәннәргә, журналистларга ел саен ярдәм күрсәтә. Без башка милләтләрне дә хөрмәт итәбез. Татарстандагы элемтәләребез белән дә горурланабыз».

Соңгы елларын Мостай Кәрим кызы янәшәсендә яшәгән, хатыны үлгәннән соң 3 елга якын гомер иткән. Фәлсәфәче әдипнең иҗат, тормыш кыйммәтләре турында уйланулары оныгына – Россиянең танылган эшкуары Тимербулатка да күчкән. Данлыклы бабасыннан күп нәрсәләргә өйрәнеп калганын Тимербулат үзе дә горурланып сөйли.

Атаклы бабайның «вакланма» дигән сүзе булган. Тормышта вак-төяктән иң мөһимен аера белергә кирәклеген балаларына да, оныкларына да төшендергән ул. «Теләсә нинди мәсьәләне хәл итәргә мөмкин, үлгән кешене генә терелтеп булмый», – дияргә яраткан. Беркайчан да, бернәрсәне дә ашыгып эшләмәгән, шул ук вакытта барысына да өлгергән. «Хәтта шоферны да көттерми иде, биш минут алдан киенеп куя, төгәл кеше иде», – ди кызы.

Нияз Кәримовта да (Илгизнең улы) бабасының чалымнары мулдан. Ул рәсем ясый, музыка иҗат итә, каләм тибрәтә. Иҗади егет. Шунысы да игътибарга лаек: Мостай Кәрим дәвамчылары барысы да гыйлемгә омтылучан, китап укырга яраталар.

Узган ел Башкортостанда Мостай Кәримнең 100 еллыгы уңаеннан зур чаралар узды. «Без Мостай Кәримнең йөз еллыгын Башкортостан өчен генә түгел, бөтен Россия өчен дә халык бәйрәме итәргә телибез», – дигән иде Тимербулат Кәримов. Ә быел Татарстанның башкаласы Казанда Мостай Кәримгә зур һәйкәл куелды. Аның тантаналы ачылышында Татарстан һәм Башкортостан Президентлары, халык язучысының кызы Әлфия Кәримова белән оныгы Тимербулат Кәримов та катнашты. Ә былтыр аның исемен йөртүче пароход суга төшерелде.

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

**Гәрәй Рәхим, Татарстанның халык язучысы, Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты:**
– Мостай Кәрим – безнең төрки халыклар арасында иң күренекле язучыларның берсе. Күп кенә шагыйрьләр, искиткеч шигырьләр язып та, аларны укучыга җиткерү өчен бик борчылмый. Бу редакция яки нәшрият эше, дип уйлыйлар. Ә Мостай Кәрим үз шигырьләрен укучыга җиткерү юнәлешендә дә эшләгән. Ул мәктәп укучылары, студентлар, хезмәттәшләре, шәһәр һәм авыл халкы алдында еш чыгыш ясый иде. Шагыйрь нинди генә вазыйфа биләсә дә, иҗаты һәрвакыт беренче урында иде. Ә тагын ул үз тыңлаучылары белән аралашуда бик гади булды, алар белән уртак тел табып, аны тыңлаучылардан беркайчан да өстен куймады. Мостай Кәрим Татарстанга, татар язучыларына карата бик якын мөнәсәбәттә иде. Ул татар әдәбиятын, мәдәниятен бик нык яратты. Татарстан язучылары белән тыгыз элемтәдә иҗат итте, алар белән аралашып яшәде. Бигрәк тә Хәсән ага Туфан белән дуслар иде. Казанга еш килде, килгәч, ул Хәсән Туфан белән икәү генә калып, бик озак серләшә иделәр. Туфанның төрмәдә язган шигырьләренең нинди зур һәм көчле әсәрләр икәнлеген белгертеп соклана торган иде. Татар әдәбиятының үсешенә игътибар бирде. 60 нчы елларда әдәбиятка килгән бер төркем шагыйрьләрне «татар әдәбиятында яңа сүз әйтүчеләр» дип атап йөртә иделәр. Бу хакта Мостай Кәрим дә Мәскәүдә «Литературная газета»да без – 60 нчы елда әдәбият мәйданына килгән татар шагыйрьләре турында үзенең фикерләрен язып чыкты. Татар җәмәгатьчелеге дә Мостай Кәримнең әсәрләрен якын итә. Аның бик күп китаплары татар телендә чыкты, драма әсәрләре сәхнәләрдә куелды. Әле бер генә башкорт язучысының да һәйкәле Казанда ачылганы юк иде. Бу Мостай аганың татар халкы тарихында үз эзе бар икәнлеген аңлатып тора торган факт. Татар халкының мәдәни тормышында бу әдип киләчәктә дә үз урынын тотып торачак.

**Әлфия Кәримова, Мостай Кәрим фонды директоры, әдипнең кызы:**
– Абыем белән яшь арабыз ун елга якын. Илгиз абый 1942 елда туганда, әткәй әле фронтта иде. Ул аны 8 айлык вакытында гына күрә, ә инде улы белән якыннан танышканда, Илгиз биш яшен тутырган була. Мин дөньяга килгәндә әткәй инде аягында нык басып тора, халык мәхәббәтен яулаган иҗатчы иде. Безнең гаиләдә беркайчан да тавыш, бер-береңне кимсетү кебек нәрсәләр чыкмады. Гаиләдәге мохит, әткәй-әнкәй арасындагы мөгамәлә үзе үк безгә өлге, тәрбия булды.

Әткәй сабыр, тотнаклы, шуңа да аны тирә-юньдәгеләр хөрмәт итә иде. Әнкәй белән бәхетле тормыш корып яшәде. Әткәйнең абруен әнкәй балалары алдында нык тотты. Ул кабинетында эшләп утырганда (андый көннәр сирәк була, чөнки әткәй күбрәк иҗат йортларына барып яза торган иде), без аяк очларына гына басып йөрибез. Әткәйгә комачау итмәскә икәнен бик яхшы беләбез. Ә инде оныклары туа башлаганда: «Сайрар кошлар һәм сунарчы кошлар була, минем балалар – сайраучы кошлар, алар белән сөйләшергә кирәк, аларга кычкырырга да, аларны җәзаларга да кирәкми. Алар белән килешергә, уртак тел табарга һәрвакыт мөмкин», – дияргә яратты. Әле дә хәтерлим, әткәй ерак сәфәрләрдән кайта, җыелып сөйләшәбез, ул безнең яңалыкларны һәрвакыт белә иде, мөгаен, әнкәй телефоннан хәбәр итеп торгандыр.

Ул – шагыйрь, дөнья ваклыгыннан ерак зат. Шул ук вакытта аягында нык басып тора иде. Тормыш итәрлек бөтен нәрсәне эшли, уңайлы яшәү шартлары тудыра белә. Бездә һәрвакыт һәр нәрсә гади иде, әткәй артыгы өчен хафаланмады. Беренче көннәремнән үк аның кызы идем инде. Аның кадәр акыллы һәм талантлы булмасам да, тышкы кыяфәтем генә түгел, башка сыйфатларым белән дә аңа охшаганмын.

Без бит – ут күршеләр, телебез, мәдәниятебез бик охшаш, тугандаш халыклар. Әткәйнең, мәсәлән, берәр драмасы Уфада куелса, бер айдан ул инде татар сәхнәсендә – Г. Камал театрында күрсәтелә торган иде. Китапларга килгәндә, башкорт язучыларының әсәрләре Татарстанда, параллель рәвештә инде Татарстанның каләм әһелләре Башкортостанда бастырыла. Әлеге элемтәләрне яңадан ныгытасы иде. Без татарлардан башка, татарлар башкортлардан башка яши алмыйбыз шикелле. Әткәй Минтимер Шәймиев белән очрашканда да бу турыда фикер алыша иделәр.

Казанда куелган һәйкәл безнең өчен бик кадерле. Мин әткәй белән Казан урамнарында йөргән чакларымны әле дә сагынып искә алам. Әткәй буыны һәм чоры язучылары белән Бауман урамындагы бинада очрашкан якты мизгел хатирәләрен күңелемдә саклыйм. Шунысы куанычлы: әткәйнең иҗаты киңкырлы булуы белән отышлы. Кемдер шигырен укый, кемдер драма әсәрләрен карый, ә замана яшьләре аны кинолары аша таный.

**Нәзифә Кәримова, Мостай Кәримнең килене, язучы, журналист:**
– Быел минем кадерле каенатам Мостай Кәримнең тууына 101 яшь булса, үлеменә сентябрь аенда нәкъ 15 ел тулды. Быел тормыш иптәшем, Мостай Кәримнең улы Илгизнең вафатына да бер ел. Еллар узган саен берни дә үзгәрми дә, онытылмый да...

Без Илгиз белән өйләнешкәндә әткәйгә бары тик 50 яшь иде. Ә инде танышу 1969 елның көзендә Мәскәүдә Язучыларның үзәк йортында, аның 50 еллык юбилеен бәйрәм иткән кичәдә булды. Илгиз мине булачак каенатам янына алып килеп таныштырды. Мине ресторанга чакырды. Ләкин мин шул тикле танылган, ләкин миңа әле таныш булмаган кешеләр арасында калып, бер табында утырырга базмадым. Без рестораннан чыгып киттек. Минем мөнә шушы тәртибем әткәйгә ошаган да. Соңыннан Илгиз сөйләде: «Әткәй сине бик тыйнак икән, дип әйтте», – диде.

Өйләнешкәнче алар гаиләсе белән әллә ни аралашмадык. Без – Мәскәүдә, алар – Уфада. Туй 1970 елның августында Уфада узды. Туйдан өйгә кайттык. Ә менә мин Илгизнең әти-әнисен берничек тә атый алмыйм. Кем дип әйтергә? Бер тапкыр «Рауза апа» дип дәшкәч, кайнанай: «Уфалар ишетмәсен тагын, көләрләр, нигә миңа апа дип дәшәсең?» – диде. Шуннан соң әткәй мине эш бүлмәсенә чакырып алды да: «Минем синең урында калганым юк, ләкин мин сине бик яхшы аңлыйм. Ят кешеләргә «әткәй, әнкәй» диеп әйтү читендер, ләкин син дә безне Илгиз кебек «әткәй, әнкәй» дип ата инде, менә хәзер үк миңа әткәй дип әйт әле», – диде. Мин аңар «әткәй» дип әйттем дә елап җибәрдем. Ул мине иңемнән кочаклап алып, аркамнан сөеп юатты. Шул ук кичне әнкәйгә дә «әнкәй» дип дәшә башладым.

Илгиз белән 49 ел бергә яшәдек. Ике бала үстердек. Әткәйне без беркайчан да истән чыгармыйбыз. Вафаты көнен гадәттә якын туганнар гына искә алабыз. Әткәй әсәрен сәхнәләштергән театрга барып, спектакль карап кайту гадәте дә бар. Аллага шөкер, әткәйне язучы буларак кына түгел, ә кеше буларак та хәтерлиләр.



# МИНГОЛ ГАЛИЕВНЕҢ ТОРМЫШ ЛИНИЯСЕ

**Автор:** Руфия Фазылова

## ВИЗИТ КАРТОЧКАСЫ

Мингол Галиев 1941 елның 27 августында Мамадыш районы Иске Комаза авылында туган. Татарстанның халык артисты, мөгаллим.

Казан дәүләт консерваториясенең вокал факультетын тәмамлый. Казан дәүләт педагогика университетының музыка факультетында күп еллар педагогик эшчәнлек алып бара. Илледән артык фәнни хезмәт бастырып чыгара. Укучылары – республика, бөтенроссия, халыкара дәрәҗәдә лауреатлар һәм дипломантлар иясе. Аның шәкертләре арасында танылган җырчылар күп.

**Гаиләдә бишенче бала булып туганмын. Ирләрен сугышка озаткан хатын-кызлар басуда иген җыйган.** Шулар арасында әни дә булган. Әллә кайгыдан, әллә авыр эштән, мин җитлекмичә – җиде айдан дөньяга килгәнмен. Кечкенә гәүдәле, бик чандыр идем. Әле үсеп беткәч тә, авыл апалары: «И, шушы бала да кеше булды», – дип аркадан сөяләр иде.

**Без класста 21 бала укыдык. Шуларның унтугызының әтисе юк иде.** Без әтиләрне күрмәдек, тик без ятимлекне дә сизмәдек. Ни өчен дигәндә, бөтен гаиләдә дә ятимлек бит. Аннан, әниләребез ир урынына да, хатын урынына да җигелеп эшләде.

**Әтиле булу белән бәйле гаҗәп бер вакыйга истә калган. Тәнәфестә малайлар сөйләшә: «Гыйльмулланы әтисе кыйнаган икән».** Шунда бер бала әйтеп куймасынмы: «Ярый әле безнең әтиләр юк, име...» Шушы вакыйгаларны кат-кат уйлап утырам. Тормышны сугыш ни дәрәҗәдә үзгәртте, ятим итте...

**Сугышка кадәр безнең якта күп ирләр шахтага барып эшләгән. 1940 ел башында әти дә, гаиләсен туендырырга теләп, шахтачылар әртиленә кушыла.** Авылга да кайтып килә. Минем туганны белгәч, әнигә посылка сала. Ә аннан аны сугышка алалар. Соңрак үлгән хәбәре килә. Шулай итеп әти мине, мин әтине бер тапкыр да күрү бәхетенә ирешми калабыз.

**Биш баланың өчесе генә үскән. Ике апам, үсмер яшькә җиткәнче, дөнья куйган.** Ул вакытта бит кызамык, тиф кебек чирләр күп иде. Медицина көчле түгел. Картайган көндә дә мәрхүм булган ике кызын әни гел искә ала иде.

**Авылдагы иң чандыр, иң бетерешкән балаларның берсе идем.** Тик минем рухым көчле булды. Кеше арасына керәсем, әнинең йөзендә горурлык хисләрен күрәсем килде. Җидене тәмамлагач ничек тә укуны дәвам итәргә теләдем. Урау юллар белән булса да, Мамадышка барып ун классны тәмамладым.

Фото: Лилиана Валитова

**Балаларны кич белән клубка чыгармауны аңлый алмыйм.** (Авыл клублары турында сүз бара). Ул бит бозык урын түгел. Клуб тәрбия чыганагы булырга тиеш. Һәрхәлдә, безнең авылда шулай иде. Мәктәп һәм клуб янәшә атларга, бергә эшләргә тиеш. Әле бүген дә шулай эшләүче авыллар бар, шуңа бик сөенәм.

**Моң миңа әниебез Миңсылудан күчкән дип уйлыйм.** 1909 елгы иде ул. Татар теленең өч графикасында укырга-язарга өйрәнгән, белемле, тирән ханым иде. Яттан бик күп шигырьләр белде, мөнәҗәтләр көйләде. Аның моңлы тавышы бүген дә колагымда яңгырап тора.

**Сугыштан соңгы елларда хатын-кызлар арасында кич утыру гадәте бар иде.** Бер төркем авыл апаларының безнең өйгә җыелып, мөнәҗәтләр, көйләп, моңланып утырганнарын хәтерлим. Мин аларны мич башыннан йотлыгып тыңлый идем.

**Өченче сыйныфта укыганда ата-аналар җыелышында җырлатканнарын хәтерлим.** Ни өчендер мәхәббәт җыры башкарганмын. Ул чакта күпләр моны аңламады. Янәсе, орчык буе малайга каян килгән мәхәббәт җырлары. Ул чорда бу темага керергә ярамый иде. Ә мин моңа икенче төрле карыйм: халыкның мәхәббәт җырлары иң изге хисләрне чагылдырган. Табигый рәвештә саф күңелдән кайнап чыккан тойгылар бит алар.

**Әни берсендә ничектер: «Кеше балаларыннан була, безнекеләрдән юк инде», – дип әйтеп куйды.** Үземне эзләгән, кайсы юлны сайларга дип йөргән вакытлар иде бу. Тиз генә документларны җыйдым да, Казанга – консерваториягә чыгып киттем. Тик бу турыда берәүгә дә, хәтта йөргән кызыма да әйтмәдем. Ни өчен дигәндә, ул вакытта артистларга караш бөтенләй башка иде. «Ә, артист булып йөргән итә», – дияләр иде. Әлбәттә, Усман Әлмиев, Рәшит Ваһапов кебек җырчыларга хөрмәт, соклану зур иде. Ләкин бит алар санаулы гына.

**Консерваториядә документлар тапшырганда миңа 18 тулмаган иде.** Баксаң, 18 яшькәчә кешенең тавышы әле утырып бетмәгән була. Шулай ук 24 яшьтән соң да уку йортына алмыйлар, инде карт санала. Алланың рәхмәте, авылдан килгән бала дип кызганып булса кирәк, документларымны кабул иттеләр. Бу минем тормыштагы иң якты вакыйгаларымның берсе.

**Миңа кайберәүләр: «Син утын пүләнен дә җырларга өйрәтәсең», – диләр. Бер карасаң, бу чыннан да шулай.** Җырлый белгән кеше белән һәркем дә эшләргә тели, ә менә моңы булмаган кешене җырларга өйрәтеп кара син! Бу авыр эш, ләкин мөмкин. Җырлый белмәгән кеше юк. Кеше ничек сөйләшә, шулай җырларга тиеш. Шуңа да гаиләдәге сөйләм балага нык тәэсир итә.

> “
>
> – Җырлый белгән кеше белән һәркем дә эшләргә тели, ә менә моңы булмаган кешене җырларга өйрәтеп кара син! Бу авыр эш, ләкин мөмкин. Җырлый белмәгән кеше юк. Кеше ничек сөйләшә, шулай җырларга тиеш.

Эти-әнисе ягымлы аралаша икән, бу балада да чагыла. Кычкырганны да сизеп була. Телне болай куй, корсак белән сула дип өйрәтергә җыенмыйм, минем үз методикам. Мин табигыйлек яклы. Сабый тугач, «ңә-ңә» дип аваз саламы. Мин дә укучыларымны шул авазны җырларга өйрәтүдән башлыйм.

**Әлбәттә, бөтен кеше җырчы була алмый.** Беренче чиратта моңа зур тырышлык, теләк кирәк. Һәм, әлбәттә, табигатьтән бирелгән талант. Менә шулар барысы да кушылгач кына, халык күңеленә кереп була.

**Җырчы Хәнәфи Шәйдуллин исән чагында, янына хәлен белергә баргач: «Миңгол, үлемнән курыкмыйм, тик менә белгәннәрем үзем белән китә, тапшырып кала алмадым, шунысы аяныч», – дигән иде.** Минем дә татар сәнгате турындагы белемнәремне, үз методикамны шәкертләремә өйрәтеп калдырасым килә. Шөкер, андый укучыларым да бар. Ләкин үсеп килүче буын, мәктәп балалары турында да онытырга ярамый. Шуңа да быел Совет районының 180 нче гимназиясендә Халыкара музыка сәнгате үзәге эшләп ятабыз. Мәктәп җитәкчелеге бик яхшы урын бирде. Сәхнәсе, аерым классы булган үзәк булачак ул. Яңа елга кадәр анда балалар шөгыльләнә дә башлар дип өметләнәм.

**Ун еллар элек намаз укый башладым.** Җай туры килмәсә, намазымны җыеп укыйм. Дин турында күп уйланам. Инкыйлабтан соң коммунистларның иң зур ялгышы – динне читкә этәрү булган. Ә бит партиядә идеология, пропаганда дигән система бар иде. Бер карасаң, коммунизмны төзү кодексы да нәкъ Коръәннән алынган бит.

**Кайбер мөселман кардәшләрем минем намаз да укып, җырлап та йөрүне бик аңлап бетерми.** Янәсе, болар бер-берсенә каршы килә. Бу бик фәлсәфи мәсьәлә. Мәчеткә йөргән кеше генә изге була дип карамыйм. Сафлыкка, чисталыкка өндәүче динебезне бик хөрмәт итәм. Тик җыр сәнгатендә дә бер начарлык та күрмим. Моң аша да кеше күңеленә кереп, халыкны тәрбияли алуыма чын күңелдән ышанам.

**«Мин иманлы кеше, Аллаһны таныйм», – дип күп тапкырлар башкалар алдында кабатлап йөрүчеләргә бераз шикләнеп карыйм.** Әгәр дә берәү гөнаһлар кылмаса, башкалар белән яхшы мөнәсәбәттә булса, эти-әнисенә, гаиләсенә ихтирам күрсәтсә, мохтаҗларга ярдәм итәргә тырышса, бу дингә, Коръәнгә каршы түгеллекне аңлата. Әгәр бүгенге көндә кайберәүләр сәхнәгә төрле кыяфәттә чыга икән, бу инде җәмгыятьнең йөзен күрсәтә. Җыр ул бүген коммерциягә әйләнде. Сәхнәдә бер төрле ул адәм баласы, ә тормышта икенче. Шулай да мин сәхнәгә ярымшәрә киенеп чыгучы артистларны хупламыйм.

Казан шәһәре 180нче гимназиядә Халыкара музыка сәнгате үзәге эшли.

**Кызык әйбер: нәрсәдер сөйли башласаң, сәясәткә кереп китмик, диләр. Ә бит сәясәткә кермәү, үзе сәясәт бит.** Ансыз тормыш юк. Ул бит һәр кешенең шәхси карашы. Моннан шактый еллар элек Шәһәр думасына сайланучы депутатлар исемлегендә идем. Педагог буларак мине Марат Мөлеков тәкъдим иткән иде. Җиде кеше арасыннан икенче урында калдым. Ул чакта Айрат Хәйруллин җиңеп чыкты. Мин анда пропаганда эшен дә алып бармадым. Дөресен генә әйткәндә, депутат булам дигән максатым да юк иде.

**Замана балаларының күзаллаулары башка.** Мин моны мәктәп балалары, үз оныкларым белән аралашканда да аңлыйм. Без төрле күргәнне, алар икенче төрле тоя. Без үскәндә: «Хәзер балалар җидене бетереп туа», – дияләр иде. Ә без балаларга: «Хәзер балалар унны бетереп туа», – дидек. Бүгенгеләр исә институт бетереп туа кебек. Миңа калса, бу шулай булырга тиеш. Кешелек бер урында гына тора алмый. Бүгенге балалар белән аралашу миңа бик рәхәт.

**Гаиләмә килгәндә, хатыным Фәния белән бер ул, бер кыз үстердек.** Ни кызганыч, кызыбыз мәрхүм булды, яман чир иде. Ике баласы – сигез яшьлек улы, алты яшьлек кызы калды. Алар этиләре янында – Аксубай районында үстеләр. Хәзер оныклар бездә яши, студент булдылар. Бик мөстәкыйль балалар. Карчыгым белән икебез дә бик канәгатьбез.

**Балаларны ярату дигәннән. Кызым вафат булгач, киявебез ике балалы хатынга өйләнде.** Әйе, ир-атка ялгызы гына авыр. Һич арттыру түгел: ул ике кызны да оныгыбыз итеп кабул иттек. Аксубайга кайткач, тезеп утыртып, дүртесен татарча җырлата идем. Бүләк алсак та, берьюлы дүртне алдык.

**Өем тулы китап: матур әдәбият, халык медицинасы... Әлбәттә, аларның барысын да укып чыктым димим. Әмма күп укыйм.** Аерым бер тема турында мәгълүмат кирәк булса, тиз генә китап киштәсен актарам. Кичләрен дә укып ятарга яратам. Безнең чор кешеләренә хас сыйфат – китапка мәхәббәт ана сөте белән кергән.

**Студент вакытта салкын тиеп бик каты авырдым.** Аннары да бик озак ютәлләп йөрдем. Шуннан тимер юлчылар хастаханәсендә үпкәләремне тикшерделәр. «Дәваланмый торган ике яклы деформацияләнгән бронхит» дигән диагноз куйдылар. Бик тәҗрибәле табиб шунда: «Сезгә нинди җырлау турында сөйләү?» – дип киная белдерде. Аллага шөкер, шул диагноз белән кырык елдан артык яшим. Әле дә сузып җырлыйм, тавышым да әйбәт. Миңа калса, шул җырлавым аркасында яшим дә. Дөрес итеп тын алганда, үпкәләр ачыла. Бу мин уйлап тапкан дәвалау ысулы гына түгел, ә дөнья медицинасы тарафыннан да танылган.

**Булган тәҗрибәмне яшьләр белән уртаклашудан тыш, сәхнәдә җырлыйсым килә.** Мактану булмасын, халык һаман да ярата үземне. «Тагын җырлыйсыңмы?» – дип килеп әйтәләр. Исәнлегемнән дә зарланмыйм. Кеше әйтмәсә, сиксәнгә җитеп килгәнемне сизмим дә...

# Мәңгелек кыйммәтләр/

Мәңгелек кыйммәтләр

Акыллы гамәлләр

Игелекле эшләр

**Бу санда тәкъдим итәбез:**

**Ни өчен** Мамадыш музее гасыр музее исемен алды

Ольга Зуеваның ике бабасы **ничек** итеп фашистларны җиңгән

**Кем** ул Хәсәнгата Габәши

Сочи татарларының хыяллары **ничек** тормышка аша

# ГАСЫР МУЗЕЕ

**Республиканың яшьтәше – «Татарстан» журналы ТАССРның 100 еллыгы сайтында барган «Гасыр музеен сайла!» һәм «Гасыр музеен сайла! Башкала версиясе» конкурсларын кызыксынып күзәтте. Җиңүчеләрне журнал редакциясенә чакырып, дусларча чәй өстәле янында яулап алган бүләкләрен тапшырдык, музейчылар шулай ук якын киләчәккә зурдан кубып корган планнары турында да сөйләделәр.**

## МАМАДЫШ ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ

Тавыш бирү вакытында музей җыйган тавышлар санына (10 меңгә якын) караганда, аларның экспозицияләрен Мамадыш халкы бик ярата.

– Безгә район башлыгы Анатолий Иванов һәм якташларыбыз теләктәшлек итеп торды, – дип шәрехли конкурсның йомгакларын Мамадыш туган якны өйрәнү музееның директоры **Минзилә Садриева**. – Бу аңлашыла да: без Мамадышлылар үзләре китергән материаллар белән күп эшлибез, туган ягыбызны, тарихыбызны өйрәнәбез.

Быел музей Бөек Ватан сугышында катнашучылар истәлегенә Хәтер дивары ачарга планлаштыра. Меңнән артык фотография җыелды инде. ТАССРның 100 еллыгына күргәзмә әзерләнә, ул Мамадышта туып-үскән, Татар ҮБК Президиумының беренче рәисе Рәүф Сабировка багышлана. Ул эшләгән еллар (1921–1924 еллар) Гражданнар сугышы һәм ачлыкның иң авыр вакытына туры килә.

Шулай ук ана музее ачарга планлаштырабыз. Идеянең нигезендә Урта Кирмән авылыннан (Мамадыш районы) Фатыйха Әхмәдиева тарихы ята, ул Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышында сигез улын югалткан.

## «КАЗАН КРЕМЛЕ» ДӘҮЛӘТ ТАРИХИ-АРХИТЕКТУРА ҺӘМ СӘНГАТЬ МУЗЕЙ-ТЫЮЛЫГЫ

Казан Кремле территориясендә җиде музей һәм күргәзмә залы урнашкан. Аларда һәр атнада төрле проектлар гамәлгә ашырыла.

– Без саңгыраулар һәм начар ишетүчеләр, сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус программалар эшлибез. «Кремльгә кагыл» проектын башлап җибәрдек. Республика сукырлар һәм начар күрүчеләр өчен махсус китапханә ярдәме белән бездә Казан Кремле архитектур һәйкәлләренең тотып карап була торган модельләре барлыкка килде. Ягъни тарихны чын мәгънәсендә тотып карап була, – ди музейның фәнни-методик эшләр бүлеге башлыгы **Дарья Моратова**. – Моннан тыш, без русча ишарәләр телендә берничә фильм эшләдек, алар безнең рәсми сайтка куелачак. Кремль территориясендә планшетларда саңгыраулар һәм начар ишетүчеләр өчен видеогид бар.

2020 елда музей-тыюлык Владимир Потанин фонды үткәргән конкурста «Уртак эш» проектында катнашу өчен грант алды. Грант музейга яңа сайт эшләү өчен тотыла, ул октябрьдә үз эшен башлаячак.

Фото: Александр Ефремов

**«Гасыр музеен сайла!» (Татарстан районнары музейлары арасында) конкурсында җиңүчеләр:**

- 1 нче урын – Мамадыш туган якны өйрәнү музее
- 2 нче урын – Долгая Полянада (Тәтеш районы) Молоствовлар утары
- 3 нче урын – Ярослав Гашекның Әдәби-мемориаль музее (Бөгелмә)

**«Гасыр музеен сайла! Башкала версиясе» конкурсында җиңүчеләр (Казан музейлары):**

- 1 нче урын – Габдулла Тукай Әдәби музее
- 2 нче урын – Николай Лобачевский музее (Казан федераль университеты)
- 3 нче урын – «Казан Кремле» дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгы һәм Казан университеты (Казан федераль университеты) тарихы музее.

## КАЗАН ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ МУЗЕЙЛАРЫ

– Асылда республиканың беренче дәүләт музейлары. Аларның күбесе университет оешканда 200 елдан артык ел элек барлыкка килгән һәм алар уку-укыту коллекцияләреннән торган. Инкыйлабтан соң коллекциянең бер өлеше ТР Милли музеена күчкән. КФУ Тарихы музее – республикада Россиядәге һәм дөньядагы фәнни белемнәр һәм ачышлар үсеше тарихын яктырткан бердәнбер музей.

Николай Лобачевский музее Казан университеты тарихы музее структурасына карый. Ул ректор Илшат Гафуров башлангычы белән оештырылган иң яшь мемориаль музейларның берсе.

Университет музейларының бүгенге трендлы – аларның киң фондларын һәм коллекцияләрен цифрга күчерү.

– Николай Лобачевскийның мирасы – китаплары, кулъязмалары, портретлары, университет математиклары 100 елдан артык туплаган Геометрия кабинеты китапханәсе Интернет ресурслар ярдәме белән һәркемгә ачык булсын дип теләр идек, – ди КФУ тарихы музее директоры **Светлана Фролова**. – Җиңүнең 75 еллыгына без инде ике меңнән артыграк экспонатны цифрга күчердек, алар сугыш вакытында Казанга эвакуацияләнгән Фәннәр академиясе институтлары хезмәткәрләре һәм студентлар тормышы белән бәйле. Алар арасында биредә җиде булачак Нобель премиясе лауреаты яшәгән һәм эшләгән. Студентлар белән бергәләп, без ике зур проект алып барабыз – эзтабарларның походлардан язган язмалары, 30–40 ел элек ветераннар белән интервьюлары чыккан «Карлы десант» стена газетасын һәм фронттан килгән хатлар архивын күчерәбез. 2021 елда музей «Университет музейлары – балаларга» проектын дәвам иттерергә планлаштыра.

## ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘДӘБИ МУЗЕЕ

Музей Казан үзәгендә Шамил йортында урнашкан. Аның экспозициясе XX йөз башы татар әдәбияты тарихын чагылдыра, һәм бары тик биредә генә дә Тукай белән бәйле җиде мемориаль экспонат бар, шулай ук шагыйрь үзе исән чагында чыккан китапларның зур өлеше биредә саклана.

Бүген музейда 0+ балалар өчен интерактив зал, конференц-зал, китапханә, Тукайның тормышына багышланган зал, XX йөз башында татар иҗади мохите турында сөйли торган зал, сәүдәгәр йортының тарихи җиһазлары белән кунак бүлмәсе, шагыйрь исемендәге премия лауреатлары турында сөйли торган зал һәм шагыйрь үлгәч алынган битлек саклана торган зал эшли.

– Без әдәби музейның Тукай үзәге булуын телибез, анда шагыйрьнең тормыш юлы һәм иҗаты фәнни нигездә өйрәнелер иде. Без фәнни җәмәгатьчелек белән гади кешеләрне бәйли торган звено. Бездә «Туган тел» дигән туган тел укытучылары клубы эшли. Мәктәпләр белән уртак проектларны яңа баскычка күтәрербез, дип өметләнәм, – ди музей директоры **Гүзәл Төхвәтова.**

**Мамадыштагы туган якны өйрәнү музее һәм Габдулла Тукай Әдәби музее – ТАССРның 100 еллыгы сайтында уздырылган «Гасыр музеен сайла!» тавыш бирүендә җиңүчеләр. Сезне үзебез белән бергә «виртуаль» экскурсиягә чакырабыз, һәм сез аларга карата халык мәхәббәтенең ни өчен көчле булуын аңларсыз.**

**Автор:** Олеся Бондаревская

# МАМАДЫШТАГЫ ТУГАН ЯКНЫ ӨЙРӘНҮ МУЗЕЕ

## ИҢ ТАРИХИ

**Мамадыш зур шәһәр түгел, биредә 16 меңгә якын кеше яши. Ярты көн эчендә бөтен шәһәрне йөреп чыгып була кебек. Алай түгел икән шул! Җирле туган якны өйрәнү музеена килеп эләксәң, тиз генә чыгармын димә. Музей ябылганга кадәр шаккатып йөрисең – кызыклы тарихларның күплегенә башкала да көнләшерлек.**

### СИГЕЗ БИЗӘКЛЕ СӨЛГЕ

Мамадышта Фатыйха исемле кыз яшәгән. Буйга җиткәч, кияүгә чыккан, бер-бер артлы балалары туган – сигезәү. Барысы да – малайлар. Зурраклары – Садри белән Ибраһим үсеп җиткәч, революция башлана, аннан соң – Гражданнар сугышы. Икесе дә Кызыл Алмия сафларына алына. Башта Колчак армиясенә каршы, аннан соң Көнбатыш фронтта сугышалар. Садри һәлак була. Ә Ибраһим кайта, үзе белән Коръәнен дә алып кайта. Изге китап гомеремне саклап калды, ди ул. Еллар үтә тора, Фатыйханың башка балалары да үсеп буй җитә. Революциядән соңгы авыр еллар артта кала кебек тоела. Яшен бер агачны ике тапкыр сукмый диләр бит! Әмма Бөек Ватан сугышы башлана. Фатыйханың уллары бер-бер артлы сугышка китә. Ана улларының кайтырын зарыгып көтә. Улы Ибраһим алып кайткан Коръәнне кулыннан төшерми, дошман ядрәләре улларын урап узсын дип, догадан калмый. Тик көтеп җиткерә алмый – берсен дә. Аның батыр уллары яу кырында ятып кала. Ана йөрәге зар елый. Малайлары истәлегенә ул сигез төрле бизәк төшереп сөлге чигә. Сөлгене дә сигез бизәкле сөлге дип атый башлыйлар. Сөлге дә, Коръән дә бүген Мамадыш музеенда саклана. Фатыйха Әхмәдиева – республикада сугышларда сигез улын да югалткан бердәнбер ана.

### МАМАДЫШЛЫ МӘСКӘҮНЕ ТАЛАНУДАН КОТКАРГАН

1942 елдан 1945 елга кадәр Мәскәү трибуналларында җинаять эшләре, мародёрлык, дезертирлык турында 300 гә якын эш карала, бандитлар шәһәрдә тәртип һәм сакның юклыгыннан файдаланып башкара аларны. Бу статистиканы нигә дип китерәмме? Ә менә нәрсәгә: 1941 елда СССР Прокуратурасы

Фотолар Мамадыш туган якны өйрәнү музееннан алынды

һәм СССР Югары Суды хезмәткәрләре эвакуацияләнә, шуңа күрә башкалада хөкем итү органнары системасын яңадан диярлек төзергә кирәк була. Бу эшне тумышы белән Киров шәһәренеке булган Николай Афанасьев башкарып чыга. Мамадышка Афанасьевлар гаиләсе Николайга 8 яшь чагында күченә. Ул иртә эшли башлый, үз теләге белән РККА сафларына языла, ак чехларга каршы көрәшә, ә 1920 елда 18 яшьлек егет Мамадышта җинаять эшләрен тикшерүләрне җитәкли. 1941 елда ул Кызыл Армиянең баш хәрби прокуроры урынбасары була. Мәскәүнең чолганышта калуы турында карар кабул иткәндә Сталин нәкъ менә аның фикере белән кызыксына. Аннан соң, КПСС ҮК секретаре Георгий Маленков күрсәтмәсе буенча, Афанасьев җәмәгать тәртибен саклау планын төзи. План дөрес булып чыга. Тикшеренүчеләр фикеренчә, Афанасьев озак вакытлар дәвамында хәрби мәсьәләләр буенча Сталинның юридик консультанты булып тора, ул шулай ук Нюрнберг процессында да катнаша. Мамадыш музеенда генерал-лейтенант Афанасьевның кителе, фуражкасы, шәхси хатлары һәм фотографияләре саклана.

## ЯШЕЛ КИЕМНӘР ҺӘМ НИКОЛАЙ ЧУДОТВОРЕЦ

Музейда 1910 нчы елларда Троица соборында узган гыйбадәт кылуларны үз күзләре белән күргән өлкән яшьтәге мамадышлыларның истәлекләре саклана. Музей белгечләре әлеге истәлекләрдә чиркәү руханиларының киемнәре бик матур булуы турындагы юлларга игътибар итәләр. Анда собор башлыгы ризасы алтын чәчәкләр чигелгән яшел төстәге кием буларак искә алына. Чиркәүнең соңгы башлыгы Павел Михайлов 1918 елда үтерелә. 1933 елда соборны ишәләр. Киемнәр югалган санала. Быелның май аенда район башлыгы Анатолий Ивановка, ә аннан соң музейга әлеге ризаны кайтарып биргәннән соң, музей хезмәткәрләренең гаҗәпләнүенә чикләр булмый. Әлеге кием бик күп яктан – бәһасез. Аңа якынча 150 ел.

Мамадышта православие традицияләре көчле. Риваять буенча, XVIII гасыр башында шәһәр янәшәсендә Николай Чудотворецның могҗизалар кылучы иконасына (тәресенә) тап булалар. Әмма киләсе йөзьеллыкта аны Алабугага озаталар, Мамадышка бәйрәм көннәрендә тәре йөртү вакытларында гына алып кайталар. Соңгы мәртәбә мондый тәре йөртү 1918 елда була (әлеге традицияләргә большевиклар шактый лояль караган, дип сөйлиләр). Аннан соң икона юкка чыга. Әллә Колчак армиясе офицерлары чит илгә алып китә, әллә кайдадыр шәхси коллекцияләрдә урын ала. Ничек кенә булмасын, музей хезмәткәрләре әлеге кадерле ядкәрнең кире кайтуына өметләрен җуймыйлар.

## ДАН ЗАЛЫ

Татарстанда Беренче бөтендөнья, рус-япон һәм Гражданнар сугышларында катнашкан якташларына багышланган аерым зал бары тик Мамадыштагы туган якны өйрәнү музеенда гына бар. Берничә ел элек җирле рәссам аларның фотографияләрдәге сурәтләрен зур киндерләргә төшерә. Әлеге портретларны карап йөргән һәр кеше ирексездән үзенә солдат булу, сугышның бөтен ачысын-төчесен тату ничек була икән дигән сорауны бирәдер. Монда куелган ике сандык та сугыш күргән. Берсен 1906 елда Цусима янындагы бәрелешләрдә катнашкан Алексей Озеров сугыштан алып кайткан. Икенчесе – 1918 елгы сугышларда катнашкан солдат Махеевныкы. Сандыкта Беренче бөтендөнья сугышында катнашкан рус армиясе солдатының тулы экипировкасы саклана.

## СОЛДАТНЫ ВАТАНЫНА КАЙТАРЫРГА!

1981 елда ТАССРның Мамадыш районы Ишки авылы егете – 19 яшьлек Илшат Гәрәйханов Әфганстанга хезмәт итәргә китә. 1982 елның августында ул хезмәт иткән ротаны Бамиан провинциясендәге Малован кышлагына җибәрәләр. Десантчылар дошманнар төркемен табарга һәм юк итәргә тиеш булалар. Әмма әфганлыларга ярдәм килеп өлгерә, ә совет солдатлары камалышта кала. Сугыш вакытында Илшат елга аша салынган күпер буйлап яраланган иптәшен ут астыннан алып чыга. Әмма Илшатның аяк астына граната ташлыйлар. Шартлау дулкыны десантчыны елгага ата. Илшатны тере килеш тә, үле килеш тә тапмыйлар. Берничә айдан мөҗәхитләр совет командирларына Илшатның гәүдәсен әсир төшкән әфганлыларга алыштыру тәкъдиме белән чыгалар. Әмма сөйләшүләр нәтиҗә бирми. Хәзерге вакытта да Илшатны табу өметен җуймаган апасы Алсу, Мамадыш туган якны өйрәнү музееның кече фәнни хезмәткәре Гөләндәм Давыдова белән бергә,

эзләү эшләрен дәвам итә. Илшатның полкташлары, Әфганстандагы Россия вәкилләре белән бергә, республика һәм Россия хакимиятләре ярдәмендә, солдатны Ватанына кайтаруга өметләнәләр.

## БЕРДӘНБЕР ЯДРӘ

Музейдагы күп кенә кызыклы экспонатлар сугыш белән бәйле. Нәкъ менә сугыш XX гасыр кешеләренең язмышларын билгели кебек. Витриналарның берсендә – бер корылмалы хатын-кыз пистолеты. 1917–1920 нче елларда шундый корал белән теләсә кайсы хатын-кыз үзен яклый алган – үтергән өчен хөкемгә тартылудан курыкмыйча. Маршал Рокоссовскийның да шундый ук пистолеты булган, дип сөйлиләр. Ялган гаепләүләр аркасында НКВД төрмәсендә өч ел утырып чыкканнан соң, ул икенче тапкыр үзе артыннан килә калсалар, тере килеш ала алмаска тиешләр дип карар кыла. Бөек Ватан сугышыннан ул герой булып кайта. Әлеге хатын-кыз пистолетының кирәге чыкмый.

## КУЛИНАРИЯ МОГҖИЗАЛАРЫ

Революциягә кадәр Мамадыш, зур булмаса да, билгеле сәүдәгәрләр шәһәре була. Монда тулыканлы тормыш белән яшиләр. Җирле эшкуар Глазков Франциягә үз куллары белән үстерелгән, маринадланган шампиньоннарны сатып байый. Андагы кулинария могҗизаларын күреп кайтканнан соң, сәүдәгәр ассортиментны киңәйтергә карар кыла. Ул күл ясый һәм бакалар җибәрә. Шампиньоннарны әзерләгән кебек, аларны да маринадлый. Консервланган бака аяклары Мамадыштан туп-туры Франция гурманнары өстәленә агыла.

1828 елгы аш-су китабы да әллә Глазковныкы, әллә шараблар белән сәүдә итүче икенче бер сәүдәгәр Щербаковныкы булган, дип сөйлиләр. Әлеге калын китап музей витриналарының берсенә урнаштырылган. Китапны басарга император Николай I үзе кул куйган. Рус һәм француз ашлары (елның һәр көне өчен өчәр төрдәге аш-су) рецептлары кабатланмый. Аларның күбесе күптән онытылган. Мәсәлән, ак казылык (балыктан) ясау рецепты. Музейда әлеге китаптагы рецептлар буенча әзерләнгән аш-су фестивале үткәрү турында хыялланалар.

## БЕР ФАМИЛИЯ, ИКЕ ЯЗМЫШ

«Чайковский Германны Фигнер буенча язган. Ул Фигнер белән аралашкан, Фигнер белән Герман партиясе буенча репетицияләр ясаган. Алай гына да түгел, ул хәтта Фигнер белән киңәшләшкән һәм Николай Николаевич фикере буенча Герман партиясенә төзәтмәләр дә керткән, дигән мәгълүмат та бар», – дип сөйләде матбугатка Россия милли китапханәсенең кулъязмалар бүлеге фәнни хезмәткәре Елена Михайлова. Бөек рус опера теноры, 1880 нче елларда Италия, Испания, Румыния сәхнәләрен әсир иткән, «Император Галиҗәнаплары солисты» Николай Фигнер 1858 елда Мамадышта, бүгенге музей урынында 1863 елгы янгынга кадәр торган агач йортта туган. Ул вакытта биредә сәүдәгәр Иван Захаров гаиләсе яшәгән, ул Николайның әнисенең кыз туганына өйләнгән булган.

Музейда артист көндәлегенең күчермәләре саклана. Көндәлектә икенче бер атаклы Фигнер – әлеге йортка шулай ук кунакка килеп йөргән террористка Вера Фигнер исеме бөтенләй диярлек телгә алынмый, гәрчә ул тенор Николай Фигнерның бертуганы булса да.

**P.S.** Мамадыштагы туган якны өйрәнү музеена килә калсагыз, экскурсияне һичшиксез Гөләндәм Давыдова үткәрүен сорагыз, әлеге кызыклы тарихларны без аңардан ишеттек.

ИҢ АТАКЛЫ

# КАЗАНДАГЫ ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ӘДӘБИ МУЗЕЕ

**Автор:** Олеся Бондаревская



Фото: Александр Ефремов

**Казандагы Габдулла Тукай әдәби музее – тулы бер галәм, ул атаклы Шамил йортына могҗиза белән генә сыйгандыр. Экскурсовод Елена Тябина белән бергә без, шагыйрь язмышының төп борылышларында тукталып, аның кыска, әмма гаять бай язмышы эзләрен барларга булдык.**

*1 нче тукталыш*

## ТУКАЙ ТУРЫНДА БЕЗ НӘРСӘЛӘРНЕ (ҺӘМ НИГӘ) ХӘТЕРЛИБЕЗ)

– Хәзерге вакытта һәр күренекле кешенең тормышы җентекле рәвештә биографлар һәм фотографлар тарафыннан документлаштырылуы гадәти хәл санала. Әмма Тукай белән алай булмаган. Аның бала чагы турында без күбрәк «Исемдә калганнар» әсәре буенча беләбез, – ди Елена Ивановна. – Ә аның бала чактагы фотографияләре бөтенләй юк. Ятим баланы фотога төшерү кемнең башына килсен, ди... Беренче күренекле татар профессиональ фотографы Кыйваметдин Зөлфакаров, Казан арты якларында Тукай эзләре буйлап йөреп, аңа бәйле урыннарны фотога төшерә. Шуның аркасында без шагыйрьнең Кушлавычтагы туган йортының нинди булуын беләбез.

*2 нче тукталыш*

## ЯБЫК ИШЕК ТӨБЕНДӘ

Тукай биографиясенең иң кызганыч сюжетларының берсе – аның Кушлавычта Шәрифә карчыкта торган вакыты. Ике яшьлек малай кыш көннәрендә тышта, төнлә, яланаяк, күлмәкчән генә көенчә авыр ишекне ача алмыйча басып тора. Шагыйрь китабының беренче иллюстраторы Байназар Әлминев исемендәге Казан сәнгать мәктәбе укучылары рә-

семнәрендә ул шулай сурәтләнә. Хәзер бу эшләр музейда «Туган тел» конференц-залы диварларын бизи.

– Без еш кына Тукайны кечкенә, караучысыз, салкында катып басып торучы үксез бала итеп күз алдына китерәбез. Ләкин күптән түгел генә КФУ студентлары шагыйрьнең язмышын өйрәнүче проект тәкъдим иттеләр. Һәм шундый фикергә килделәр: Тукай авырлыкларны җиңә ала торган характерга ия булган, – ди экскурсоводыбыз. – Һәр яңа гаиләгә килеп эләккән саен, ул шатлык өчен сәбәпләр табарга ашыга, яңалыкны белү өчен теләсә кайсы мөмкинлектән файдалана. Күпме авырлыклар кичкәннән соң, беренче мәртәбә бәхетле балачак мизгелләре бүләк иткән Кырлай авылы аның күңеленә әкияти затлар белән тулы тылсымлы төбәк булып кереп кала.

### 3 нче тукталыш

## «ЯҢА ГАСЫР»НЫ ТӨЗҮЧЕЛӘР

Музей витриналарының берсенә гаилә ядкәре – шагыйрьнең бабасыннан атасына күчкән Коръән куелган. Алар барысы да хәзрәтләр була, Габдуллага хас гыйлемгә омтылу, күрәсең, алардан күчкән. Беркем өйрәтмәсә дә, ул иртә укый башлый, күп укый, ятлаган шигырьләрен сәнгатьле итеп сөйли белә. Тукай Кырлай мәдрәсәсендә яхшы укый. «Мин биремнәрне җиңел башкарып чыга идем, еш кына ни эшләргә белми идем. Шуңа күрә миңа артта калган балаларны беркетә башладылар, мин аларны өйрәтә идем», – дип искә төшерә ул үзенең китабында. Җаекка, атасы буенча апасының гаиләсенә – бала чактагы сәяхәтләрнең финалына килеп эләккәч, Тукай атаклы мәгърифәтче, имам Мотыйгулла Төхвәтуллин тарафыннан ачылган «Мотыйгия» мәдрәсәсенә укырга керә. Нәкъ менә ул үсмер малайда шигырь язу сәләтен күреп, аны шигърият сәнгатенең нигезләренә өйрәтә.

«Мотыйгия» шәкерте Габдулла тормышы турында сөйли торган витринада укудагы уңышлар өчен бирелгән мактау кәгазьләре шактый. Тукай рус мәктәбендә укырга өлгерә, Пушкинны, Кольцовны, Крыловны татар теленә зур энтузиазм белән тәрҗемә итә.

Төхвәтуллинның улы Камил Габдулланың дустына һәм фикердәшенә әверелә. Гаилә типографиясендә алар бергә татар телендә газета, ә аннан соң татар телендә «Яңа гасыр» дип аталган беренче әдәби журнал һәм татар телендә «Ук» дип аталган беренче матур бизәлешле сатирик журнал чыгаралар. Ике шәкерт тә – автор да, мөхәррир дә, корректор да, хәреф җыючы да. Тукайның үзенең күләмле әсәрләре язылуга кадәр дә инде күп калмый.

### 4 нче тукталыш

## ТЫШЛЫКТАГЫ ФОТО

Габдулла Тукай һәм аның дусты Габдулла Кариев мәдрәсәне тәмамламый калалар. Икесе дә Казанга китәргә ашкына. Берсе – үзенең китабын бастырырга, икенчесе үзенең театрын ачарга хыяллана. Җаектан киткәндә Тукайга – 21 яшь кенә, әмма ул инде атаклы автор, журналист, аның әсәрләре басыла, газета-журналларда урын ала. Иң билгеле фотопортреты (үз гомерендә беренчесе!) чираттагы басма өчен төшерелә. Музейда әлеге портретлы укучы дәфтәрләре саклана.

Тукай нинди генә күренекле булмасын, аңа кагылышлы предметлар аз. Музейда шәхси әйберләре күп түгел. Үрелгән кәрзин һәм сөлге алар арасында мөһим урынны алып тора. Тукай әлеге әйберләрне күпләгән сәяхәтләрендә үзе белән йөрткән. Аның үз йорты беркайчан да булмаган.

– Тукай бүлмә алып торган «Болгар» кунакханәсендә беренче татар китапханәсе, татар нәшрияты эшли, Шәрык клубының беренче җыелышлары уза. «Болгар» номерларында, асылда, XX гасыр татар мәдәнияте формалаша башлаган, дип әйтергә мөмкин. Кызганычка каршы, ул вакыттагы бинаны сүттеләр, – дип сөйли Елена Тябина. – Кунакханәдә шагыйрь бүлмәсенең кайсы урында урнашкан булуы турында замандашларының истәлекләрендә теркәлгән фикерләр дә төрле. Шулай да бүген шагыйрь янына кунакка кереп чыгарга мөмкин. Беренче катта безнең музейга урын бүлеп бирелде һәм без Россиядә беренче музей-витрина ачтык. Монда ул заманнардагы номерларның интерьеры торгызылган, Тукай яшәгән чор һәм аның турында электрон китапны карап чыгу мөмкинлеге дә бар. Тукай инде күптән ятим түгел. Ул – татар халкының бөек улы, аның горурлыгы. Аның тормышына багышланган экспозиция дә, иҗаты кебек үк, үзәк урын алып торырга тиеш. Шагыйрь моңа лаек.

5 нче тукталыш

## ШКАТУЛКАДА НӘРСӘ САКЛАНА

– Мин Тукайны аңладым! – дип белдерә бервакыт композитор Рөстәм Абязов. Бу сүзләрне ул Тукай апасы Газизәгә бүләк иткән фарфор шкатулканы карагач әйтә. Әлеге фарфор савытта Тукайның үзе ташлап киткән экияти Кырлайга, җете төсләргә бай татар рәсем сәнгате һәм музыкасына булган мәхәббәте яшеренгән кебек. Бөтен эчке дөньясы белән зыялы шагыйрь һәрвакыт туган халкының, аның мәдәниятенең асылына омтыла. Курай, мандолина, гармун һәм бигрәк тә кубыз – аның яраткан музыка уен кораллары. Тукай бервакыт дусларына халык җырларны ярата, аларны җырлый, ә җырның тарихын белми, дип зарланды, дип искә төшерә Габдулла Кариев. Дуслар нишләргә кирәген уйлап табалар. Тиздән шәһәрдә афишалар пәйда була: атаклы Тукай халык җырлары турында лекция укыячак. Халык күп җыела... Нәкъ менә шул кичәдә шагыйрь беренче тапкыр үзенең «Туган тел» шигырен укый. Никадәр генә сорасалар да, шагыйрь лекцияне кабатламый. Аның урынына «Милли көйләр» һәм «Милли әдәбият» дип аталган китаплар бастырып чыгара. Аның беренчесе – йозак, икенчесе – ачкыч, ди автор. Бу әсәрләр, һичшиксез, үз укучыларын таба. «Тукай – татар халкының күңеле ул», – дип язган үзенең иншасында Казан мәктәпләренең берсендә укучы 12 яшьлек Ильяс.

6 нчы тукталыш

## СӘГАТЬЛӘР КАЛА

Идән сәгатьләрен Тукай беренче тапкыр бер сәүдәгәр йортында күрә – бу хәл Казанда яшәгәндә Газизә энисе белән үзләре теккән кәләпүшләрне һәм аяк киемнәрен сатарга баргач була. Музейда сәгатьләр – һәркайда. Алар шагыйрь иҗатының еллары, көннәре, минутлары уза барганын искәртеп тора кебек. 1912 елның мартында Тукайның якын дусты – Хөсәен Ямашев үлә. Тиздән сәламәтлеге какшаган Тукай, империянең башкаласы – Санкт-Петербургны күрергә дип, озын юлга чыга.

Гимназиягә очрашуга килгән шагыйрьгә, сәфәр истәлеге итеп, бронза кара савыты бүләк итәләр. Ул сәламәтлек һәм озын гомер символы булган имән яфраклары белән бизәлгән. Кара савыты кырыенда маэмай утырып тора. Тукайга кара савыты да, маэмай да бик ошый.

– Йөгерәләр алды-артлы бер көтү

Кәкре койрыклар! – кая Башны җитү! – дип кабатлый ул «Кисекбаш» поэмасының сүзләрен, әлеге маэмайны сыйпый-сыйпый. Ул заманнарда шагыйрьнең әсәрләре патша полициясе тарафыннан җентекләп тикшерелә, беренче җыентыгына арест салыначак дигән хәбәрләр йөри – халыкның аңын уятырга омтылганы, тигез хокуклык өчен көчле пропаганда алып барганы, хөкүмәткә каршы фикерләр әйткәне өчен. Әмма Тукай үзе өчен жандармнарның да, үлемнең дә куркыныч булмавын инде аңлый:

*«Мин сыялмыйм андый шартлар, фани дөнья вакътына,*
*Башны бөксәм – зур җинаятьтер олугъ җан хакъкына.*

*Ашкынамын мин әбәд бетмәс урынга, мәңгегә,*
*Мәңгелеккә – мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!*

*Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим;*
*Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим»,* –
дип яза ул үзенең «Ваксынмыйм» шигырендә!

7 нче тукталыш

## «МИН БИЕКЛЕККӘ ОМТЫЛАМ...»

Нәни кыз тәрәзәгә күз сала да аптырап кала: йорт каршындагы мәйданга халык җыелган. Өлкәннәр аңа кешеләрнең җеназа намазына җыелуларын аңлата – бөек Тукайны соңгы юлга озатырга.

Музейның кунак бүлмәсенә кергәч, шушы вакыйганы күз алдына китерергә мөмкин. Чөнки 1914 елның апрелендә кызчык нәкъ менә шунда басып торган. Ул эти-энисе белән бергә әлеге йортның ул вакыттагы хуҗасы Вәлиулла Ибраһимовка кунакка килгән була.

Кунак бүлмәсендә бүген XX гасыр башы интерьеры яңадан торгызылган. Киштәләргә Аппаковлар, Максудилар, Хәсәниләр гаиләләренә, Ризаэтдин Фәхретдингә караган предметлар урын алган. Өйдә урнаштырылган орган өстендәге диварлардан Тукайның якын дуслары – Исхакый, Кариев, Галәү, Гыйззәтуллина-Волжская һәм башкалар карап тора. Идәндә – сәгать, ул Тукай бала чагында күргән сәгатькә охшаган. Әлеге сәгать образы кебек үк, шагыйрь яшәгән чорда башланган вакыйгалар бүгенге көн белән бәйләнгән. Шагыйрь исемендәге премия ел саен тапшырыла, тикшеренүчеләр аның тормышы турында яңадан-яңа фактларны ача тора. Без аларның бары тик бик кечкенә өлеше турында гына сөйләдек. Музейга рәхим итегез! Мөгаен, сез үзегез өчен нәкъ менә биредә Тукай турында яңа нәрсәләр ачарсыз. ■

# ҖИҢҮ ӨЧЕН БАБАЙЛАРГА РӘХМӘТ!

**Без Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган материалларны бастыруыбызны дәвам итәбез. Бүген – Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең фәнни методика бүлеге баш китапханәчесе Ольга Зуева үзенең ике бабасы турында сөйли. Алар икесе дә – бер буын кешеләре. Һәр икесенең дә тормышын сугыш баштанаяк үзгәрткән.**

## ИВАН ДМИТРИЕВИЧ

### БИК ЯКЫН, ГАДӘТТӘН ТЫШ

1978 елның 9 мае. Без, туганнан туганым Андрей белән, кызарып-пешеп, Некрасов урамындагы йортта яшәгән бабабыз Иван Дмитриевич Шаронов янына йөгереп килдек. Ул безне тулы «парад»та – күкрәгенә орден һәм медальләрен тагып көтеп тора иде инде. Андрей тиз генә пионер галстугын такты да, без өчәүләп Ирек мәйданына юл алдык. Менә-менә бәйрәм парады башланачак, бабайның безнең белән шөгыльләнеп торырга вакыты юк, шуңа безне тиз арада җитди костюмлы бер оештыручы кулына тапшыра. Ә ул безне кунаклар трибунасына озатып куя, без шуннан яныбыздан гына үтүче хәрбиләрне һәм курсантларны күзәтәбез. Андрей горур рәвештә аларга пионер салюты биреп тора. Парадның иң ахырында мәйданда ветераннар пәйда була. Өлкән яшьтә булуларына карамастан, барысы да хәрбиләрчә тигез адым белән атлый. Алар арасында – безнең бабабыз, шундый ыспай, күңелгә шундый якын! Һәм аның һич тә як-ягына карану чамасы булмаса да, бер генә секундка безнең якка күз сирпеп ала, һәм безнең карашларыбыз очраша. Мин беркайчан да бабамның ул карашын, җиңүчеләрнең медальләре чыңлавын һәм мәйданны биләп алган ул тантаналы тынлыкны онытмаячакмын.

Фотолар Ольга Зуеваның гаилә архивыннан алынды

## ПЛЯЖГА ҖЫЕНГАН БУЛГАН, СУГЫШКА ЭЛӘККӘН

Берничә кешегә җитә алырдай язмыш. 1906 елда Зөя өязенең (Югары Ослан районы) Рус Макылы авылында ишле крестьян гаиләсендә туган ул. Яланаяклы балачак, яшьлек, ике класс белем алу. Бик күпләрнеке кебек үк, тормышы ярлы булган, хезмәт белән үткән. Кечкенәдән үк бабай икмәк сыныгының бәясен белгән. Батрак булган, җигелеп эшләгән, Татарстан совет партия мәктәбендә укыган, эшче-крестьяннарның Кызыл Армиясендә хезмәт иткән. Нәкъ менә сугыш башланыр алдыннан, 1940 елда, аны Лиепая шәһәренә комсостав әзерләү курсларына җибәргәннәр, һәм бабай сугышны аэродром ротасы командиры вазыйфасында каршы алган.

Чехословакия (Шаронов уңда).

Иң соңгы фотографияләрнең берсе.

1941 елның 22 июнендә өлкән лейтенант Шаронов гаиләсе белән пляжга җыенган. Тик барып чыкмаган. Сугышның якынаюын сизеп торса да, ахыргача моңа ышанасы килмәгән. Беренче сәгатьләрдә үк ул хатыны белән кызын Казанга туганнары янына озаткан да, үзе фронтка киткән. Мәскәү, Курск, Орёл янындагы коточкыч сугышлар, иптәшләрен югалту. Курск янында тиз арада аэродром төзү өчен аны Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләгәннәр. Шундый ук икенче орден – Киев өчен. Бабай 4 нче Украина фронтының инженерлык-аэродром батальоны составында Польшаны азат иткән, сугышны майор званиесендә Чехословакиядә тәмамлаган. Тыныч тормышка 1948 елда гына әйләнеп кайткан. Иван Дмитриевич өчен гаиләсе, табигать, балык тоту һәм үз куллары белән төзегән безнең дачабыз тормыштагы иң мөһим, кадерле нәрсәләр булып әверелгән.

# ВАСИЛИЙ ИВАНОВИЧ

### ТАБИГАТЬ ҺӘМ ШИГЪРИЯТ – ИКЕ МӘХӘББӘТЕ

Бабайның шундый кызыклы гадәте бар иде: ул эчтәлекле итеп табигать турында көндәлекләр алып барды. Дәфтәр битләрендә, календарьларда тыгыз почеркы белән бүген нинди һава торышы булуын яза, кояш, яисә яңгыр тамчыларын, кар бөртекләрен ясап куя. Әгәр кул астында кәгазь булмаса, хәтта дача верандасының такта стеналары да ярый эшкә. Беркем дә аңа үпкәләми – бабайга язу ошый икән, язсын. Бу аның мәхәббәте иде. Шигърият кебек үк. «Сережка»ны – бабай Есенинны шулай дип атый иде – барысыннан да аерып яратты. Күрәсең, шагыйрьнең шигырьләре аңа үз балачагын һәм яшьлеген искә төшергәндер. Бервакыт Актёрлар йортына башкала артистларыннан кемдер килгән иде, кем икәнен хәтерләмим, бу мөһим дә түгел. Иң мөһиме – ул Есенин шигырьләрен укыды. Менә бабай шунда йөрде. Үзе белән шигырьләр китабын ала иде дә, ләззәтләнеп тыңлый иде...

### РӘСМИ ПАТРИОТИЗМНАН БАШКА

Сугыш турында искә төшерергә яратмый иде. Тик, партияле буларак, аңа шундый эш куштылар – балалар янына барып, аларга героик үткәннәре турында сөйләргә, һәм ул сөйли иде. Безнең мәктәпкә дә килде. Бабайның пафослы булмаган истәлекләреннән иң хәтердә кала торган җөмләсе: «Бу бик куркыныч, балалар!» Бүтән бернинди дә бәя дә бирми иде...

### ЯРАТУНЫҢ ТЫЙНАК СҮЗЛӘРЕ

Әбине бик яратты. Юкса, моны кычкырып йөрү кабул ителмәгән иде. Ә менә әбием, Калиста Владимировна авырып киткәч, мин ирексездән аның әнием белән сөйләшүенә шаһит булдым. Бик кыенсынып кына тыныч тавыш белән ул әнигә, больницада әби янында утырганда, аны үбүе турында сөйләде.

Ә инде Иван Дмитриевич авырып киткәч һәм дәвалауның файдасы булмавы аңлашылгач, без, бергә яшәү һәм аны карау өчен, аның янына күчендек. Хәтеремдә бер көнне шулай эшкә чыгып китүем. Бабай караватта ята. Мин аңа: «Сау бул», – дидем. Ул да миңа: «Сау бул», – диде. Аннары без күрешмәдек инде.

### ИСТӘЛЕК БУЛАРАК – ЙОРТ ҖИҺАЗЫ

Бер караганда әллә ни кыйбат та саналмаган кайбер әйберләр һәм предметлар кемне дә булса хәтерләткән истәлек буларак бәһасез була. Минем өемдә алтмыш еллап элек икенче бабам Василий Иванович Зуев ясаган шкаф-солдатик тора. Савыт-саба шкафы. Ул шулкадәр нык һәм сыйфатлы ки, чит ил кибетләренең заманча җиһазлары бер читтә елап торырлык. Барлык туганнарыбызның да йортларында Вася бабайның столярлык мирасыннан ни дә булса бар – табуретка, шкаф, киштә, өстәлләр... Көче барда: «Кызганыч түгел», – дип, барысына да нидер ясаган. Куллары алтын булган бит.

### ӘБИНЕҢ КОТКАРУЧАН СИЗГЕРЛЕГЕ

Аны барысы да үз итеп «дядя Вася» дип кенә йөрткән. 1907 елның апрелендә Питрәч районының Яңа Никольск авылында туган ул. Башлангыч мәктәпнең өч классын тәмамлаган. 1930 нчы еллар башында гаиләсе белән Казанга күчеп килгән. Минемчә, бу күчену аның урта хәлле ныклы гаиләсен туздырылудан саклап калгандыр. Әйе, кыенлыклар күргәннәр, әйе, күп әйберләрен талап алганнар, әмма үзләре, Аллаһка шөкер, исән калганнар бит. Шура әбекәй «җилнең каян искәнен» чамалый белгән, авылдан Казанга күчену дә аның ихтыяры булган. Бәхеткә, сөрелүләр һәм репрессияләрдән читтә калганнар...

Сугышчан дуслары белән бергә (Василий Зуев уртада баскан).

## ЙОМЫК «ДЯДЯ ВАСЯ» – ГЕРОЙ-АРТИЛЛЕРИСТ

Василий Зуев фронтка 1941 елда чакырыла, башта – наводчик, аннары, сугыш башланып, бер ай үткәннән соң артиллерия установкасы командиры була. Волхов фронтында, соңыннан Воронеж янында сугыша. 1943 елның 28 гыйнварында Курск өлкәсенең Касторное бистәсен азат итү өчен каты сугыш бара. Шул бәрелештә кече сержант Василий Зуевка пулялар яңгыры һәм көчле миномёт уты астында үз орудиесе белән дивизион установкаларының көченүен каплап торырга туры килә. Чынлыкта аныңниләр кичерүен чамалау да авыр. 1943 елның 5 март приказы белән ул «Батырлык өчен» медале белән бүләкләнә. Фронтовиклар арасында бу медаль бик югары бәяләнә. Бабай бик тыйнак һәм партизаннарча сөйләшмәүчән була. Мәсәлән, аның Курск дугасында күрсәткән батырлыгы турында якыннары сугыш бетеп, еллар үткәч кенә белгәннәр, һәм гаҗәпләнүдән «ачкан авызларын яба алмый» торганнар. Тыйнак кына «дядя Вася» образы герой-артиллеристка һич туры килми кебек...

Сугыштан соң бабай күп еллар балта остасы булып эшли, бакча үстерә, оныкларын бер дә игътибарыннан калдырмый.

## АВЫЛ ТӘРБИЯСЕ

Аның тыныч темпераменты туган апабыз сөйләгәннәр белән дә ярашмаган шикелле: игелекле, тотнаклы Вася бабакай яшьлегендә үзенең мәхәббәте Шура әбекәй өчен авылның бөтен егетләре белән сугышып чыккан. Ошаган ул аңа һәм бетте-китте! Тыныч, сабыр Василий бабай бик максатчан булган, һәрвакыт гади генә, тик турысын әйтеп, икейөзлеләнмичә сөйләшә иде – гомумән, әби белән икесе дә халыкның үз арасыннан иде. Беренче тапкыр бакчаларына килгәч, шаккатуым әле дә исемдә. Озын-озын кишер, чөгендер, суган түтәлләре – чып-чын плантацияләр. Авылда үскән кешеләр буларак, алар җирне гади участок кына дип түгел, ул, һичшиксез, ни дә булса үстерергә тиеш дип исәпләгәннәр...

## БАРЫСЫНА – БЕР

Минем ике бабам – ике фронтовик, ике темперамент, ике дус... Бөтен гаилә бәйрәмнәрендә алар кайдадыр берәр почмакта янәшә утырырлар иде. Әбиләрдән ерактарак. Шундый төрлеләр һәм шундый ук бертөслеләр. Берсе – инанган коммунист, икенчесе беркайчан да комсомол да булмаган. Икесе дә авылдан, хезмәт кадерен беләләр. Алар хәтта якынча бер үк вакытта күн эшкәртү трестында эшләгәннәр, бәлки сугышта да янәшә диярлек булганнардыр. Язмыш аларны сугыштан соң таныштырган, алар оныкларын бергәләп үстерделәр, безнең уңышларга шатландылар. Холыкларының, белемнәренең төрле булуына карамастан, аларның сөйләшер сүзләре күп иде. Хәтта каты авыру килеш тә бабабыз Иван Дмитриевич үзенең авылдагы кодасы Василий Иванович янына бара иде. Аларның дуслыгы нык, чын ирләрчә булды.

Икесенең дә тормышында – фронт, яраланулар, госпитальләр, ә соңыннан – Җиңү. Сугышны искә төшерергә яратмадылар, бу турыда китаплар һәм кинолар бар, диләр иде. Чөнки Җиңүгә ниләр бәрабәренә ирешелгәнне яхшы беләләр иде.

# МИЛЛИ ТӘРӘККЫЯТ ЮЛЫНДА: ХӘСӘНГАТА ГАБӘШИ

**Автор:** Илдус Заһидуллин

**Мәктәп-мәдрәсәләр өчен язган дәреслекләре, Мәхкамәи шәргыядә казыйлык эшчәнлеге аны Хәсәнгата Габәшине XIX гасыр азагы зыялылары арасында төбәкнең интеллектуаль лидеры итеп таныта. Габәшинең 4 нче чакырылыш Дәүләт думасына сайлаулар вакытында Уфа губернасы мөселманнары тарафыннан депутат итеп күрсәтелүе XX гасыр башында бу шәхеснең гомуммилләт әйдәманына әверелүе турында сөйли. Ләкин ул, милләт өчен файдасы зуррак булыр дип, урынын юрист Ибнеәмин Әхтәмевкә бирә.**

## БЕЛЕШМӘ

Хәсәнгата Габәши 1863 елның 11 гыйнварында Кече Солабаш авылы мулласы гаиләсендә дөньяга килә. 1874–1889 елларда, 11 яшеннән, Казанда, Әҗем мәчете каршындагы «Гаффария» мәдрәсәсендә укый һәм хәлфәлек итә.

Габәшинең милләткүләм әһәмиятле бик күп вакыйгаларда катнаша. Санкт-Петербургта уздырылган IV мөселман съездында (1914 елның 15–25 июнь көннәре), 1917 елның 1–11 маенда Мәскәүдә булган I Бөтенроссия мөселманнары съездында Президиум әгъзасы буларак катнаша. Аның кандидатурасы мөфтилеккә тәкъдим ителә. 1917 елның июль аенда Казанда узган Бөтенроссия мөселман руханилары съездында Мөселман руханилары союзының рәисе итеп сайлана, II Бөтенроссия мөселман съездында федералистик проектны яклап чыгышлар ясый. Уфада җыелган Милләт мәҗлесендә катнашып, «туфракчылар»ны яклап чыга, Милли идарәнең мәгариф бүлегендә хезмәт куя.

1932 елның башында кулга алынып, Архангельск өлкәсенә лагерьга сөрелгәндә аңа 70 яшь була. 1936 елда, сәламәтлеге какшау сәбәпле, ирекккә чыгарыла. Туган авылына кайтып вафат була.

Фотолар автордан алынды

## МӘРҖАНИНЕ ЧӘКЧӘК МӘҖЛЕСЕНӘ ЧАКЫРГАН ХӘЛФӘ

Габәши истәлекләрендә «Гаффария» мәдрәсәсендә үзенең 12 еллык шәкертлек һәм 5 еллык хәлфәлек тормышында ике мөһим факторны билгеләп үтә. Беренчесе – мәдрәсә программасын уңышлы тәмамлаудан тыш, үзлегеннән рус телен, география, геометрия, хисап, тарих һәм башка гыйлемнәр үзләштерүе. Бу Габәшине актив, белемгә омтылучан, мөстәкыйль фикерле, русча газета һәм китаплар укучы шәхес буларак характерлый. Аның кешеләр белән мөнәсәбәтләр кора белү осталыгын да әйтми мөмкин түгел. Хәлфә вакытында «Гаффария»дәге остазы урынына шәһәр төрмәсенә барып әҗерсез мөселман тоткыннарының дини ихтыяҗларын үтәп йөрүе дә күп нәрсә турында сөйли.

Икенче фактор – яшь кешенең дөньяга карашын һәм гражданлык позициясен формаштыруга йогынты ясаган интеллектуаллар белән аралашуы, алар даирәсенә керүе. Әйтик, Казан муллалары арасында Мәрҗанигә нигездә караш уңай булмаса да, хәзрәтнең хезмәтләрен укып, аның олы галим булуын танып, даими аралашып, хәтта биографиясен язарга теләк белдереп, материаллар да сорап каравы аның зиһенле һәм кыю шәкерт икәнен дәлилли. Хәзрәт тә аны якын итә, чакыргач, 1887 елны хәлфәнең чәкчәк мәҗлесенә килеп, хөрмәтен дә күрсәтә, бер хезмәтен укып, төзәтеп, бастырырга рөхсәт бирә.

Ул татар мәгърифәтчеләре Каюм Насыйри, Гали Мәхмүдов, Шаһбазгәрәй Әхмәрев, Галимҗан Баруди, шулай ук университет галимнәре Иосиф Готвальд, Николай Катанов һәм башкалар белән аралаша. Исмәгыйль Гаспралы белән очрашу, фикер алышу да дөньяга карашын киңәйтеп җибәрә.

1889 елдан ул Казан сәүдәгәрләре – бертуган Юнысовларның мөселман балалар ятимханәсе мәктәбенә эшкә урнаша, биредә 1891–1892 уку елларында, шәһәрдә беренчеләрдән булып, укырга өйрәтүдә аваз ысулын (әлифба) куллана.

## ХАЛЫК ТЕЛЕ ВӘ ХАЛЫК ТАРИХЫ

Мәгърифәтче рухлы яшь хәлфәнең беренче әсәрләре шәкертләр, укучы балалар өчен мөһим саналган темаларга – педагогика һәм балаларның шәхси гигиенасына багышлап язылган. 1889 елда Габәшинең «Тәрбияле бала» исемле китапчыгы дөнья күрә, анда үзеңне тоту кагыйдәләре бәян ителә. «Сагълык» (1890) төрле авыруларга каршы торуны, шәхси гигиена кагыйдәләрен аңлата, ул русча китаплардан тәрҗемә итеп әзерләнгән була.

26 яшьлек мәгърифәтче татар зыялылары арасында «Басыйрәт» («Аңлылык», 1889) хезмәте белән танылу ала. Җәдитчеләр басмасына әверелгән «Тәрҗеман» газетасы әлеге китапка югары бәя биреп, мактап язып чыга, Риза Фәхретдин, Фатих Кәрими һ.б. зыялылар да, авторга уңышлар теләп, тәбрикләр җибәрәләр. Бу китапның үзегенә «милләтне гыйлем алга җибәрә» концепциясе куелган була. Автор мөселманнарның урта гасырларда ирешкән ачыш-казанышларының, фикерләренең Европа гыйлемен үстерүгә йогынтысын ассызыклап, бүгенге Урта Идел төбәгендә яшәүче милләттәшләренең мескен хәленә ишарә ясый һәм узган заман мөселманнарының уңышларын үрнәк итеп, гыйлем ияләре Ибн Сина, Фәраби һ.б. турында яза.

Хәсәнгата Габәшинең тарих буенча уку китаплары эшләве махсус игътибарны һәм өйрәнүне сорый. Милли тарихны өйрәнүнең әһәмиятен ул үзе болай аңлата: «Тарихта хәбәре булмаган вә үз үткәнен танымаган кавемнәр хакыйкый вә ныклы милләт булып яши алмый».

Авторның тарих буенча беренче хезмәте – «Төрек ыруглары» 1897 елда башлангыч мәктәпләргә атап язылган, энциклопедик планда кыскача мәгълүмат бирә. 1898 елда бастырылган «Кыскача төрек кавеме тарихы» китабы исә мөдәррисләр, шул исәптән Галимҗан Баруди үтенече буенча урта мәктәп шәкертләре өчен әзерләнгән.

Авторга танылу һәм шөһрәт китергән «Төрек кавеменең җентекле тарихы» китабы 1909 елда Уфада «Шәрык» матбагасында басыла. Татар халкының этногенезы мәсьәләсендә Шиһабетдин Мәрҗанинең болгар концепциясе тарафдары булган Хәсәнгата Габәши, татар тарихчылары арасында беренче булып, төркиләр тарихының төп этапларын аерып чыгара. Аныңча, «борынгы чор» Идел буе Болгар дәүләтен монгол гаскәрләре 1236 елда җимерү белән тәмамлана, «урта гасырлар» 1552 елда Казан ханлыгы егылганга кадәр дәвам итә, руслар кулындагы чор «яңа тарих» була.

## КАЗЫЙЛЫК ЭШЧӘНЛЕГЕ

Хәсәнгата Габәши мөфти М. Солтановка Мәхкәмәи шәргыяны реформалаштыру проекты төзеп җибәрә… һәм казый булырга чакыру ала.

Беренче казыйлык чорында башкарган иң зур хезмәте 1898 елда Уфа шәһәрендә «Ислах лисан төрки, ислах мәктәп һәм нәшир мәгариф әл-мөслимин» иҗтимагый оешмасын оештыру, аның җыелышын уздыру була. Җыелышта берничә олы мәсьәлә тикшерелә һәм аларның һәрберсе буенча карар кабул ителә. Утырыш карарларының проектларын Хәсәнгата Габәши үзе әзерли.

Беренче бурыч итеп гади халык телендә китаплар язу кирәклеге турында карар һәм кайбер язу кагыйдәләре кабул ителә, төрки телнең морфологиясе һәм синтаксисы Каюм Насыйриның, Хөсәен Фәизхановның фәнни хезмәтләре нигезендә язылыр, дип белдерелә.

Икенче бурыч – дүрт еллык җәдит башлангыч мәктәбен, аның укыту программаларын төзү, һәр сыйныфта укытылачак предметларның исемлеген булдыру. Алар арасында намаз шартлары, дини предметлар белән беррәттән, кыскача география һәм төрки кавем тарихы, хисап, геометрия нигезләре кебек дөньяви фәннәр карала. Ләкин рус телен укыту программага кертелми, ягъни башлангыч белемне укучылар фәкать туган телләрендә алырга тиеш дигән фикер уздырыла. Шулай ук, башлангыч мәктәп өчен кирәк булган ун дәреслек тәгаенләнеп, аларның авторлары билгеләнә, шул исәптән төрки кавемнең тарихын язу Хәсәнгата Габәшигә йөкләнә.

Бу чарадан соң кадимчеләр Хәсәнгата Габәшине хаксыз сүзләр белән рәнҗетәләр, мондый мөгамәләне казый авыр кичерә, чиргә сабыша һәм, табиблар киңәшен тотып, туган авылына кайтып китә. Шул сәбәпле җәмгыять башка җыелмый, ләкин сөйләшенгәннәр буенча эш башланып китә.

Хәсәнгата Габәшинең икенче тапкыр 1908 елны Мәхкамәи шәргыягә чакырылуына казый Хәйрулла Госмановның вафаты сәбәп була. Бу юлы да Габәши, мөфтинең уң кулы буларак, М. Солтанов авырганда яки шәһәрдән киткәндә аның вазыйфасын башкарып тора.

Дини идарәнең «Мәгълүмате Мәхкамәи шәргыя Оренбургия» исемле журналын чыгару 1908 ел азагында казыйларга калгач, Хәсәнгата Габәши үзе теләп күп көч һәм вакыт сорый торган рәсми булмаган бүлек материалларын басмага әзерләүгә алына һәм мәкаләләре белән, үзе әйтмешли, «мөмкин кадәр укучыларның күзен ачарга тырыша». 1910 елда журнал ябылгач, казыйның буш вакыты арта, һәм ул башы-аягы белән җәмәгать эшенә чума.

Оренбург «Хөсәения» мәдрәсәсенең мөтәвәллиләр идарәсе әгъзалары. Утырганнар (уңнан сулга): Нурмөхәммәт казый Мәмлиев, Гыйниятулла казый Капкаев, Хәсәнгата казый Габәши, Габделгалим хәзрәт Дәүләтшин; басып торалар: Мәхмүт Госманов, Хәсәен Акчурин, Закир Рәмиев (Дәрдмәнд), Гайса Еникиев, Мәхмүт бай Хөсәенов, Габделхәмит Хөсәенов, Фатыйх Кәрими, Закир Хәеров. Оренбург, 1909 ел.

Габәшинең оештыру осталыгы 1911 елны М. Солтановның мөфтилек хезмәтенә 25 ел тулу уңаеннан уздырылган чараларда калку күренә. Җәдитчеләр юбилейны укытучылар семинариясе ачтыру өчен файдаланырга тырышалар. Тантаналы олы җыелыш 19 май көнне юбилей комитеты рәисе ярдәмчесе Хәсәнгата казый җитәкчелегендә уза, анда шәһәрдә укытучылар семинариясе ачарга кирәк дигән карар кабул ителә. Юбилей комитеты, ике ай дәвамында юристлар һәм педагоглар белән киңәшләшеп, проект әзерли. Тик башкала хакимияте башлангычны якламый – куелган хезмәтләр җилгә оча...

## ЗЕМСТВОДАГЫ ХЕЗМӘТЕ

Уфа губерна земствосы каршындагы Мәскәү авыл хуҗалыгы җәмгыятенең филиалында әгъза булып тору Хәсәнгата Габәшигә губернада мөселманнардан билгеләү өчен бер ярдәмчесе булган агроном штаты алырга, земство хисабына авыл хуҗалыгында яңа технологияләр турында китапларны земство хисабына татар теленә тәрҗемә иттереп бастырырга мөмкинлек бирә. Бу өлкәдә Уфа земствосының уңышлары зур була.

Казыйның Уфа губерна земствосы управасының мәгариф бүлегендә алты ел буе әҗерсез эшләү вакытындагы тырышлыклары аерым игътибарга лаек. Беренче чиратта, Хәсәнгата казый мөселман мәктәпләренә матди ярдәм һәм ана телендә укыту өчен уку әсбаплары бастырып чыгаруда булышлык итә.

1911 елның 23–25 май көннәрендә мөселман гомумбелем бирү мәктәбе мәсьәләсе буенча Уфа губерна земствосы управасындагы киңәшмәдә

милли башлангыч мәктәпнең 5 еллык укыту программасы раслана (уку предметлары: туган тел һәм рус теле, дин белеме, арифметика, география, тарих, табигать белеме, геометрия, рәсем, гимнастика, малайлар өчен хезмәт һәм кызлар өчен тегүчелек дәресләре). Җәдит уку йортлары өчен уку әсбапларын Габәши җитәкчелегендәге комиссия экспертиза уздырып куллануга тәкъдим итәргә тиеш була.

1912 елда Уфа губерна земствосы идарәсендә оешкан «инородческий» белем бүлегенә Хәсәнгата Габәши һәм аның тарафдарлары мөдир итеп Казан татар укытучылар мәктәбен тәмамлаган Гомәр Терегуловны билгеләтүгә ирешәләр. Терегулов җитәкчелегендә земство идарәсендә мәктәптән тыш уку өчен медицина, авыл хуҗалыгы буенча фәнни-популяр брошюралар бастыру җайга салына, авылларда китапханәләр ачыла, терлекчелек, бакчачылык, умартачылык курслары эшләп китә.

## МУЗЫКАНЫ ЯКЛАП КЫЛГАН ТЫРЫШЛЫКЛАРЫ

Милли һәм дини җәмгыять тормышын яңача кору омтылышы искелек тарафдарлары каршылыгына очрап тора, мондый чакларда казыйның дәлилле төзелгән фәтвалары әһәмияткә ия була. Хәсәнгата казый Уфа каласында музыкаль кичәләр уздыруны яклаучы һәм аларны оештыручы буларак та танылa. Вакытлы матбугатта музыканы яклап бәхәсләрдә катнашу, махсус мәкаләләр язу һәм Уфа җәмгыяте хәйрия мәҗлесләрендә бу эшнең ислам диненә каршылыгы юклыгын дини китапларга таянып чыгышлар ясавы тулы бер хәрәкәткә әйләнә: Уфадагы «Галия», «Госмания» кебек мәдрәсә шәкертләре катнашында музыкаль, әдәби кичәләр уздыруга дини-хокукый нигез шулай калыплаша.

Үзе, балаларының музыкага тартылуларын белеп алып, улы Солтанәхмәтне һәм кызы Рокыяны музыка укытучысына шөгыльләнергә бирә.

1909 елдан шәһәр җәмгыяте активистлары белән бергә музыкаль кичәләр оештыруда актив катнаша башлый. Сәлимгәрәй Җантурин һәм Хәсәнгата Габәши, Уфа мәдрәсәләреннән, хөкүмәт мәктәпләрендә укучылардан, хезмәткәрләрдән катнаш төркем туплап, үзләренең йортларында репетицияләр ясаталар. Ул казыйлыктан киткәнче, Уфа каласында «залга сыймаслык кадәр халык» җыелган мәдәни чаралар уздырылып килә. Шушы кичәләрдә аның улы Солтанәхмәт (булачак беренче татар композиторы) пианинода үзенең беренче әсәрләрен башкара («Кәккүк», «Рокыя», «Пикник», «Татар кызы» һ.б.).

Табигать кочагында. Уңнан сулга: Хәсәнгата Габәши, Баһаветдин Максудов, аның ике улы, Солтанәхмәт Габәши (скрипка белән), Мөхәммәтһади Килдебәки. Уфа, якынча 1913 ел.

## УФАДАГЫ ИҖТИМАГЫЙ ТОРМЫШ

Хәсәнгата Габәшинең оештыру өлкәсендәге уңышлары ул вакыттагы шәһәр мөселман җәмгыятендәге мәдәни һәм иҗтимагый активлык, җәдитчеләр, мәгърифәтчеләр, язучылар – зыялылар һәм интеллектуаллар булу белән дә аңлатыла.

Улы Солтанәхмәт, «Галия» мәдрәсәсен тәмамлап, реальный училищега керә. «Аталар җәмгыяте» идарәсенә сайланган Хәсәнгата Габәши мохтаҗ мөселман балаларына, өс-баш, аяк киемнәре, уку-язу әсбаплары белән дә ярдәм итеп, укуларын уңышлы тәмамларга булыша. Уфадагы «Педагоглар җәмгыяте»ндә әгъза булгач, ул анда тарихи темаларга лекцияләр укып гына калмый, бу җәмгыятькә русча белгән мөгаллимнәрне дә тарта. Шәһәрдәге Гомумхалык университетында үзе катнашында ачылган мөселман секциясендә эшли башлый, земство управасы залында халык өчен шулай ук төрле темаларга лекцияләр белән чыгыш ясый.

Хәсәнгата казый «Госмания» мәдрәсәсе бинасында һөнәр мәктәбе ачуга булышлык күрсәтә, бу уку йортында Габдулла Шинаси белән бергә мөгаллимлек итә. «Галия» мәдрәсәсенең попечительләр советы идарәсендә әгъза булып тора, шулай ук кайсы вакыт гигиена, башка шундый гомуми, ләкин шәкертләрнең көндәлек тормышлары өчен әһәмиятле темаларга лекцияләр укый.

Уфада губерна төрмәсендәге 450 тоткын мөселманны «гыйлем нуры белән нурландыру» өчен, Габәши башлангыч мәктәп ачтыруга ирешә (мәктәп йорты сыйдыра алмаганнан, һәр көн ике мәртәбә иллешәр кеше укытыла), казна хисабына дәреслекләр алдыртып, укытучы билгеләтеп, үзе дә атнага ике тапкыр килеп дәресләр бирә. Белем алучы тоткыннарны төрмәдә урнашкан сәнәгатьханәдә һөнәр үзләштерергә күндерә. Хәсәнгата Габәши истәлекләрендә әҗерсез башкарган шушы гамәлен «үз гомеремдәге халык хезмәтләремнән зурысы итеп карыйм», дип бәяли.

Милләт мәҗлесенең «туфракчылар» төркеме. Икенче рәттә – уңнан бишенче Хәсәнгата Габәши. Уфа, 1917 ел.

## АВЫЛ МУЛЛАСЫ

Габәши 1890 елдан туган авылында имам-хатыйб вазыйфасына керешә. Ул 1893–1894 уку елыннан үз йортында җәдит ысулы белән укыта башлый. 1899 елны, Уфадан кайткач, Әхмәт бай Хөсәеневтән үтенеп туган авылында зур мәктәп салдыра, бай хисабына үз янына тагын бер мөгаллим ала. Нәтиҗәдә, волостьта иң яхшы уку бинасына ия булган Кече Солабаш авылында барча кеше белемле, укый-яза белә. Мәктәп 1917 елга кадәр 50ләп мөгаллим әзерләп чыгара, шуларның яртысы педагогик эшчәнлекләрен совет мәктәпләрендә дәвам итә.

Совет хакимияте урнашкач, аның төбәк ихтыяҗын күздә тотып һәм имамлык шөгыленә бәйле рәвештә мөгаллимлек хезмәте һәм мәгариф өлкәсендә башкарган оештыру эшләре шулай ук игътибарга лаек. Мулла Арча кантон мәгариф бүлеге үтенече буенча үз йортында 2 нче баскыч совет мәктәбе ачып, анда мөгаллим һәм мөдир булып эшли башлый. Алат волосте укытучыларына тарих һәм төбәк тарихы буенча дәресләр бирә, волость укытучылары белән Себергә, Урал тауларына, Свердловскига һәм Омскига экскурсияләргә бара. ТАССРның Үзәк музеена экспонатлар туплауда булыша. 1923 елны Эчке Россия һәм Себер мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәтенең Голәмәләр шурасы әгъзасы итеп сайлана. 1932 елда кулга алынганчы шунда эшли.

махсус проект
«ТАТАРСТАН»
ЮБИЛЯРЛАРЫ
57
ЧЫГАРЫЛЫШ

**Александр Штром,** ТРның Тарифлар буенча дәүләт комитеты рәисенең беренче урынбасары, октябрьдә үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

**Рәүзил Хаҗиев,**
«Татэнерго» АҖ
генераль директоры

## ЧЫН БЕЛГЕЧ һӘМ ЗИРӘК ҖИТӘКЧЕ

– Хөрмәтле Александр Леонидович!

Сезне «Татэнерго» АҖ хезмәткәрләре коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән ихлас тәбрик итәм! Сез куйган хезмәтегез һәм шәхси кешелеклелек сыйфатларыгыз нәтиҗәсендә абруй яулап, энергетика өлкәсендә зур уңышларга ирештегез. Хезмәт юлыгыз гади эшче буларак башланган. Сез техник һөнәреннән башлап, Татарстанның мөһим ведомствосында җитәкче вазыйфаларга кадәр булган хезмәт юлын үтеп, Татарстан Республикасының Тарифлар буенча дәүләт комитетын рәисенең беренче урынбасары итеп билгеләндегез һәм «Атказанган энергетик» дигән республика дәрәҗәсендәге мактаулы исемгә лаек булдыгыз.

Шушы еллар эчендә үзегезне компетентлы белгеч, зирәк җитәкче һәм югары әхлаклы шәхес итеп күрсәттегез. Сез олы тәҗрибә тупладыгыз, чын дусларга ия булдыгыз. Сезне хаклы рәвештә үземнең хезмәттәшем, иптәшем итеп саныйм һәм Сезнең олы һөнәр иясе булуыгызга сокланам.

Хөрмәтле Александр Леонидович! Сезгә яңа казанышлар, ныклы сәламәтлек, тынычлык һәм иминлек телим!

Реклама

**Валерий Сазанов,**
«Газ-транспорт компаниясе» ҖЧҖнең
генераль директоры

## ЭНЕРГЕТИКАГА КЕРТКӘН ӨЛЕШ

– Хөрмәтле Александр Леонидович!

«Газ-транспорт компаниясе» ҖЧҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән Сезне 60 яшьлек юбилеегыз белән котлыйм!

Сезнең тормыш юлыгызның һәр сәхифәсе Татарстан Республикасы сәнәгате үсеше белән бәйләнгән. Дүрт дистә ел эчендә Сезнең тирән белемегез, менә дигән кешелеклелек һәм эшлеклелек сыйфатларыгыз, оештыру сәләтегез, югары һөнәри осталыгыгыз Сезне абруйлы һәм ихтирамга лаек кеше итеп танытты!

Безгә Сезнең белән республика өчен әһәмиятле бурычларны хәл иткәндә, бергә эшләргә туры килде. Без Сезнең үзенең һөнәри фикерен әйтә белгән һәм башкаларны да шуңа ышандыра ала торган җитәкче икәнлегегезне күрдек.

Бай тәҗрибәгез, остаз буларак әзерлегегез ТР Тарифлар буенча дәүләт комитетының күп белгечләренең нәтиҗәле эшенә нигез булсын һәм киләчәккә ышаныч белән карарга мөмкинлек бирсен. Сезне алга таба да файдалы һәм кирәкле эшләр көтүенә ихлас ышанам.

Хөрмәтле Александр Леонидович! Чын йөрәктән Сезгә ныклы сәламәтлек, алга куелган планнарыгызның уңышлы итеп гамәлгә ашуын, көч-куәт, көндәлек бурычларны хәл иткәндә ныклык һәм сабырлык телим! Янәшәгездә һәрвакыт Сезне аңлый торган кешеләр булсын, туганнарыгызның һәм якыннарыгызның күңел җылысы яңа казанышларга ирешергә этәрсен! Юбилеегыз белән!

Реклама

Фотолар «Татэнерго» АҖ һәм «Газ-транспорт компаниясе» ҖЧҖнән алынды

Татарстан агросәнәгать комплексында нәтиҗәле эшли белгән һөнәр осталары белән дан тота. Республиканың авыл хуҗалыгында иң абруйлы һәм хөрмәткә лаек кешеләрнең берсе – Россиянең Татарстан Республикасы буенча Авыл хуҗалыгы күзәтчелеге идарәсе җитәкчесе, Баулы якташлар җәмгыяте башлыгы **Нурислам Хәбипов**. Быел Нурислам Нуриман улы үзенең 65 яшьлеген бәйрәм итә.

# ❝ РЕСПУБЛИКА ИМИНЛЕГЕ ХАКЫНА

Яшүсмер вакытында ук Нурислам хезмәт сөючәнлеге, максатка омтылучанлыгы һәм туган җирен яратуы белән аерылып тора. Исергәп авылында туып-үскән егетне әти-әниләре кыр эшләренә өйрәтеп үстерә, соңыннан исә ул аның тормыш мәгънәсенә әйләнә. Нурислам Нариман улы агроном, совхоз директоры, авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы булып хезмәт итә. Перспективалы авыл хуҗалыгы белгеченең идарә итү осталыгын тиз күреп алалар, һәм Минтимер Шәймиев указы белән ул Баулы районы башлыгы итеп билгеләнә. Аннан соң яңа үрләр – аңа экология өлкәсендәге вазыйфаны йөклиләр – ул вакытта Хәбипов табигатьне саклау эшчәнлеге кысаларында бик күп эшләр башкара. Менә 10 ел инде Хәбипов Ветеринария һәм фитосанитария күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең ТР буенча идарәсе җитәкчесе вазыйфасында хезмәт итә һәм илнең азык-төлек һәм биологик куркынычсызлыгын тәэмин итә. Россиянең ТР буенча Авыл хуҗалыгы күзәтчелеге идарәсе үтә дә әһәмиятле эш белән шөгыльләнә: ветеринария, карантин, үсемлекләрне саклау, бөртекләләр һәм аларны эшкәртү сыйфатын тәэмин итү, авыл хуҗалыгы культуралары орлыкларын җитештерү, авыл хуҗалыгы җирләрен саклау һәм файдалану өлкәсендә контрольлек-күзәтчелек итү вазыйфаларын башкара.

Бу хезмәт бөтен республиканың авыл хуҗалыгы көйле эшләсен, Татарстанның табигый байлыклары дөрес файдаланылсын өчен үтә әһәмиятле өлкә. Идарәнең уңышлы эшчәнлек алып баруы нәтиҗәсендә файдаланылмыйча яткан авыл хуҗалыгы җирләренең мәйданнары елдан-ел кими, туфракның уңдырышлы катламы бозылу һәм юкка чыгу, кешеләр сәламәтлегенә һәм әйләнә-тирәгә зыян сала торган җитештерү калдыклары белән җирләрне чүпләү очраклары торган саен сирәгәя бара. Нурислам Нуриман улының эше иң югары дәрәҗәләрдә югары бәясен алган, ул федераль дәрәҗәдәге агросәнәгать өлкәсе белгече булып тора, аның «Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре» дигән мактаулы исеме шул турыда сөйли.

Баулы якташлык җәмгыяте эшчәнлеге кысаларында идарә рәисе Хәбипов Баулы районында туып--үскән якташларына ярдәм итүгә өстенлек бирә, бу яшь баулылылар якташларыннан ярдәм алсын һәм туган җирләренең кадерен белсен өчен эшләнә. Бу аңлашыла да, Хәбипов өчен традицияләр, мирас, рухият – бик мөһим төшенчәләр. Ул һәрвакытта да үзенең туган авылына ярдәм итә, мәчет төзелешенә матди булышлык күрсәтә. Аны җаваплылык, тәвәккәллек һәм үз көченә ышанганлык, агросәнәгать комплексында олы тәҗрибәсе, ватанпәрвәрлек һәм югары һөнәри осталыгы аерып тора.

Россиянең ТР буенча Авыл хуҗалыгы күзәтчелеге идарәсе хезмәткәрләре коллективы

– Хөрмәтле Нурислам Нуриманович!

Россиянең Татарстан Республикасы буенча Авыл хуҗалыгы күзәтчелеге идарәсе хезмәткәрләре коллективы исеменнән юбилеегыз уңае белән иң ихлас котлауларны кабул итеп алыгыз!

Сез язмышыгызны авыл хуҗалыгы белән бәйләгәнсез һәм бу тармакта үзегезнең хезмәт сөючәнлегегез һәм талантыгыз белән зур уңышларга ирешкәнсез. Сез безнең өчен үрнәк җитәкче һәм олы ихтирамга лаек шәхес. Без Сезгә һөнәр осталыгыгыз, ведомство эшен алга этәрә белгән, нәтиҗәле эшләргә омтыла торган, дустанә, бердәм команда оештыруыгыз, дөрес карарлар кабул итә белүегез һәм хезмәткәрләргә игътибарлы мөнәсәбәтегез өчен рәхмәтлебез. Сез безнең өчен киң күңелле укытучы да, акыллы остаз да.

Хөрмәтле Нурислам Нуриманович! Сезгә чын күңелдән ныклы сәламәтлек, уңышлар, бәхет телибез! Юбилеегыз белән!

Фото Россиянең Татарстан Республикасы буенча Авыл хуҗалыгы күзәтчелеге идарәсеннән алынды

**Евгений Ибраһимов,** «В. Б. Шнепп исемендәге НИИтурбокомпрессор» (ГМС Төркеме) АҖнең генераль директоры, ноябрьдә үзенең 60 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

**Илнур Сәгъдиев,**
«Казанкомпрессормаш» ГАҖнең (ГМС Төркеме) идарәче директоры

## ҮЗ ЭШЕНӘ БИРЕЛГӘНЛЕК

– Хөрмәтле Евгений Рәшитович! «Казанкомпрессормаш» ГАҖ коллективы һәм шәхсән үз исемемнән гомерегезнең матур бәйрәме белән котлауларыбызны кабул итеп алыгыз!

Юбилеегыз көнендә шуны әйтәсем килә: сез бөтен гомерегезне илебезнең машина төзелеше тармагын үстерү эшенә багышлыйсыз. Сез җитәкләгән фәнни-тикшеренү институты Россиядә заманча компрессор җиһазлары эшләүчеләрнең берсе булып тора һәм озак еллар дәвамында ул илне югары сыйфатлы газ кудырту агрегатлары һәм компрессор станцияләре белән тәэмин итеп тора. Завод белән институтны компрессорлар төзү комплексында озак елларга сузылган элемтәләр бәйли – бу исә үзе фән белән җитештерү арасындагы хезмәттәшлекнең уңай үрнәге булып тора. Безнең өчен шушы уңай һәм конструктив мөнәсәбәтләр кадерле.

Сез бай тарихлы һәм уникаль тәҗрибәсе булган легендар предприятие җитәкчелегендә торасыз. Уртак максатлар тирәсенә фикердәшләр, югары квалификацияле конструкторлар һәм фәнни хезмәткәрләр командасы тупладыгыз. Сезнең кешелеклелек сыйфатларыгыз, максатка омтылучанлыгыгыз, новаторларча фикер йөртүегез югары уңышларга нигез булып тора. Ә бай һөнәри һәм тормыш тәҗрибәсе, компетентлы булуыгыз, тармакта тирән белемнәрегез хезмәттәшләрегезнең, кул астында эшләүчеләрегезнең һәм партнерларыгызның ихтирамын яулады.

Хезмәт бөтен нәрсәне дә җиңә! Нәкъ менә Сезнең тырыш хезмәтегез һәм үз эшегезне яратуыгыз тирән хөрмәткә лаек. Миңа рухи яктан якын кеше буларак, Сезгә – кайчандыр сайлаган юлына тугрылык саклаган кешегә карата шәхсән соклануымны белдерәм.

Сез куйган максатларыгыздан тайпылмыйча, аңа ышанычлы адымнар белән барасыз. «В.Б. Шнепп исемендәге НИИтурбокомпрессор» АҖ сезнең акыллы җитәкчелек итүегез нәтиҗәсендә алга таба да актив рәвештә үсештә булачагына һәм ил икътисадына лаеклы өлешен кертәчәгенә иманым камил. Һәрвакытта да перспективага эшли һәм дөрес, заманча карарлар кабул итә белә торган ныклы ихтыярлы, көчле кеше булып калыгыз.

Юбилей – тормышның чираттагы этабын йомгаклап куя торган көн генә түгел. Беренче чиратта, бу үткәннәрне, бүгенгене һәм киләчәкне тоташтыра торган җепне кулда тотып, бүгенгегә кыю караш ташлап, үткәннәргә горурлык белән борылып карарга, киләчәккә өметле планнар корырга мөмкинлек тудыручы көн.

Хөрмәтле Евгений Рәшитович! Сезгә ныклы сәламәтлек, гаилә иминлеге, иҗат илһамы, шулай ук бетмәс-төкәнмәс көч, дәрт-дәрман, кызыклы һәм уңышлы эшләр телим! Үзегезгә һәм якыннаргызга бәхет, гармония, оптимизм, иминлек, шатлык-куаныч юлдаш булсын! Юбилеегыз белән!

Реклама

Фото «Казанькомпрессормаш» ГАЖ (ГМС Төркеме) матбугат хезмәтеннән алынды

**Айдар Шәмсетдинов,** ТР Азнакай районы башкарма комитеты җитәкчесе, октябрьдә үзенең 50 яшьлек юбилеен билгеләп үтә.

**Рамиль ИСЛАМОВ,**
Азнакай районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе;
Азнакай районының барлык милек формалары авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре җитәкчеләре

## ҖИР – ИМИНЛЕК НИГЕЗЕ

– Хөрмәтле Айдар Хәләфетдинович! Сезне Азнакай районы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе, Азнакай районының барлык милек формалары авыл хуҗалыгы товарлары җитештерүчеләре җитәкчесе исеменнән туган көнегез белән котлыйбыз! Сезгә һәр башлаган эшегезгә уңышлар һәм илһам тугры юлдаш булсын! Сезнең өчен яраткан гаиләгез, дусларыгыз, хезмәттәшләрегез ныклы терәк булсын!

Азнакайда яшәүче кешеләр буларак, әлбәттә, безгә төзек урамнарны һәм ишегалларын, яңа торак йортларны һәм социаль объектларны күрү рәхәт, район өчен мөһим булган бәйрәмнәрдә һәм чараларда катнашу күңелле. Барлык максатлар һәм бурычларны, социаль проектларны да Сез гади кешеләрнең ихтыяҗын күздә тотып куясыз, гамәлгә ашырасыз.

Җир – районның төп байлыгы, иминлек нигезе. Район нефтькә генә түгел, икмәге белән дә бай. Һәм Сезнең район башлыгы белән бердәм булып, авыл хуҗалыгы үсешенә һәм шушы өлкәдәге эшкуарлыкка зур игътибар бирүегез бик мөһим. Сез биредә һәр авылны, һәр почмакны беләсез, авыл кешеләренең ничек яшәвен, аларның өмет-ышанычларын белеп торасыз. Районның авыл хуҗалыгы җитештерүчеләренә Сезнең тырышлыклар белән зур ярдәм күрсәтелә, Сезгә аның өчен зур рәхмәтләребезне белдерәбез.

Сезнең тәҗрибә һәм яшәү дәртегез белән Сез әле Татарстан иминлеге хакына озак еллар хезмәт итәрсез дип ышанабыз. Азнакай районы халкының ышанычы һәм теләктәшлеге Сезгә һәрвакытта да ярдәм итеп торсын! Тынычлык һәм имин тормыш телибез!

**Руслан Гәрәйшин,**
«Жилсервис-Азнакаево» Идарәче компаниясе» ЖЧҖ директоры

**Сәгыйрь Гомәров,**
«Наш дом Восход» Идарәче компаниясе» ЖЧҖ директоры

**Элеонора Алчина,**
«Универсал-Азнакаево» Идарәче компаниясе» ЖЧҖ генераль директоры

**Алинә Солтанова,**
«Квартал 28» Идарәче компаниясе» ЖЧҖ генераль директоры

**Илмир Гәрәев,**
«Актүбә» Идарәче компаниясе» ЖЧҖ директоры

## ЫШАНЫЧЛЫ ЛИДЕР

– Хөрмәтле Айдар Хәләфетдинович! Районның Торак-коммуналь хуҗалыгы тармагы җитәкчеләре һәм безнең предприятиеләрдә эшләүче хезмәткәрләр коллективы исеменнән юбилеегыз белән ихлас күңелдән котлыйбыз!

Бүген шушындый истәлекле көндә без Сезгә район иминлеге хакына куйган хезмәтегез өчен рәхмәт әйтәбез. Бүген Сез иң уңышлы тормыш этабында – бай тормыш тәҗрибәсе зирәк акыл белән үрелеп бара, артта башкарылган бик күп эшләр калган, киләчәк өр-яңа планнар белән тулы. Чын мәгънәсендә лидер һәм талантлы оештыручы буларак Сез – Азнакай җиренең ватанпәрвәре, бик күпләр өчен эшсөярлек, фидакарьлек, куелган максатка төгәл адымнар белән ирешә торган шәхес үрнәге. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе вазыйфасында Сез территориянең һәрьяклап үсеше өчен төрледән-төрле бурычлар хәл итәсез, аның иминлеге һәм халкының тормыш дәрәҗәсе яхшырсын өчен хезмәт куясыз. Сезнең җитәкчелектә район халкы иминлеге хакына яңа проектлар гамәлгә ашырыла. Сезгә торак-коммуналь хуҗалыгы тармагына зур игътибар бирүегез һәм көн кадагында торган проблемаларны хәл иткәндә катнашуыгыз өчен рәхмәтләребезне җиткерәбез.

Хөрмәтле Айдар Хәләфетдинович! Чын күңелдән Сезгә һәр башлаган яңа эшегезне уңыш көтеп торсын, куелган максатларга ирешелсен, ә киләчәккә планнар тормышка ашсын, дип теләргә рөхсәт итегез! Конструктив идеяләр, бетмәс-төкәнмәс дәрт-дәрман һәм илһам телибез, үзегезгә һәм якыннарыгызга ныклы сәламәтлек юлдаш булсын!

Фото Азнакай муниципаль районы матбугат хезмәтеннән алынды

Фото «ННК-Геофизика» ЖЧҖнән алынды

**Илдар ХӨСНУЛЛИН,**
«ННК-Геофизика» ЖЧҖнең генераль директоры

## ҺӘРЬЯКЛАП ҮРНӘК

– Хөрмәтле Айдар Хәләфетдинович!

Сезне «ННК-Геофизика» коллективы һәм шәхсән үз исемемнән юбилеегыз белән котлыйм! Сезгә, гаиләгезгә һәм якыннарыгызга иминлек телим. Аларның җылысы һәм кайгыртучанлыгы Сезне тирә-юнегездәге кешеләр белән бүлешердәй тормыш энергиясе белән тулыландырып торсын.

Озак еллар дәвамында Сезнең хезмәт юлы Азнакай районы белән бәйле булды, Сез анда һәрвакытта да җаваплы вазыйфалар башкардыгыз. Соңгы сигез елда Сез районның башкарма комитетын җитәклисез, барлык азнакайлылар өчен мөһим мәсьәләләрне хәл итәсез. Сезнең эшчәнлек, һичшиксез, вакыт һәм көч исраф итүне, өстенлекләрне билгеләп, масштаблы фикерли белүне таләп итә.

Сезнең турыдан-туры катнашлыгыгызда күпме идеяләр тормышка ашырылган, азнакайлылар иминлеге хакына күпме бурычлар хәл ителгән! Без Сезгә бәһаләп бетергесез хезмәтегез өчен рәхмәтлебез. Беренче чиратта, район халкы иминлеге хакына кылган игелекле гамәлләрегез Сезгә өчләтә кайтсын, дип телим. Сез бик күпләр өчен – һәрьяклап үрнәк. Эшкә, гаиләгә, җәмгыятькә карата мөнәсәбәтләрдә үрнәк. Якыннарыгызның күңел җылысы һәм хезмәттәшләрегезнең теләктәшлеге һәрвакыт йөрәгегезне җылытып торсын, ә Сезнең белемегез, тәҗрибә һәм оештыру сәләтегез озак еллар әле район иминлегенә хезмәт итсен. Уй-ниятләрегезгә элеккечә уңышлар юлдаш булсын! Ныклы сәламәтлек һәм иминлек Сезгә!

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА
ТАТАРСТАН
TATARSTAN
facebook.com/protatarstan
twitter.com/protatarstan
БЕЗНЕҢ ТӨРКЕМНӘРГӘ РӘХИМ ИТЕГЕЗ!
instagram.com/protatarstan
Реклама 16+

# ДҮРТ ӨЙЛЕ

# АВЫЛДА – БЕР КӨН

**Автор:**
Руфия Фазылова

**Быелгы көзне әйтәм, нәкъ шагыйрьләр язганча, «алтын» булды. Рәхмәт төшкере, озакка сузылган әбиләр чуагы бу гүзәллекнең гомерен тагын да озынайтты. Чистай районының Дүрт Өйле авылына баргач та, күзгә матурлыкка янә бер сокландык. Хәер, күзгә генә түгел, сөенер, шаккатыр өчен бүтән сәбәпләр дә бар иде.**



Фото: Александр Ефремов

## «ҖИР БЕЛӘН КҮК АРАСЫ»

Дүрт Өйле район үзәге Чистайдан егерме биш чакрым ераклыкта урнашкан. 268 кеше яши биредә, 90 йорт исәпләнә. Әйе, зур дип әйтеп булмый, әмма кечкенә дә түгел. Кызганыч, мәктәпне саклап кала алмаганнар, балалар бакчасы да ябылган. Кайчан гына йөз укучыга белем биргән ике катлы бина бүген ятим булып утыра. Әле ярый авылга яңа Мәдәният йорты, ФАП төзеп куйганнар. Каршыда гына яңа мемориаль такта балкып тора. Болар булмаса, авылның үзәге күңелсез, үзе бетеп баручы саланы хәтерләтер иде. Ә болай күңел авыл яши дип үзен юата.

Бакча яшендәге өч бала бар, биш бала күрше Гаделша урта мәктәбенә йөреп укый икән. Аларны көн саен мәктәп автобусы килеп ала, кайтарып куя. Студентлар күп, әти-әниләре янына атна саен кайталар.

Ни кызганыч, соңгы елларда авылда калучы яшь гаиләләр булмаган. Биредә төп көч – урта яшьтәге кешеләр һәм пенсионерлар. Соңгылары аеруча игътибарны җәлеп итте – җитмешкә җиткән әби-бабайларның берничә сыер асравы гадәти күренеш. Берничә гаиләдә булдык, барысы да күп итеп мал-туар тота.

Авыл җирлеге башлыгы Илшат Нуретдинов башта яңа ФАП, Мәдәният йорты белән танышып чыгарга тәкъдим итте. Бу алар өчен көтеп алынган, бик кирәкле биналар икән.

ФАПның бердәнбер фельдшеры – Эльмира Гатина. Казан дәүләт медицина университетында белем алган, алты ел РКБда хезмәт куйган тәҗрибәле фельдшер ул.

– ФАП ачылганга декабрьдә бер ел гына була, – диде Эльмира ханым. – Искесе белән чагыштырганда, җир белән күк арасы. Бөтен шартлар тудырылган. Процедуралар ясау өчен аерым кабинет бар. Беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен барлык кирәк-ярак җиһазлар да кайтты.

– Элеккеге ФАП бик иске идеме?

– Иске генәме соң?! Аның исеме генә бар иде инде. Шуны да әйтәм: ярык бүрәнәләрдән урам күренеп тора иде.

– Коронавирус белән авыручылар булдымы? – дим Эльмира ханымга.

– Әйтергә дә куркам, бездә берәү дә авырмады дияргә була. Бер читтән кайтып йөрүче кешедә ачыкланды, тик ул өендә үзизоляциядә торды. Аллага шөкер, ул да терелеп китте.

ФАП белән янәшә генә Мәдәният йорты балкып тора. 2016 елда ачылган ул. Мәктәп, балалар бак-

– Һәр бәйрәмгә концерт әзерлибез, театр куябыз. Берничә түгәрәк эшли, – диде Мәдәният йорты җитәкчесе Альбина Нуретдинова.

– Китапханәгә хәзер өлкәннәр дә йөри башлады, чөнки бакча эшләре бетте, – диде китапханәче Альбина Нуретдинова.

Галимовлар – авылның күрке.

часы да булмаганлыктан, авыл халкы, шул ук вакытта балалар өчен очрашу, аралашу урыны да ул. Мәдәният учагы әллә ни зур түгел – 50 урынга исәпләнгән. Шунда ук китапханә дә бар. Ял итү бүлмәсе – барысы да заманча, якты, җылы.

– Халык йөри, – диде Мәдәният йорты җитәкчесе Альбина Нуретдинова. – Һәр бәйрәмгә концерт әзерлибез, театр куябыз. Берничә түгәрәк эшли. Балалар да, өлкәннәр дә йөри. Дөресен генә әйткәндә, хәзер күбрәк өлкәннәр белән эшлибез. Яшьләр бик юк бит инде.

– Әле күптән түгел генә Укытучылар көненә багышлап, авылдан чыккан барлык укытучыларны җыйдык, – дип сүзгә кушылды китапханәче Альбина Нуретдинова. (Кызлар бертуганнарга кияүгә чыккан. Шулай итеп авылда хәзер ике шундый исем-фамилияле ханымнар бар. – Авт.) – Ел саен нинди дә булса һөнәр ияләрен җыеп, җылы, күңелле кичә оештырабыз. Шулай ук якташларны җыябыз.

– Китапханәгә йөрүчеләр бармы? – дим.

– Бар, хәтта күп. Җәен балалар еш килде, каникулга кайтучылар да күп булды. Хәзер инде өлкәннәр йөри башлады, чөнки бакча эшләре бетте. Газета-журналларны алып укучылар да күп. Матбугатка язылу кыйммәт, элеккеге кебек һәр йортка берничә газета-журнал килми.

## «ТЕХНИКА ҖЕНЕ» КАГЫЛСА...

Яшерен-батырын түгел, йортка кунак килсә, ата-ана баласының уңышларын күрсәтергә тели. Авылларга баргач та шундыйрак хәл күзәтәбез – авыл җирлеге башлыгы иң матур гаиләләр белән таныштыра. Дүрт Өйлегә баргач та шулайрак булды. Илшат Нуретдинов белән ике катлы, заманча йорт каршысына килеп туктадык. Биредә Галимовлар яши икән. Гаилә башлыгы түбәтәйдән, хуҗабикә исә яулык бөркәнгән. Галимовлар – авылның күрке.

– Төп нигезебез – каршыда, – дип сүз башлады Илдус Галимов. – Анда хәзер әни яши. Иптәшем Мәликә белән гаилә корганга егерме биш ел булды. Ике бала үстердек. Кызыбыз кияүдә инде, оныгыбыз да бар. Улыбыз Эмильгә унҗиде яшь, быел 11 нче сыйныфны тәмамлый.

– Сезне авылда үз итеп «лесник Илдус» дип йөриләр икән? – дим.

– Әйе, унбиш ел «лесник» булып эшләдем. Бу вазыйфадан киткәч тә урман хуҗалыгы белән бәйле юлны дәвам иттем. Үзебезнең пилорама бар, такталар, борыслар чыгарабыз. Тагын буралар бурап, утын ярып сатабыз. Якын-тирәдәге ун район, Казан, Чаллы шәһәрләре – җитештергән продукция төрле җирләргә китә.

– Агачны сатып аласызмы?

– Әйе, Ижаудан ташыйбыз.

Илдус Галимов шәхси эшмәкәр булып теркәлгән. Пай җирләрен рәсмиләштереп, әнә шулай пилорама ясаган.

Даими эшкә ике кешесе бар, заказлар күп булганда, тагын бүтән авылдашларын да чакыра. Җәй – төзелеш сезоны, шуңа да әлегә кадәр ике сменада эшләгәннәр.

– Быел төзелеш материалларына сорау азрак булды,-ди эшкуар. – Беренчедән, агач, ягулык кыйммәтләнде. Бу сорауны киметә торган беренчел фактор. Әле бездә бәяләр башкаларныкы белән чагыштырганда арзанрак та. Конкуренция зур булганда, кулланучыларны җәлеп итүнең төп чарасы бу.

Гаилә башлыгы тормыш иптәше белән таныштырырга ашыкты:

– Мәликә ханым була, балаларга дин сабаклары укыта, – диде.

Мәликә Галимова Дүрт Өйле мәчетендә дә, Чистайга барып та балаларга белем бирә икән. Үзе исә Мөхәммәдия мәдрәсәсен тәмамлаган.

– Дингә кайчан килдегез? – дидем Мәликә ханымга.

– Дәү әнием бик гыйлемле иде. Илдус белән өйләнешкәндә намазда түгел идек әле. Безгә килгән саен дәү әни Аллаһ, Коръән турында сөйләде. Бу йортны эшли башлаганда исламга килдек дисәм дә була. Йортка хәрам ризык, эчемлек кергәне юк, шуңа сөенәбез.

– Дин сабакларын өйрәнергә теләүче балалар күпме?

– Күп, Дүрт Өйледә дә, Чистайда да. Гомумән, соңгы елларда районыбызда динебезгә карата игътирам, игътибар артты. Чистайда зур мәчет ачылды. Күңелендә иман булган кешеләргә мөмкинлекләр зур хәзер.

Галимовлар гаиләсендә биш сыер бар, тагын үгез-бозаулар асрыйлар. Моннан тыш, сарыклары күп, аларга Корбан бәйрәмендә сорау зур икән.

Гаилә башлыгы гаражга чакырды. Бу аның иң яраткан урыны икән. Гаражда ике «Ленд Крузер» (ирнеке, хатынныкы), ике чит ил мотоциклы, «Буран», квадроцикл... Һәм тагын бер ят техникага күз төште. Үзе трактор, үзе экскаваторга охшаган бу машинаның төгәл исемен әле хуҗа уйлап тапмаган. Ни өчен дигәндә, яңа ул, 12 көн эчендә җыелган трактор-машина. Иген ташырга, кар көрәргә, йорт арасындагы башка кирәк-яракларны эшләр өчен дип планлаштыралар.

– Руль артына утыргач, үземдә канатлар үскән кебек тоям, – диде Илдус Галимов. – Шундый бер рәхәтлек бирә. Һәр төр техника үзенчә кыйммәтле. Җәен мотоциклда җилдерергә яратам. Документларны шәһәргә алып барып кайтырга кирәк булса да җайлы, тиз. Кышын «Буран»да кызык. Аның белән күбрәк Чистайга – Балалар йортына барам. Андагы балаларны йөртеп әйләндерәм. Алар көтеп тора.

Раил Зиннәтов,
Дүрт Өйле авылы
мәчете имамы.



Мингалимовлар:
«Алга таба
мал асрап
көн күрергә
уйлыйбыз».



**Мең баш каз-үрдәк асраучы Хәмматга-лимовлар.**

Галимовларның улы Эмильгә дә «техника җене» кагылган. Унике яшеннән трактор йөртә икән. Әтисенең уң кулы да, сул кулы да ул.

Миңа менә нәрсә кызык тоелды – гадәттә, күп ата-ана чыгарылыш сыйныф баласына бер эш тә кушмыйча, «укысын» гына дип тора. Ә Эмиль мәктәптән кайтуга пилорамага килә, утын вата. Аңа карап мәктәптә дә сынатмый – яхшы билгеләргә генә укый.

Утын вату дигәннән, күпләр унҗиде яшьлек малай балта белән утын вата дип уйлар. Бу алай түгел. Илдус әфәнде утын вата торган җайланманы да үзе уйлап тапкан. Тракторны кабызгач, ул «җанлана». Бары тик киселгән агачларны куеп кына барырга кирәк. Менә шулай яшиләр хәзер авылда!

## «БЕЗНЕҢ ДӘҮЛӘТ – ӘТИ-ӘНИ!»

Тагын бер гаилә – Мингалимовлар янында булдык. Күп балалы гаилә дип таныштырдылар. Төпчек балалары беренче сыйныфта укый, олы кызлары кияүдә икән инде.

– Авылда калган яшь гаиләләрнең берсе сез икән, – дигәч, хуҗабикә Рәзинә Мингалимова елмаеп куйды:

– Кырыктан узгач та яшьләр рәтендә йөрибез менә, – диде.

Фәргать һәм Рәзинә Мингалимовлар, ике кызлары үсеп беткәч, бер-бер артлы кыз, малай алып кайтканнар. Бүген Самат – беренче, Зәринә икенче сыйныфта укый.

– Кечкенәләрнең үскәнен күрмәдек, аларны ике кыз үстерде, – диде ата кеше.

Мингалимовларның гаилә коруларына егерме биш ел була икән. Ана кеше унбиш ел Дүрт Өйле урта мәктәбендә эшләгән, башлангыч сыйныфлар укытучысы. Гаилә башлыгы исә төрле җирдә хезмәт куйган: бүген трактор, комбайнда эшли.

– Алга таба мал асрап көн күрергә уйлыйбыз,– диде Фәргать Мингалимов. – Кешегә эшләп әллә ни майтарып булмый. Бүген биш савым сыеры, биш танабыз бар. Алла боерса, сыер башын уннан да ким итмәскә иде.

– Дәүләт программаларында катнашканыгыз бармы, грантлар алдыгызмы? - дим.

– Юк, үз көчебез белән яшибез. Безнең дәүләт – әти белән әни. Гел ярдәм итеп торалар. Күршедә генә яшиләр. Печәнен дә бергә җыябыз, башкасын да. Үзебезнең пай җирләрен алып печән чәчтек. Әтинең техникасы бар.

– Быел биш баш савым сыеры булган кешеләргә бушка сыер саву аппараты бирәбез, – дип куйды авыл җирлеге башлыгы Илшат Нуретдинов. – Узган ел алты сыеры булучылар алды.

Мактаулы әти белән дә таныштык – тиздән җитмеш яшен тутыручы Азат абый Мингалимов тормыш иптәше Зөлфия апа белән бергәләп гомер итә икән. Күзгә ташланган иң беренче сыйфат – икесе дә җор телле.

– Яңа гына биш бозау алып кайттык. Өйдә биш савым сыеры, дүрт бозау бар иде, – дип шаккатырдылар.

– Ә шул хәтле малны кем карый? – дим Азат абыйга.

– Үзебез, карчыгым белән.

– Минем адрес лапаста, – дип көлде Зөлфия апа.

– Сез гел шундый шат күңеллеме? – дип гаҗәпсенәм. – Җитмешкә җиткәндә кеше эшләп арыган була...

– Без дә арыйбыз инде, сеңлем. Тукта, дип янә йөгерәсең, – диде хуҗабикә. – Балаларга булышасы килә. Бабай тик торырга яратмый, мине дә тик тотмый. Менә шулай илле елга якын яшибез. Гел йөгереп, гел чабып, дигәндәй. Утыз ел почта тараттым. Гаделша авылы безгә биш чакрым ераклыкта. Шуннан көн саен диярлек кочак-кочак газета-журнал алып кайта идем, күп очракта җәяү йөрелде.

...Мөгезле эре терлектән тыш Дүрт Өйледә күп итеп кош-корт асрыйлар. Авылда ике зур күл бар, шунда йөзүче каз-үрдәкләрне күреп шаккаттык. Ә Хәмматгалимовлар бөтенләй гаҗәпләндерде – хуҗалыкларында 1 мең баш каз-үрдәк бар. Дистә елдан бирле шулай үстерәләр икән. Кара көздән башлап Яңа елга кадәр көн саен диярлек өмә ясыйлар.

– Каз, үрдәкләрне йолкырга авыл апаларын чакырам. Җырлашып, элеккеге хәлләрне сөйләшеп утырабыз, – диде Гүзәлия Хәмматгалимова.

Ир белән хатын эшне җайлаган: каз, үрдәк түшкәләрен атна саен ярминкәгә алып баралар. Өйдән дә килеп алучылар күп икән.

Һәр авылның бер үзенчәлеге була. Кайдадыр ул матур йортлар, кайдадыр ул заманча берәр объект. Дүрт Өйленең иң зур байлыгы – аның шат күңелле тырыш кешеләре. Өлкән яшьтәге кешеләре дә боегып утырмый, гел хәрәкәттә. Белгәнебезчә, хәрәкәттә – бәрәкәт!

## ТАРИХ БИТЛӘРЕННӘН

**Раил Зиннәтов, Дүрт Өйле авылы мәчете имамы:**

– Ни кызганыч, авылның тарихын архивларда утырып өйрәнгән кеше юк. Халык сүзләренә караганда, авылда 1640 елга караган каберлек булган. Димәк, Дүрт Өйле шул чорда ук яшәгән дип исәпләргә мөмкин. Әби-бабайлардан килгән риваятьләр буенча, авылга Кадыйр дигән кеше нигез салган. Казан ханлыгы алынып, көчләп чукындыру дулкыны башлангач, Казан янындагы районнардан халык таулы, ташлы якларга барып урнаша. Безнең авылның да оешу тарихы шулай булырга бик мөмкин, диләр. Авыл тарихы белән бәйле икенче тарих та бар. Минемчә, анысы чынбарлыкка күбрәк туры килә. Гадәттә, татар авылларының атамасы рус теленә тәрҗемә ителми. Ә менә Дүрт Өйле барлык документларда да Четыре Двора дип тәрҗемә ителгән. Моның сәбәбен болай аңлаталар – бирегә иң беренче булып дүрт рус гаиләсе килеп урнашкан. Әле безнең бабайлар да Микуч исемле кешене телгә ала иде, ди авыл халкы. Менә шул авылга нигез салучыларның берсе булгандыр дип фаразлый алар. T

# БУ БИТ СОЧИ! РӘХИМ ИТЕГЕЗ!

**Бөтен Россия журналистлары, җәйне тагын бер атнага озынайтып, Сочида узган XXIV «Вся Россия – 2020» заманча журналистика форумында очрашты. Анда аларны диңгез, кояш, әйдәп баручы спикерларның осталык дәресләре, Россия Журналистлар берлеге үткәргән конкурста җиңүчеләрне (шул исәптән «Татарстан» журналын да) котлау, ә бию мәйданчыгында номинантларны рәхәтләнеп ял иттергән Верка Сердючка көтә иде...**

## БЕЗ ҺАМАН ШУЛ

Мондый командировкалардан зарланучы булмый – Россия халкын үзебезнең курортларны сайларга мәҗбүр иткән пандемия ярдәменә карамастан, биредәге хезмәт күрсәтүнең һаман да дөнья дәрәҗәсенә күтәрелмәве дә кәефне төшерә алмый хәтта. Барысы да шуңа бәйле: әлеге хезмәт күрсәтүчеләрнең һәркайсы биредә иң әүвәл шәхес, аннары гына хезмәткәр, персонал яки үзе кебекләргә хезмәт күрсәтергә мәҗбүр ителгән бахыр. Шунлыктан «Жемчужина» кунакханәсенең әле бер, әле икенче җирендә канәгатьсезлекләр, низаглар кабына торды – журналистлар исә, күнегелгән гадәтләре буенча, аларны тырышып яктыртты – вакыйгалар урыныннан турыдан-туры репортаж алып барды. Барысы да бер нәтиҗәгә килде – биредә һаман СССРдан калган гореф-гадәтләр хакимлек итә әле!

## СССР МИРАСЫ

Төркия кунакханәләренә бәяләрнең төшүен һәм моның үз территориясенә агылучы сәяхәтчеләрне киметү ихтималын яхшы чамалаган Сочи мэры, курортның туристлык имиджын күтәрү һәм шәһәр казнасын тулыландыру өчен, сочилыларны кунакчылрак булырга өндәсә дә, кунаклардан шактый туеп өлгергән кунакханәләр тулысынча «совет сервисына» күчте. Бу алтын чорда яшәргә өлгермәүчеләргә исә «Сваты» сериалыннан әлеге сервисны бик төгәл бәяләүче гыйбарәне искә төшерү җитәрдер: «Понаедут из своих Турций-шмурций...Мне шо, разорваться, шо ли?»

## КУНАКЛАР

Бу юлы Сочига, «Кинотавр-2020» фестиваленә дип, – кино йолдызлары, «Вся Россия – 2020» форумына дип, журналистлар һәм тагын «Формула 1» узышчылары төялеп килеп төште. Әлеге топ-чараларда катнашучыларның барысы да совет чорыннан калган хезмәт күрсәтүне үз җилкәсендә татыды:

– Бүген сезнең номерны җыештырырга өлгермибез – туристларны урнаштырасы бар бит! Сабыррак булыгыз!

– Командировка кәгазьләрегезне тутырырга өлгермибез – туристларны урнаштырасы бар бит! Күрмисезме әллә?!

– Пляжда сөлгеләр бетте – ни өчен икәнен белмим, аптыратмагыз инде! Әллә кайлардан киләләр дә бездән дә шуны таләп итәләр!..

## ЧАГЫШТЫРЫП ТА БУЛМЫЙ

Җәй буена шактый арыган Сочи халкы үз алдына сукранып, мыгырданып йөри:

– Аяк астында буталалар һаман, үзләре бернәрсә дә алмыйлар, нигә киләләрдер монда!

– Сезгә Таиландта елмайсыннар энә, бусына да рәхмәт әйтегез әле!

– Бәрхет сезонга килгәннәр, имеш, үзләре дәфнә яфрагы да сатып алмыйлар, хәерчеләрмени!

Ял итүчеләр дә бурычлы булып калмый билгеле, сөенә-сөенә талаша башлыйлар – ата-бабалардан калган әрләшү геннары үзенекен итә:

– Балыгыгыз нигәдер бик вак сезнең!

– Том-ям да Таиландтагы кебек түгел...

– Бу кадәр акчага Төркиядә биш йолдызлы затлы, чиста кунакханәдә бер ай буе рәхәтләнеп ял итеп булыр иде!

– Балига барып кайту арзангарак төшә!

– Үз акчабызны түләп, шундый тупаслыкка түзәбез бит, әй!

– Үткән заманга кайткандай, бер утыз яшькә яшәргәндәй булдык...

## ҮЗЕБЕЗНЕКЕ, ҮЗЕНЧӘЛЕКЛЕ, КАБАТЛАНМАС

Әмма болай тиргәшеп, сүз көрәштереп алулар ике якның да кәефен төшерми. Сувенирларның барысында да диярлек «Бу бит Сочи!» – дип язылган: җылы диңгезе һәм тупас сервисы – барысы да үзебезнеке! Үзебезнеке, үзенчәлекле, кабатланмас. Төркиядәге ял да бит башка беркайда да кабатланмый, Таиландтагы да, Балидагы да бары тик аларга гына хас... Һәрбер курортның үз диңгезе, үз өстенлеге, үз төсмере бар.

Шуңа күрә әгәр беркайчан да үзгәрмәс кунакчыллык мисалы табасыгыз килә икән, татарстанлыларгы кунакка барыгыз. Республикабыздан читкә китүчеләрнең кайсы илдә яшәве әһәмиятле түгел – бөтен җирдә дә һаман шундый ук кунакчыл безнең якташларыбыз.

Шунлыктан «Татарстан» Сочи татарлары янына кунакка барып килде. Һәм алар һәрвакыттагыча өметне акладылар, йөзгә кызыллык китермәделәр:

– Бу бит Сочи! Рәхим итегез!

## ДИҢГЕЗДӘ ХЫЯЛЛАР ЧЫНГА АША

– Рәхим итегез! – дип сәламлиләр «Татарстан» журналы вәкилләрен Татарстанның Чирмешән районында туып-үскән Рушания апа Беляева һәм чыгышы белән Сарманнан булган Рәшит Вәгыйзь улы Заһиров. Һәм, безгә йорт түбәләрендәге күзәтү мәйданчыгыннан әйләнә-тирәгә экскурсия үткәреп, үз хыяллары белән уртаклашалар. Хыяллары исә мондыйрак: Сочида, әнә тегендәге тауда, мәчетле татар авылы булсын иде, ул әллә кайдан күренеп торсын иде! Бик күп мөселман яшәгән Сочида бер генә мәчет тә юк икән бит!

– Ә бу бит бер дә толерантлылык түгел, – ди Рушания апа һәм шундук искә төшереп тә ала: Минтимер Шәймиев Татарстанда һәр мәчеткә бер чиркәү һәм һәр чиркәүгә бер мәчет төзергә кушкан бит.

Без инде моны хәтерләмибез дә, гыйбадәтханәләрнең һәрвакыт шулай парлашып төзелүенә күптән күнеккәнбез. Ә менә Рушания апа хәтерли.

Без әлеге Татарстан – Сочи хыялының тормышка ашуын теләп рәхәтләнеп шашлык-өчпочмаклар белән сыйланабыз.

– Диңгездә барлык хыяллар да тормышка ашарга тиеш! – дип өметләндерә безне хуҗалар. – Бу бит шуңа күрә дә Сочи! т



ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

# ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама 16+

## Безнең Инстаграмда – «Татарстан»ның йөрәге!